Безнен МИРАС

04
апрель 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Фото ТР Президенты сайтыннан алынды

16-18 мартта башкалабыз Казанда V Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены булып үтте. 700гә якын делегат катнашкан әлеге эшлекле вә мәртәбәле җыенны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты оештырды. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты һәм чыгыш ясады.

Без – һөнәрле, булдыклы халык!

Лилия Гаделшина фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
4(51)
апрель 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас»,
2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан кабат гамәлгә куелып,
«Чын мирас» исемнәре белән чыкты.
2014 елның маеннан «Безнең мирас»
итеп үзгәртелде.

34 ТАТАР ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕК. *Гариф Латыйф*

90 ИЛДУС ӘХМӘТҖАНОВ: «ТУКАЙ МИҢА МӘРХӘМӘТЛЕ БУЛДЫ...»

60

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Туры Тукай сүзләре
6 Писатели мира о Тукае / Әдипләребез, шәхесләребез Тукай турында

ТАРИХИ МИРАС

16 Мотыйгулла, Мөхәммәтгариф һәм Габдулла. *Ә.Фәйзрахманов*
22 Уфа да Тукай эзләрен саклый. *Ф.Фәтхи*
25 «Шималь ягы» газетасы. *Л.Гобәйдуллин*
30 «Сүз» газетасының Тукайга багышланган бер саны. *Э.Галимҗанова*
34 Татар халык шагыйре Габдулла Тукай турында истәлек. *Г.Латыйф*
43 «Үзем дә, балалар да ялангач...» *Л.Тябина*
46 «Тукайны өйрәнгәндә сенсация артыннан куарга ярамый!» *(Түгәрәк өстәл)*

ТАТАР ГАМЕ

56 Габдулла Тукай: «Бу милләтне Ходаем бәхетле итсен». *Шәехҗан Фәния Хуҗахмәт*

ӘДӘБИ МИРАС

62 Габдулла Тукай белән күрешүем. *М.Гали*
64 Чын кеше кадере. *М.Вәлиев*
71 Габдулла Тукай Олы Мәңгәрдә. *М.Әхмәтҗанов*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

72 Габдулла Тукай. *Р.Мөхәммәтша*
80 Тукай бәете

СӘНГАТИ МИРАС

81 Тукайга якынаю баскычлары. *Ә.Зарипов*
88 «Сират күпере». *Р.Батулла*
90 Илдус Әхмәтҗанов: «Тукай миңа мәрхәмәтле булды...»
96 «Шүрәле» балетының катлаулы тарихы. *А.Алмазова*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

ХӘТЕР САГЫНДА

105 **Г.Тукай әдәби музеенда шагыйрьнең шәхси әйберләре**

ТАТАР ҖЫРЫ

108 **Милләт яшәсә, Тукай онытылмас!** *Ш.Әхмәтҗанов*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

110 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
112 **Тукай һәм туган телебез.** *В.Хаков*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның апрель ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Габдулла Тукай**

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Апрель*

Заказ №М-809. Тираж — 2000 данә. Формат 70 X 108 $^{1}/_{16}$
Басарга кул куелды: 30.03.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Тукай Кырлайда». *Фәйзрахман Әминов рәсеме*



Туры Тукай сүзләре

Туган телебез гасырлар дәвамында эшкәртелгән, шомартылган. Тормыш тәҗрибәсен төрле яктан гомумиләштереп, канатлы сүзләр, афоризмнар да барлыкка килә, тарала, халык тарафыннан көндәлек тормышта киң кулланыла. Алтын бөртекләредәй канатлы сүзләр, афоризмнар иҗат итүгә шагыйрь-язучылар да зур өлеш керткән. Мифтахетдин Акмулла «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән», дип әнә шуңа ишарә иткән дә инде. Бу җәһәттән караганда, халкыбыз арасында «Туры Тукай» дип дан казанган бөек шагыйребез дә үзеннән зур өлеш керткән. Кайбер тикшерүчеләр фикеренчә, Тукайның 150гә якын шигъри юллары мәкаль-әйтем рәвешендә йөри.

Танылган җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, тел галиме Галимҗан Шәрәф (1896-1950), Габдулла Тукай әсәрләреннән гыйбрәтле сүзләрне җыйнап, «Тукаев сүзләре. Җамигел-кәләмләре (афаризмалары), халык мәкальләре урынында йөртерлек вә йөртелә торган сүзләре)» дигән китап төзеп, аны берничә мәртәбә бастырып чыгара. Ул аларны унбер тематик төркемгә берләштергән һәм ахырда янә гыйлавә, ягъни өстәмә рәвештә дә урнаштырган.

Безнең карамакта бу китапның 1915 елда нәшер ителгән икенче басмасы бар. Журнал укучыларга мисалларны шуннан тәкъдим итәбез. Төрле төрдәшләр кебек кабул ителмәсеннәр өчен, текстлар безгә мәгълүм басмалар нигезендә китерелде. Ләкин шулай да кайбер фонетик үзенчәлекләр оригиналдагыча калдыру мәгъкуль күрелде.

АЛЛАҺКА ЫШАНУ

Түкмә күз яшь: ярдәмеңдә һәр заманда Аллаһ бар;
Ал җәсарәт[1], алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!

[1]Җәсарәт — батырлык.

***

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

МӘХӘББӘТ

Минемчә, тик яралган ул сөелергә,
Сөяргә һәм куаныргә, көенергә;
Күргән саен, минем төсле гашыйкларга:
«Бу минеке булмас!» — диеп көенергә.

***

Хуш, җаным! — сөймим хәзер сине вә синнән башканы;
Син сөя бир алда тагын берне — миннән башканы!

***

Бер мәхәббәтне — газабын, михнәтен сизгән кеше,
Бер сөеп арган вә җөмлә нәрсәдән бизгән кеше —

Күңеле бозланган кешедер: һич тагын бер кат сөймәс,
Инде ул беркем өчен дә гамь йимәс һәм «аһ!» димәс.

БАЛАЛАР ВӘ БАЛАЛЫК ВАКЫТЫ

Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең — барлык вөҗүдең[2] *пакь синең;*
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

[2] Вөҗүдең — бар булуың.

***

Бәхетле нарасыйдә! Тар бишек тә киң әле аңгар!
Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан тиң әле аңгар!

ҮЗЕҢӘ ЫШАНУ

Сәгадәт талына менсәң — үзең мен;
Ни ярдәм килсә дә килсен үзеңдин.

***

Ышанма, дөньяда һәркемдә ялган!

***

Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл.

ЭШКӘ ӨНДӘҮ

Булса калдырмак берәү, ошбу җиһанда изге ат,
Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһад[3]*.*

[3] Иҗтиһад — тырышлык.

***

Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың бер заман!

***

Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел.

ӨМИД ВӘ ӨЗЕЛГӘН ӨМИД

Юк! Түбән калмас бу җан: фитрәттә[4] *гали булган ул,*
Кисмәк өстенә каракош — иттифакый[5] *кунган ул.*

[4] Фитрәттә гали — яратылыштан ук бөек.

[5] Иттифакый — очраклы.

***

Теләү бетте хәзер миндә теләк соңра теләкләрне...

МИЛЛӘТ, МИЛЛИЯТ ВӘ ТУГАН ЙИР

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.

Татар бәхете өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

***
Бу сәбәптән аңладым мин, и туган йирем, синең
Җанга җагымлы икәндер ялкының да дулкының!

ХАЛЫК ТЕЛ ВӘ ӘДӘБИЯТЫ

Халык җырлары — безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр.

ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘРГӘ

Ул тота ат койрыгын да: «Бу — озын сач!» — дип куя.
«Тик нигә башта түгел, тәнкыйтькә мохтаҗ!» —дип куя.

***
Үзләре... сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән;
Эт кеби һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.

Дөньядан туйдым, өмидем юк, алар күпсенсә дә;
Тик мин үлгәчтен, караңыз, типмәсеннәр нәгъшемә[6]!

[6] Нәгъшемә — табутыма.

АЛТЫН ВӘ БАЙЛЫК

Бу җиһан Иблис вә шәйтаннар белән калыр тыныч,
Бетсен иде шул сары йөз, — шундадыр зур куркыныч.

***
Туктале, бер көн килер дә өйрәтер, әлбәт, ләхет, —
Мильёның ул тар ләхеттә файда бирмәс, бәдбәхет!

КИҢӘШ-НӘСЫЙХӘТ

Ихтыяҗын гарз[7] итеп килсә теләнче капкаңа,
Каты сүзләр берлә инсаниятен[8] син таптама.

[7] Гарз (гарыз) итеп — үтенечен белдереп.

[8] Инсаниятен — кешелеген.

***
Әйләнә, көпчәк кеби, байлык вә шөһрәт, мәртәбә:
Син бүген бай, бәлки, шәйтаннан да ярлы иртәгә!

***
Батарсың, дим — йөгермә Нилгә каршы;
Кире кайтыр — түкермә җилгә каршы.

***
Кем генә булсаң да бул — юк ансына һичбер сүзем;
Тик сүзем шулдыр сиңа: саклан булудан үз-үзең!

*Кереш мәкалә һәм текстларны **Рәмил Исламов**,*
***Җәүдәт Миңнуллин** әзерләде.*

ПИСАТЕЛИ МИРА О ТУКАЕ

ӘДИПЛӘРЕБЕЗ, ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ ТУКАЙ ТУРЫНДА

Гаяз ИСХАКЫЙ (1878-1954):

«Тукайның бәхете шунда ки, ул үзенең бөтен үсүене, күтәрелүене халкыбызның үсүе, күтәрелүе белән бергә баглап алып барган. Ул үзенең бөтен иҗадының көч-куәтене халыкның көченнән алып, халыкның кайгы-хәсрәтене, сөенечене халкыбыз белән бергә җырлап, бергә көйләп, халкыбыз эчендә үзенең иҗад куәтене эретеп җибәреп, халык белән берләшкән, үзенең бөтен иҗадиятенең тамырларыны халыкның бу көненә генә түгел, кичәгесенә дә, аннан элеккесенә таба да җибәреп, халыкның барлыгы белән бергә тамырланган, төпләнгән. Халыкның баруы, яшәве белән Тукайның яшәве табигый рәвештә берләштерелгән.

Менә шуның өчендер ки, гыйльми әзерлеге урта, ятим, фәкыйрь егерме биш яшьлек Габдулла Тукай һичбер кемнең өндәве, димләвеннән башка, халкы тарафыннан сөелеп җитеп, киң халык катлавының эченә, рухына сеңеп, халык шагыйре булып өлгергәндер. Менә шул милләтнең күңеленә манчып кына каләмене тибрәткән өчендер ки, Тукайның шигыре зыялыларыбыз мохитендә генә булып калмаенча, авылга җитеп, урамга, кырга, басуга чыгып, киң халык катлавыбызның малы булып өлгергәндер. Вә бик кыска еллар эчендә аның шигырьләре көйләп-көйләп, халык җырларыбыз белән ярышып, аларның урыннарын тота башлагандыр».

Фатих ӘМИРХАН (1886-1926):

«...Аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды... Шәхси тормыштан мәхрүм Тукаев үзенең шигырьләре, ул шигырьләрнең халык күңелендә яңгыраткан яңгырашы белән генә яшәде, шул гына аңа тормыш иде».

Чингиз АЙТМАТОВ (1928-2008):

«Я движим чувствами признательности к таланту и наследию Тукая, ибо Тукай принадлежит не только татарскому народу, география принадлежности его неизмеримо шире. Что я думаю об этом великом человеке, о нашем предшественнике в тюркоязычных литературах? Мустай Карим сказал, что Габдулла Тукай был и есть самый великий татарин во всей татарской истории. Я согласен с ним. Появление такой личности происходит, по моему мнению, не случайно. Мне думается, что такая личность появляется в самый обостренный, самый напряженный, самый трудный, самый обнадеживающий момент истории, какой была история предреволюционной России, в лоне которой возник и возвысился голос Габдуллы Тукая. Тем не менее есть загадка Тукая, есть тайна великого поэта, необъяснимость таланта.

...Как, каким образом возникают такие таланты? Как мог появиться Лермонтов? И как мог появиться Тукай? Удивительная зрелость таланта Тукая, она поражает; иногда думается, что он прожил не 27, а может быть, 270 лет на свете. Вот какова сила и мудрость его мысли. Удивительно также, что этот великий поэт, великий художник проявлял поразительное политическое чутье и социальное сознание. Он был среди тех, кто вел под уздцы нацию и боролся за ее возрождение. Значение Тукая состоит в том, что он совершил переоценку истории и культуры своего народа. Это великое достижение личности, великое достижение художника.

Значение Тукая огромно и для прежнего Туркестана, для всей Средней Азии. Все тюркоязычные народы испытали воздействие творчества Тукая. Нет таких людей в нашем краю, среди тюркоязычных народов Средней Азии, которые бы не знали, не были знакомы с творческой личностью Тукая, его взглядами».

Расул ГАМЗАТОВ (1923-2003):

«Тукай является как бы удостоверением величия таланта своего замечательного, великого народа. К нему любовь у меня наследственная. Я вырос в поэтической семье. Мой отец был поэтом. Еще в детстве в нашей горской сакле звучало это имя, и запало оно в мое сердце. Мой отец не знал по-татарски и я не знаю. У этого поэта удивительная судьба. Ведь даже наши поэты Дагестана, которые писали на родственных языках, часто друг друга не знали. Из далекого Татарстана это имя шагало через моря, через реки. В каждом доме, сакле он нашел приют. «Какой удивительный поэт!» – сказал о нем мой отец. Замечательный русский поэт Есенин, читая его, тоже сказал: «Какой поэт!»

Наверно, каждый, кто с ним познакомился, скажет: «Какой поэт!» Поэт он действительно замечательный и великий. У нас была должность – огнедержатель, когда в горах не было электричества, не было свеч. Огнедержателем своего народа можно назвать и Тукая. Это – огонь любви, это – огонь таланта, это – огонь непримиримости к пошлости, лжи, огонь ненависти к многочисленным врагам всей земли. Этот огонь он завещал нам. И мы пронесем его через годы, века. Имя его дорого нам. Жизнь его – как молния. Судьба его нам дорога, потому

что эта судьба сплетена с судьбой народа. Он оставил нам большое наследство. Оно принадлежит не только татарскому народу, но и всем народам. Жалею себя, что я беден, чувствую себя бедняком, что не знаю татарского языка. Но в то же время чувствую себя богатым, так как я его понимаю, чувствую его любовь, его дружбу, его талант. Спасибо народу, который подарил нам такого великого сына, как поэт Габдулла Тукай».

Максим ГОРЬКИЙ (1868-1936)

«Мир этот не для художников, им всегда было тесно и неловко в нем, – тем почетней и героичней их роль. Очень хорошо сказал один казанский татарин – поэт, умирая от голода и чахотки: «Из железной клетки мира улетает, улетает юная душа моя…»

Давид КУГУЛЬТИНОВ (1922-2006):



«Поэзия Тукая как бы полностью вобрала в себя время со всеми его заботами, со всеми его проблемами. Время – это жизнь людей, их обычаи, традиции, взаимоотношения. И если мы посмотрим на поэзию Тукая, она вся пронизана народным началом (форма, содержание, стиль произведений).

…Тукай умер в 27 лет. И даже не верится, что за такую короткую творческую жизнь он смог охватить такой широкий круг тем, затронуть такие глобальные проблемы…

Гениальность Тукая не только в том, что он умел своевременно поднимать вопрос, гениальность его и в том, что он своевременно умел на него и отвечать».



Рувим МОРАН (1908-1986):

«До сих пор не до конца еще изученная творческая деятельность Тукая спрессована в короткие семь лет, но богатства ее хватило бы не на одну более протяженную жизнь. В этом одна из черт величия Тукая. Столь любимый им Лермонтов не дожил до своего 27-летия два с половиной месяца, Тукай – несколько дней. А сколько они успели сделать!

В Тукае мы распознаем лермонтовскую раннюю поэтическую зрелость и страсть, пушкинскую широту интересов, многожанровость, качества журнального бойца, горьковский склад характера, – имея за плечами только медресе, поэт самообразованием сумел подняться до уровня передовых умов России того времени.

Творчество Тукая, поднявшееся на гребне революционной волны 1905 года, до последней строки пронизано идеей служения народу, обездоленным людям, чьи страдания поэт с детских лет познал на собственном жизненном опыте.

Отдать жизнь и талант своему народу, быть помянутым добром в народе, – вот в чем видел Тукай смысл существования и назначения поэта.

Тукай – первый истинно народный татарский поэт. Его огромная фигура возвышается в начале века у истоков новой современной татарской поэзии. Однажды в трудные часы, которых столько было в его жизни, он с горечью писал Ф.Амирхану: «Думаю, думаю и говорю себе: «Боже милостивый! Неужели пламень моего таланта, который я сохранил и пронес через свое сиротство, нищету, голод, сберег даже тогда, когда меня продавали из деревни в деревню, когда служил у бездушных татарских баев и гнил в татарском медресе, неужели он заглохнет?»

Нет, не угас пламень великого тукаевского таланта. Более того, спустя десятилетия он светит все ярче и ярче, и зажигает ответный огонь в человеческих душах далеко за пределами родного края».

ШАЛЯПИН И ТУКАЙ...

Я слушал оперу, сидя в гостях... Все партии пел один человек — сам создатель этого произведения, композитор, ныне уже покойный, Антон Александрович Эйхенвальд, народный артист Башкирской Автономной Республики. Оперу он создал по мотивам поэмы «Водяная ведьма» Г.Тукая.

Я увлёкся, слушая. Когда Антон Александрович захлопнул крышку рояля и заговорил, я в первый момент ничего не мог понять.

«Давно я собирался написать эту вещь, — рассказывал Эйхенвальд. — Ещё Шаляпин посоветовал. Я дал ему слово...»

Шаляпину? Как просто! Это, наверное, все одно что сказать, что он дал слово Пушкину, Глинке, Мусоргскому, Чайковскому. В моём воображении — они рядом.

Оговорюсь всё же: лично для меня Шаляпин не только реставрированные пластинки и не только портреты, сделанные рукой Нестерова или Кустодиева. Я слушал его в бывшем Михайловском театре в партии дона Базилио, видел его у нас дома, где он так же пел, и сам бывал у него на Петроградской стороне. Но впечатления-то в общем детские, несерьёзные. Да, но я могу сказать: видел, слышал. И всё одно это почти невероятно, как сон, как море, мелькнувшее под крылом самолёта. Много было людей, блеснувших чем-то, но едва скрылись, даже отблеска от их былой славы не осталось. А Шаляпин... Время не удалило его. Напротив, ещё величественнее с годами стало его имя. И потому, наверное, было мне так странно, когда рядом со мною сидящий человек запросто вспоминал свои последние встречи во Франции с Шаляпиным.

«Ты, Антоша, оркестровал бы для меня старинные русские песни, — попросил Эйхенвальда Шаляпин. — Хочу с хором напеть для пластинки».

Эйхенвальд, разумеется, дал своё согласие.

Шаляпин вздохнул и задумался. Потом заговорил:

«Встретил я в Казани замечательного человека. Когда это было? Двадцать или двадцать пять лет тому назад? Я сейчас так отчётливо себе его представил...»

Разговор происходил в кафе. Шаляпин схватил меню и тут же карандашом нарисовал молодого татарина.

«Правда, на Лермонтова похож? Только в татарской аранжировке. Писал стихи: «...Как Аллаха ни хвали, он выше всех похвал. И благодать он даровал и подать даровал». Ещё помню: «Скупимся с бедным говорить, будь он мудрейшим

из людей, и сыплем, как цветы, слова перед богатым дураком...» Погиб в таком же почти мальчишеском возрасте, что и наш Михаил Юрьевич... — Шаляпин подправил рисунок. — Нет, не сумел я передать его лицо, прозрачное, совсем детское. А какие у него были глаза, какие глаза, Антон! Мудрые... И совсем стариковские... утяжелённые. Он, наверное, мог сказать словами Лермонтова: «Небо учило меня любить, люди — ненавидеть»...»

На лице Шаляпина вдруг вспыхнула улыбка.

«Ты жил в Одессе, знаешь, наверное, как там называли чаек?» — спросил он.

«Мартынами».

«Верно. Но, собственно, мартыны — только одна из множества пород чаек. Ну а одесситы всех подряд так окрестили. Я иногда представляю себе мартына в железной клетке: неужели никогда не полетит над морем, не коснётся он крылом лихой волны, не окликнет другого мартына и вместе со многими своими друзьями в весёлом воздушном хороводе не закружится? Вот таким мартыном видится мне тот татарин поэт. Тоска тяжёлым булыжником легла в его душу. Жаль, забыл, начисто забыл его имя».

Эйхенвальд давно уже догадался, о ком ведёт речь Фёдор Иванович, молчал из деликатности. Да и оторваться от голоса Шаляпина было невозможно.

«Тукай», — ответил он.

«Тукай, Тукай!» Совершенно верно», — обрадовался Шаляпин.

«Мы под Казанью в лесу познакомились, — рассказывал Эйхенвальд. — Была оттепель, испарина. Мы бросали воробьям крошки хлеба. Подружились несмотря на разницу в возрасте. Я был старше. Часто мы вдвоём ходили по татарским деревням. Он помогал мне записывать песни. Объяснял крестьянам, зачем я делаю эту работу».

Эйхенвальд на память прочитал стихи Тукая. Тогда именно Шаляпин и посоветовал ему написать оперу по мотивам поэмы «Водяная ведьма»[1].

Л.Рубинштейн
(«Дружба народов», №9, 1969)

Николай ДОРИЗО (1923-2011):

«Чем является Пушкин для русской литературы, Тукай стал для татарской. И близость их гораздо глубже, чем это может показаться на первый взгляд.

Мы называем Пушкина великим национальным гением, при этом подчеркивая, что, будучи в первую очередь глубоко русским явлением, его поэзия стала достоянием мировой культуры, приобрела интернациональное звучание. То же самое с полной ответственностью можно сказать и о поэзии Тукая.

Как и русские классики, Тукай для своего народа больше, чем поэт. Он стал явлением не только литературы, но и всей национальной культуры, дав толчок развитию всех искусств – татарской музыки, живописи, театра. Все творчество Г.Тукая преисполнено чувством великой любви к своему народу. И поэтому почти каждая строка поэта источает боль, ибо любить для него означало говорить

[1] Партитура этой оперы после смерти композитора передана вместе с партитурами опер «Ашказар», «Мэргэн», «Степь» (ставились в Уфе в Государственном театре оперы и балета, а «Степь» шла также в Казани) в музей имени Глинки.

правду, сколь бы горькой она ни была. Тукай умер не от туберкулеза, он сгорел так рано именно от боли за свой народ, который ему так и не довелось увидеть свободным.

* * *

Тукай родился тогда, когда ему нужно было родиться, когда история велела ему родиться. Как рождаются только великие поэты».

Олжас СУЛЕЙМАНОВ (1936):

«Казань издавна волновала воображение степного края своим сложным и красочным духовным образом, неотъемлемой частью которого стала в начале века поэзия Габдуллы Тукая.

В девятнадцатом столетии, когда поднималась, крепла демократическая культура татарского народа, Казань стала одним из мест притяжения мыслей и чувств казаха. В Казани печатались первые произведения многих казахских писателей. Первая книга Абая на родном языке была издана в Казани. Татарская литература читалась в Казахстане без перевода. И ее проникающее, животворящее влияние – закономерно. Когда мы недавно отметили 90-летие со дня рождения основоположников советской казахской поэзии Сакена Сейфуллина, Ильяса Джапсугурова, Султанмахмута Торайгырова, мы подчеркивали, какое сильное воздействие на их творчество, особенно в начальный период, оказала лира Тукая, стихи которого они знали наизусть.

Многие из нас, и я в том числе, могут сказать: в багаже наших умственных, душевных накоплений есть доля Тукая, есть доля татарской культуры».

Нәкый ИСӘНБӘТ (1899-1992):

«Тукай турында сөйләгәндә, аны Пушкин белән чагыштырырга һәм аны татарның Пушкины дип атарга яраталар. Турыдан-туры мәгънәдә булмаса, бу чыннан да шулай. Чөнки Пушкин рус поэзиясенә нигез салса, Тукай татарның яңа шигъриятен тудыра.

***

Мәгълүм булганча, Пушкинның әдәби мирасы һәрьяклап тулысынча өйрәнелгән, тикшерелгән, барланган, хәтта аның әсәрләренең сүзлекләренә хәтле бар. Бу хакта борчылмаска мөмкин. Ә менә Тукайга килгәндә, моны әйтеп булмый. Тукай теле хакында...»

***

Белгәнебезчә, Тукайның «Мөхәммәдия» дәвере, ягъни борынгы китаплардагычарак югары стильдә гарәп, фарсы сүзләрен мул кулланып иҗат иткән чоры бар. Ул чорда язылган әсәрләре шактыйга җыела, алар күп, алар – шагыйрьнең мирасы. Бу әсәрләрне мин бик җиңел укыйм, хәтта күбесен күңелдән, яттан да сөйләп бирә алам, чөнки мин – Тукайның замандашы. Ә менә хәзерге яшьләр, балаларыбыз, Тукайның бу телен аңлый, үзләштерә алырмы? Алсалар, ни дәрәҗәдә? Әйтерләр:

«Нигә кирәк ул? Тукай үзе дә, бу телдән ваз кичеп, чын татарча яза башлаган бит», – диярләр. Шулай. Ләкин хикмәт нәрсәдә? Хикмәт шунда: Тукайга, бүгенге әдәби телнең нигезен салу өчен, элеккеге әдәби телне, аның традицияләрен ныклап өйрәнергә, иҗади үзләштерергә кирәк булган. Тукайның «галибанә яктырып ал таң ата» дигән фәкать бер шигырь юлы да бу фикерне раслый булса кирәк».

Мостай КӘРИМ (1919-2005):

«Татар әдәбиятының бәхете булып, дөнья әдәбиятының шатлыгы булып 1886 елны бу фани дөньяга Габдулла Тукай килде. Үз милләтенең гасырларга сузылган газапларыннан һәм өметләреннән, моңнарыннан һәм ырымнарыннан, кан катыш туфракта, изге җирлектә яралды ул. Язмыш аңа бер генә чеметем, бер генә мизгел гомер бирде. Шул ара эчендә ул Россиядә үзен дә, сүзен дә үлемсез итте. Алай гына да түгел, аның исеме һәм даны ил чикләрен узып чыкты. Көнбатыштагы караимнәрдән алып көнчыгыштагы уйгырларга хәтле барып җитте. Тукайны мин XX гасырда төрки телләрдә иҗат иткән иң бөек шагыйрьләрнең берсе, дияр идем. Аның янәшәсенә, ихтимал, Назыйм Хикмәтне генә куеп буладыр.

Тукай дигән могҗизаның төп сере нәрсәдә соң? Тукай дигән могҗизаның төп сере шунда, ул үзенең бөек талантын дөнья мәдәниятенең казанышлары белән баета алды. Шул талантка, байлыкка баш булып, аны халык тормышының, заманның иң төп, иң олы юлы белән алып китте, алсыз-ялсыз хезмәт иттерде. Аны үз-үзенә соклану яки кызык өчен генә сүз уйнату кебек буш, мәгънәсез нәрсәләргә исраф кылмады. Әйтер сүзен ул кешеләр башы өстеннән зәңгәр бушлыкларга карап әйтмәде, ә замандашларының, кан кардәшләренең мөлдерәмә хәсрәт һәм өмет тулы күзләренә туп-туры карап әйтте».

Гали АКЫШ (1918-2011):

«15 апрель көнне һәр ел саен, хәтерем ялгышмаса, 1920 еллардан бирле йола белән уздырабыз. 15 апрель — олы даһи шагыйребезнең үлгән көне булу сәбәпле, Тукайны искә алабыз. Мондый чараларның ватаныбызда да уздырылуын чын күңелдән телибез.

Тукай — безнең өчен Пушкин, Байрон, Шекспир, Гете, Мицкевич, Намик, Кәмаллар дәрәҗәсендәге олы шагыйрь һәм философ. Мисал өчен балалар әдәбиятын гына алыйк: Тукаебызның әдәби энҗеләре — «Су анасы», «Шүрәле», «Кисекбаш» поэмалары, «Эш беткәч, уйнарга ярый», «Тынма, эшлә» шигырьләре, «Кәҗә белән сарык» әкияте, «Өзелгән өмид» шигырьләре — шедевр».

Нажар НӘҖМИ (1918-1999) :

«Без, һич шикләнмичә, — Тукайга кадәрге һәм аннан соңгы дөнья, дип хаклы рәвештә әйтә алабыз. Без аның шигърият кояшы астында туганыбыз белән бәхетле.



Кешелек дөньясында төрле гаҗәеп ачышлар ясалган. Фәнни фикер көче фәнни закончалык көчләренә нигезләнгән. Мәсәлән, әгәр Ньютон җирнең тарту көче законын ачмаган булса, аны, берсүзсез, башка берәү ачар иде. Әмма әдәбиятта, сәнгатьтә андый закончалык юк. Пушкин язганны бары тик Пушкин гына яза алыр иде. Тукай язганны Тукайдан башка һичкем яза алмас.

Габдулла Тукай иҗаты шуның кадәр намуслылык һәм гаделлек, кыюлык һәм килешмәүчәнлек, үткенлек, шат күңеллелек һәм, шул ук вакытта һәрнәрсәдән канәгатьсез калу хисләре белән тулган ки, хәтта бер кешенең җаны шуның кадәрне ничек сыйдырганын күз алдына китерү дә авыр. Тукай — тормышның үзе кебек катлаулы. Бу бөтен нәрсәдә сизелә — аның шигырьләрендә, публицистик мәкаләләрендә һәм әдәби осталыкка багышланган тәнкыйди язмаларында, сәяси памфлетларында да.

Мин Тукай турында яңа фикерләр әйтмим, ә үземне аның укучысы итеп исәпләгәнгә, күңел түрендәгеләр белән генә уртаклашам. Мине һәрвакыт сокландырганы һәм Тукай алдында хәзер дә тез чүктергән нәрсә — ул аның үзен җиңелгән дип хис иткәндә дә дөреслекнең күзләренә туры карый белүе...

Тукайның соңгы шигырьләреннән берсен, — гомер белән аерылышу вакыты килеп җитүен сизенеп, сазы бик аз уйнавы, җаны сүнә баруы турында язган шигырен укыганда йөрәк әрни. Тукай соңгы юлларны бик сагышлы тәмамлый: җанының җылысы кабер ташына китсен, иң ачы һәм иң баллы күз яшьләре шунда тамсын... Нәрсә бу? Йөрәк сызлавымы, яралы кош авазымы? Әйтүе кыен. Хәзер, Тукай гомеренең һәр елын анализлап, аның баш өстендә нинди яшеннәр яшьнәвен, нинди күкрәүләр яңгыравын күз алдына китерергә мөмкин. Әмма, әгәр Тукай «Шүрәле»не, «Су анасы»н һәм «Яңа Кисекбаш»ны язмыйча, бары тик шушы шигырен генә иҗат иткән булса да, ул безнең хәтердә калачак иде.

Тукайга пессимистлык ят булган. Тукайның: «Мин дипломат» дигән сүзләрен, шагыйрь компромисс, килешү мөмкинлегенә юл куйган, дип аңларга кирәкми, бу сүзләр — ул үз халкының мәнфәгатен белдерүче вәкил дигәнне аңлата. Тукайның бөтен иҗаты дөнья язмышы, милләт язмышы турында уйлану белән тулы. Тормыштагы мохтаҗлык һәм авырлыкларга, кайвакыт шагыйрьне биләп алган күңел төшенкелегенә карамастан, аның тәүге һәм соңгы юлларына кадәр барысы оптимистлык, халыкка ышаныч белән сугарылган.

Тукай җыр белән үләчәкмен, фәрештәләрне күргәндә дәшми калмамын, дип юкка гына әйтмәгән. «Без китәбез, сез каласыз...» дип җырларга вәгъдә иткән. Тукайның гомере бер мизгел кебек үтә. Аңа бирелгән вакыт бик кыска була, әмма ул туктаусыз эшчәнлектә уза. Һәм бу эшчәнлеге үзенең җимешләрен бирде. Тукай һәм аның поэзиясе — мәңгелек хәрәкәттә».



Сәгыйть СҮНЧӘЛӘЙ (1889-1937)

«Тукай куәтле иде... Нинди козырьлар алдында да «мин»леген кимсетми, горурын, гыйззәте нәфсен җуймый иде. Ул дәүләтле кешеләргә түбәнтен югары карамый иде...

Тукай башта ук оста язды. Аның искерәк шивә белән язган шигырьләре дә шаян дикъкать бит! Тукай газиз телебезгә шактый нык нигез салып куйды».

Педер ХУЗАНГАЙ (1907-1970):

«Халыкларның тарихи язмышлары төрлечә булган кебек, аларның кешелек культура хәзинәсенә керткән өлешләре дә төрлечә. Ләкин шунысы бәхәссез: һәр халык өчен уртак, интернациональ мирасны бары тик тирән һәм милли үзенчәлеккә ия булган иҗат үрнәкләре генә баета ала. Беренче карашка сәеррәк булып яңгыраган бу төшенчәнең үз диалектикасы бар. Моның шулай икәнлеге дөньякүләм культураның үсеш юлы белән исбат ителә. Гомер һәм Данте, Руставели һәм Нәваи, Низами һәм Кол Гали, Шекспир һәм Сервантес, Пушкин һәм Шевченко барыбызга да шуның өчен кадерле, аларның һәркайсы безнең көннәргә үз халыкларының тарихын, язмышын, омтылышларын чагылдыручы буларак килеп җиткән.

Татар шагыйре Габдулла Тукай һәм чуваш шагыйре Константин Иванов (1890–1915) беренче рус революциясе һәм халыкларыбызның милли азатлык хәрәкәте дулкынында күтәрелеп чыктылар. Аларның иҗатында, революция тарафыннан уятылып, соңыннан кара реакция көчләре тарафыннан рәхимсез рәвештә бастырылган чордашларының теләк һәм омтылышлары шактый тулы сурәтләнде. Алар үз милләтләренең йокыдан уянуын башлап хәбәр итүчеләр булдылар, бу уянуның төп чагылышын туган телдә күрделәр һәм шул чагылышны иҗатларында зур осталык белән яктырттылар.

Безгә Ивановның Тукай турында нинди дә булса фикер әйткәнлеге билгеле түгел: шагыйрьнең күп кенә кульязмалары безнең көннәргә кадәр сакланмаган. Казанда яшәгән Тукайның Сембердәге тугандашы Константин Иванов хакында ишетүен яки ишетмәвен без шулай ук белмибез. Ләкин аларның язмышлары уртак булды: икесе дә кара реакция елларындагы иң авыр шартларда яшәделәр; икесе дә ялкынлы иҗат учагында янып беттеләр; икесенең дә гомерен үпкә авыруы кисте. Алдынгы карашлы рус кешеләре тарафыннан «халыклар төрмәсе» дип тамгаланган патша Россиясендә күпчелек талантларның язмышы әнә шундый иде.

Мин үзем Тукайны беренче тапкыр П.Радимов тәрҗемәсендә укыдым. Ләкин миңа «Шагыйрь» исемле шигырьнең чувашча тәрҗемәсе ныграк тәэсир итте. Бу шигырь матбугатта безнең шагыйрь С.Чегесь тәрҗемәсендә 20 нче еллар башында басылып чыккан иде. Мин шушы көнгә кадәр ул шигырьне сүзен сүзгә диярлек яттан беләм. Бу шедеврның соңгы ике юлы минем күңелдә искиткеч югары гуманистик һәм көчле аккорд булып яңгырый:

«Без китәбез, сез каласыз!» – дип җырлармын
Җәсәдемне туфрак белән күмгәндә дә.

Бу оптимизм, яшәүнең үлем өстеннән тантана итүе минем аңымны киңәйтеп, күңелемдәге иҗат тойгысын көчәйтеп, тормыштагы урынымны билгеләде».

МОТЫЙГУЛЛА, МӨХӘММӘТГАРИФ ҺӘМ ГАБДУЛЛА

Әгъзам Фәйзрахманов

Һәрбер халык кайчан да булса үз шагыйрен тудыра, диләр. Бу уңайдан гадәттә конкрет мисаллар да китерелә. Борынгы Грециядә – Гомер, Италиядә – Данте, Англиядә – Шекспир, Германиядә – Гёте, Казакъстанда – Абай, Грузиядә – Руставели, Россиядә – Пушкин. Татар халкы өчен Тукай шундый шагыйрь булды. Нәкъ менә Тукай иҗатында татар халкының күп гасырлар дәвамында туплана килеп тә, әлегәчә мәйданга чыга алмый яткан рухи тәҗрибәсе, зур потенциаль мөмкинлекләре чын мәгънәсендә гәүдәләнеш таба, тормышка аша башлый. Аның шигърияте халык күңеле белән бердәм рәвештә яңгырады.

Габдулла Тукайның шигырь турында беренче белемне Мотыйгулла Төхфәтуллиннан алуы мәгълүм. Әмма Апушның шагыйрь булып китүенә этәргеч ясаган бу игелекле затның эшчәнлеге тиешенчә өйрәнелмәгән, Тукай иҗаты белән шөгыльләнүчеләр дә ни өчендер аны читләтеп үтәләр[1]. Шунлыктан, Мотыйгулла турында кайбер фактларны укучылар игътибарына җиткерү урынлы булыр. Татарстан Милли архивында сакланачы тугызынчы (1850) һәм унынчы (1858) ревизия материалларыннан күренгәнчә, 1844 елның ноябрь аенда дөньяга килгән. Әтисе — Төхфәтулла Нигъмәтуллин, әнисе — Сәрбиҗамал Минкина. Аларның өч уллары һәм ике кызлары булуы билгеле.

Тарихтан мәгълүм ки, Мотыйгулла туу белән әнисе үлә, ә бераздан әтисе дә үлеп киткәч, апасы тәрбиясендә кала. Мотыйгулла яшьтән үк зирәк, зиһенле була. Инде биш яшендә кешеләрне таң калдырырлык итеп Коръән аятьләрен укый, шуңа күрә аны «могҗизалы» бала дип атаганнар. Әтисе урынына килгән мулла, Мотыйгулланы тыңлап караганнан соң, соклануын белдерә һәм ул заманда иң данлыклы саналган Кышкар мәдрәсәсенә укырга җибәрә. Бу мәдәрәсәдә Кушлавыч авылыннан килгән, киләчәктә Габдулла Тукайның әтисе булачак Мөхәммәтгариф дигән шәкерт тә укый. Мотыйгулла белән Мөхәммәтгариф тиз арада дуслашып китәләр. Мотыйгулла ятим бала булганлыктан, Мөхәммәтгариф аны үз химаясенә ала, алар бергә яшиләр,

[1] Фоат Галимуллинның «Талантлар арасында» (урысчасы — «В созвездии талантов») дип аталган документаль повестенда Мотыйгулла хәзрәт хакында гаять тәфсилле бәян ителә — Ред.

«Габдулла Тукай һәм аның мөгаллиме, остазы Мотыйгулла Төхфәтуллин». Рәссам Ильяс Айдаров. 2006

бергә укыйлар. Укып бетергәч тә аерылмаска сүз куешалар.

Мәдрәсә тәмамлауга, Мөхәммәтгарифны туган җире Кушлавычка мулла итеп билгелиләр. Ә Мотыйгулла, укуын дәвам итү өчен XIX йөзнең икенче яртысында ислам дөньясының гыйлем учагына әверелгән Мисырның әл-Әзһәр университетына укырга китә һәм 1868-1874 елларда шул уку йортында белем ала. Укуын тәмамлап кайтканда, Мотыйгулла Җаек (Уральски) шәһәрендә яшәүче апасы янында туктала. Мәчеткә намазга баргач, Каһирәдә белем алып кайткан бу кешенең Коръән укуын сорыйлар. Намазда катнашучылар аның укымышлылыгына исләре китә һәм мәхәллә кешеләре аның Түбән оч мәчетенә мулла булып калуын сорыйлар. Мәчетне салдырган Гани бай Мотыйгуллага үзенең төскә бик матур, уналты яшьлек Гыйззеназ исемле асрау кызын кияүгә бирә. Мотыйгулла хәзрәтнең унбиш баласы була, ләкин аларның сигезе яшьли үлә.

Хәзрәт М.Төхфәтуллин, Җаек шәһәре мәчетендә мулла булу белән бергәттән, XIX йөзнең 70 еллар ахырында «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә дә нигез сала. Бу уку йорты XX йөз башында, нигездә,

www.gabdullatukay.ru сайтыннан алынды

Бу таш йортта Кызыл мәчет имамы, «Мотыйгия» мәдрәсәсе мөдәррисе Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин гаиләсе яшәгән. 2006 елда Уральскиның татар җәмәгатьчелеге бу йортны үз көчләре белән төзекләндереп, биредә Габдулла Тукай музее ачалар. 2010 ел

кадими мәдрәсә саналса да, өлешчә генә уку-укыту реформасы үткәрелеп, башкалардан хөр фикерлелеге белән аерылып торган. Габдулла Кариев үзенең истәлекләрендә (Г.Кариев. «Тукай турында хатирәләр». Казан. 1976, 43 нче бит) *«Дамелла Мотыйгулла хәзрәт Мисырда укыган бер галим фазыйль (башкалардан аерылып торучы) кеше булганлыктан, алар мәдрәсәсендә башка мәдрәсәләрдәге кебек вак-төяк кыенлыклар булмый иде. Ул заманда иң хөр мәдрәсә — алар мәдрәсәсе иде»*, — дип яза.

Шәхсән үзем «Мотыйгия» мәдрәсәсен кадими уку йорты булган, дигән фикер белән килешә алмыйм. Кадими дип исәпләнгән мәдрәсәнең җитәкчесе дә кадими караштa була бит инде. Әмма дә Мотыйгулла хәзрәтнең алдынгы карашлы кеше булуы бәхәссез. Хәзрәт мәдәният, әдәбият, сәнгать белән даими кызыксынып яшәгән. Гарәп телендәге «Траблис», Кырымда һәм Тифлиста чыга торган «Тәрҗеман», Шәркый рус» газеталарын алдырган, бай китапханәсе булган. Йортта рояль торган, сабыйлар нота укырга, җырларга өйрәнгән. Балалары Камил Мотыйгый һәм Галия Кайбицкаяны гына телгә алсак та, аларның үз чоры өчен алдынгы карашлы, җәмгыятьнең үзәгендә кайнаучы шәхесләр икәнен күрәбез. Камил Мотыйгыйның соңыннан популяр җырчы булып китүе, татар операсында үзәк партияләрне башкарган Галия Мотыйгулла кызы Кайбицкаяның шушы гаиләдән чыгуы очраклы хәл түгел. М.Төхфәтуллинның тагын бер кызы — мәгърифәтчелек рухында язучы шагыйрә Әминә Төхфәтуллинаны да атап китәргә мөмкин. «Сөембикә» журналында аның шигырьләре күп басылган. Мотыйгулла хәзрәт, ир балалар белән беррәттән, кызлар өчен дә мәктәп ачкан кеше. Аның «Шура» журналында һәм «Вакыт» газетасы битләрендә дин гыйлеме мәсьәләләренә багышланган берничә мәкаләсе дөнья күрә. Аларның берсе бераз кыскартылып, тарих фәннәре кандидаты Рафилә Гыймазова тарафыннан текстологик яктан эшкәртелеп, «Гасырлар авазы» журналында басылып чыкты (2008 ел, №2). Мәкалә «Коръәни кәрим тәрҗемәсе хакында» дип атала.

ШАГЫЙРЬНЕҢ БЕРЕНЧЕ УКЫТУЧЫСЫ

Еллар үтеп, Мөхәммәтгариф вафат булгач, аның ятим калган улы Габдулланы апасы Газизә һәм җизнәсе — Арча төбәгеннән чыккан сәүдәгәр Галиәсгар Госманов үзләре янына Җаекка алдыра, «Мотыйгия» мәдрәсәсенә укырга бирә. Г.Тукаевның кем баласы икәнен белүгә үк Мотыйгулла хәзрәт аны үз

Мотыйгулла Төхфәтуллин. XX гасыр башы

Гыйззеназ Төхфәтуллина. XX гасыр башы

өенә алып кайта. Габдуллага әтисе Мөхәммәтгариф турында: *«Синең әтиең мәдрәсәдә мине бик карады, якын итте. Бәйрәмнәрдә мине үзе белән гел Кушлавычка алып кайта иде. Синең дәү әниең безнең кайтуыбызны тәмле ашлар пешереп көтеп тора иде»*, — дип сөйли.

Мотыйгулла үзенең хатыны Гыйззеназга: *«Габдулла ятим бала, аны кара. Аның әтисе, әби-бабасы мине бик тәрбия итте»*, — ди. Кече улы тугач, Мотыйгулла үзенең мәрхүм дусты истәлегенә аңа Мөхәммәтгариф дип исем куша.

Габдулла мәдрәсәдә вакытын бушка үткәрми, тырышып укый. Г.Кариев үзенең истәлекләрендә: *«Габдулла әфәнде гомуми дәрескә дамелла Мотыйгулла хәзрәткә утырадыр иде. Габдулла әфәнде мәдрәсәдә иң галим, иң үткен, иң зирәк шәкертләрдән хисапланды»*, — дип яза.

Тукай Җаекка килгән елны ук җизнәсе Галиәсгар Госманов, Россиядә яшәгән кеше урыс телен дә үзләштерергә тиеш, дигән караштан чыгып, каенэнесен өч сыйныфлы рус мәктәбенә укырга бирә. Бу мәктәпне дә Габдулланың уңышлы тәмамлавы мәгълүм. Мәдрәсәдә укыткан хәлфәсе Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин истәлекләреннән күренгәнчә, Тукай «Әхмәтша учитель» китапханәсеннән Пушкин, Лермонтов, Крылов һәм башка рус әдипләре әсәрләрен алып укырга яраткан.

Каһирәдә белем алып кайткан ата-лы-уллы Мотыйгулла һәм Камил Төхфәтуллиннарның «Мотыйгыя» мәдрәсәсе тирә-як өчен зур мәдәни мәркәз булып әверелә. Мәдрәсәнең югары сыйныфларында көнчыгыш телләре һәм дини тәгълиматтан тыш, тарих, мантыйк, әдәбият һәм шигърият белемнәре дә өйрәтелә. Әбугалисина кебек шәхесләргә табынган Гомәр Хәйямны, Нәваины яттан белгән, төрки һәм көнчыгыш халыкларының әдәбиятын җентекләп үзләштергән Мотыйгулла хәзрәт тарих һәм әдәбият фәннәрен мәдрәсәдә үзе укыта.

Бу мәдрәсәдә шәкертләргә карата тән җәзасы бөтенләй кулланылмаган. Менә шуңа күрә мәдрәсә диварларында кульязма газета-журналлар чыгуы,

аларда шәкертләр тарафыннан язылган парчалар, хикәяләр басылуы табигый бер күренешкә әверелә. Аларда шәкерт Габдулла Тукаев язмалары да басылгандыр, дип уйларга тулы нигез бар. Истәлекләрдән күренгәнчә, әлеге мәдрәсәдә Мотыйгулла хәзрәт алдынгырак карашлы шәкертләргә шәрыкнең бөек шагыйрьләре әсәрләре турында да сөйләгән, шигырь төзелешенә кагылышлы дәресләр дә биргән. Шулай итеп, Габдулла Тукай шигырь төзелеше турындагы беренче белемне остазы Мотыйгулла Төхфәтуллиннан ала. *«Габдулла Тукаев Мотыйгулла хәзрәтнең гыйльме гаруз (шигырь төзелеше хакындагы белем) дәресләренә бик иҗтиһад белән йөрде»*, — дип яза Камил Төхфәтуллин үзенең истәлекләрендә.

Ничектер шулай килеп чыкты, үткән гасырның 70 нче елларында мин Камилнең улы Хәмит Төхфәтуллин белән нык аралашып яшәдем, хәтта дуслашып киттек, дияргә дә була. Ул минем эш урыныма — телевидениегә еш килеп йөри башлады. Без кичләрен, эштән соң аның белән җыр сәнгате турында әңгәмә корырга ярата идек. Фатирында очрашканда да, гадәттә, ул мине берничә җыр тыңлатмыйча җибәрми иде. Хәмит ата-бабасының «Мотыйгыя» мәдрәсәсендәге эшчәнлеге турында тәфсилләп сөйләргә яратмады. Чөнки ул чорда туган-тумачаның мулла булуы, дин сабагы укытуы хакында сөйләмәвең хәерлерәк иде. Шулай да Хәмитнең бабасының да, әтисенең дә Тукай белән аралашып яшәве, аңа һәрдаим ярдәм итүләре турында сөйләве хәтердә сакланып калган.

Тукай иҗатын өйрәнүчеләр шагыйрьнең башлангыч чор әсәрләрендә гарәп-фарсы сүзләренең шактый еш очравын искәртә. Мин монда да Габдуллага бу телләрне Мисырда яшәп, ныклап өйрәнеп кайткан Төхфәтуллиннарның йогынтысы булгандыр, дип саныйм. Укытучы укучысы өчен һәрьяктан үрнәк булып тора бит инде ул.

СЕРЛЕ ТУКАЙ

Гадәттә, кешенең табигате турында сүз йөрткәндә, ул аның асылы, эшчәнлеге белән билгеләнә, диләр. Җаекта яшәгәндә үк 18-19 яшьлек егет — Габдулла Тукаев үзен таныта, шәхес буларак, халыкның рухи дөньясында урынын билгели алган. Шагыйрь халкына үз сүзен турыдан-туры әйткән. Аның күңеле өчен мондый хәл бик тә табигый күренеш булса кирәк. Тукайны бу эшкә беркем дә өйрәтмәгән, ул үз аңы, үз акылы белән шушы юлга басарга җөрьәт иткән. Философия фәннәре кандидаты Ил Саттаров (күренекле татар шагыйре Рәхим Саттарның улы) мондый юлны пәйгамбәрлек юлы, дип атады. *«Кешелек вакыт-вакыт үзенә пәйгамбәрләрне булдыра. Бу — табигый хәл. Тукайның пәйгамбәрләр юлына басуының сәбәбе аның язмышыннан киләдер. Өч яшьтән ятим калганга, кулдан-кулга йөреп үскәнгә, аны халык үстергән, дип әйтеп була, шуңа күрә дә аның күңеле-җаны иртә уяна, биеклеккә күтәрелә. Әгәр дә Тукай, әти-әнисе исән булып, тыныч кына мулла гаиләсендә үскән булса, аның җаны шулай уянып китәр идеме икән? Ул үзен халкы белән бердәм сизәр идеме икән? Үз көчеңне тою дигән нәрсә бар. Тукайның беренче шигырьләрен укыганда ук сизәсең — ул үзенең шагыйрь икәнлегенә бер дә шикләнми»*, — дип яза ул 2000 елда «Туры Тукайның серләре» дигән мәкаләсендә.

Фикерен дәлилләү өчен, И.Саттаров мисалга Тукайның басылып чыккан шигырьләренең беренчеләреннән саналган «Мужик йокысы» шигырен китерә:

...Тик яткач, Ходаем
Бирми мал сәбәпсез;
Бишмәтең таланган,
Күлмәгең сәдәпсез.

Хак сүзне әйткәнгә
Киң күңелең тарайса,
Урыныңнан кузгалма,
Йоклый күр, алайса.

Беренче карашка гап-гади сүзләр. Әмма алар һәркемне үзенең бүгенге хәле, язмышы турында уйланырга, башкалардан калышмаска, тулы канлы тормыш белән яшәргә этәрә. Күрәсең, холкы шундый булгандыр, Тукай яшьтән үк халкы алдында үз урынын билгеләргә тырыша. Көчен сизеп, халык алдында торган мәсьәләләрне хәл итәргә керешә. Бу уңайдан 1906 елда «Әлгасрел-җәдит» журналында басылган «Үз-үземә» шигыреннән берничә юлны китереп үтик:

Телим булырга мин инсане гали,
Тели күңелем тәгали биттәвали.
Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вакытын татарның.
Татар бәхете өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә — чын татармын.

Менә шулай шагыйрь турыдан-туры халкы белән әңгәмә кора. Ул чорда мәдәниятебезнең артта калуына, татарлар арасында инженерларның, табибларның, галимнәрнең бик аз булуына борчыла. Болай уйлау, үз алдыңа милләтне күтәрү максатын кую өчен, әлбәттә инде, үз-үзеңә ныклы ышаныч белән бергә, кыюлык та кирәк. «Тели күңелем тәгали биттәвали» — күңелем бертуктаусыз югарылыкка күтәрелүне тели, дигән сүзләр бу. Халкы белән үзен бердәм тоеп, милләтне күтәрү өчен җиң сызганып көрәшергә өндәгән шагыйрьләр, мөгаен, тарихта әллә ни күп тә түгелдер.

...И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк.
Башка милләтләр хәлен карап карыйк;
Мәдәният мәйданында урын алыйк,
Егыла-тора алга таба атлыйк, имди.
(«Дусларга бер сүз», 1905 ел).

1905-1906 елларда язган шигырьләрен укыганда шагыйрьнең үз юлы, вазифасы һәм үз өстенә алган бурычлары турында җитди уйланганы сизелә. Күрәсең, шунлыктандыр, Тукай яшәгән чорларда ук халык аны үз итеп яраткан һәм татар халкы гына түгел, барлык төрки халыклар да. Казакъ язучысы Сабит Муканов Казанга Тукайның сиксән еллыгына багышланган фәнни конференциягә килгәч, үзенең чыгышында: *«Алма-Атада фатирымда китапханәм бар. Ул байтак зур, дип әйтер идем. Шул китаплар арасында бик тә затлылары бар. Ләкин иң кадерлесе кечкенә генә кәгазь тышлы, әтинең юртасыннан калган бер китап — Тукайның Бөек Октябрь революциясенә кадәр Казанда басылып чыккан шигырьләр җыентыгы. Безнең гасыр башында һәр төрки халыкның үзенең танылган, яраткан шагыйре булган. Ләкин шул чорда үз итеп бар төрки халыклар Тукайны белгән, хөрмәтләгән»*, — дигән иде.

Тиздән Тукайның тууына 130 ел тула. Аның вафат булуына да инде йөз елдан артык гомер үтте. Казанда һәм шагыйрьнең туган төбәге Арчада үтәчәк чараларда төрле төбәкләрдән кунаклар катнашыр дип көтелә. Бөек якташыбызның юбилее уңаеннан әллә ни зур булмаган өй-фатир шартларында да кулланырлык портретын һәм иң популяр әсәрләреннән торган китабын чыгарасы иде. Юбилейга кадәр моны әзерләп булмаса да, артык борчылырга кирәкми. Аларны чыгаруны бик озакка сузмыйча, кунакханәләргә сатуга куйганда, аларны истәлеккә үзләре белән алып китәргә теләүчеләр аз булмас, дип уйлыйм. Тукайның портреты өйләрендә булмаган язучылар Татарстанда да аз түгел бит. Күпчелек җитәкчеләрнең эш бүлмәләрендә дә юк ул. Казанда илкүләм чаралар даими үткәрелә. Соңгы вакытта туристлар агымы да артты. Кунакларның һәркайсы үзе белән ниндидер сувенир алып китәргә тырыша. Тукайның портреты һәм бу максаттан махсус чыгарылган китабы иң яхшы сувенир булыр иде.

26 гыйнвар, 2016 ел ■

УФА ДА ТУКАЙ ЭЗЛӘРЕН САКЛЫЙ

Фәнис Фәтхи

Башкортстан башкаласы Уфа шәһәрендә дә быел халкыбызның бөек улы, мәңге горурланып сөйләрлек олуг талант иясе Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулуга багышланган чаралар байтак оештырылачак. Башкортстан дәүләт университетында һәм Башкортстан дәүләт педагогия университетында, шулай ук Уфаның 65 нче һәм 84 нче санлы татар гимназияләрендә, гомум белем бирү катнаш мәктәпләренең татар сыйныфларында Г.Тукайга багышланган кичәләр оештыру каралган. Уфа татар милли оешмалары да кайбер мәдәни чараларны әзерләп тора.

Мәгълүм ки, Уфа шәһәре дә Габдулла Тукайның эзләрен саклый. Уфаның иң матур урынындагы урамга Габдулла Тукай исеме бирелгән. Бередә Башкортстан Республикасы башлыгы һәм хөкүмәте эш урыны булган Ак йорт та урнашкан. Шушы ук урамда, Хөкүмәт йортыннан бераз аска төшкәч, Әби патша заманында ук төзелгән борынгы Җамигь мәчете бар тирә-якны ямьләп тора. Бу үзе үк бөек Тукаебызның хәтерен саклаучы бер изге кальгә булып кабул ителә.

Габдулла Тукай Уфага беренче һәм соңгы тапкыр 1912 елда килә. Татарлар күпләп яшәгән, татар иҗади зыялылары бихисап булган, гөрләп эшләгән «Галия» мәдрәсәсе белән дан

алган Уфага гел тартыла ул. Әмма бирегә юллары вафатына бер ел калгач кына төшә. Анда да әле, кымыз белән дәвалану максатында, Троицк каласына сәфәр чыккач, юл уңаенда гына кебек килеп чыга.

Атаклы шагыйребезне үпкә чире тәмам йончыта башлагач, аңа кымыз эчеп дәвалануны киңәш итәләр. Казаннан март азагында чыгып китә ул Уфага. Апрельнең беренче көннәрендә килеп төшә. Алдан каршы алу өчен кемгә дә булса телеграмма йә хат юлламый Тукай, холкы андый түгел. Уфага килеп төшүен Тукай үзе болай сурәтли: «Менә Уфа. Тау башында тәртипсез таралып утырган. Извозчикка утырдым. Ләкин бу инде Самаранықы түгел иде. Арбасы шундый иске, шундый каты иде ки, эчәкләрем такта арбага буш салган дилбегә кеби, үрле-кырлы сикерә иде».

Озын юлда да арып-алҗып һәм өшеп килгән Г.Тукайны Уфада каршы алучы булмый. Чөнки үзе хәбәр итмәгәч, аның килүен белүче дә булмый. Шагыйрь, тимер юл вокзалыннан туры менүче урам буйлап өскә күтәрелгәч, хәзерге Карл Маркс белән Свердлов урамы чатындагы «Сабах» ширкәтенең китап кибете һәм китапханәсе урнашкан бинада ял итеп, чәй эчеп алырга туктала. Исәбе — аз гына хәл җыйгач, арзанлы һәм уңайлы гына бер кунакханә номерына урнашу. «Сабах» хезмәткәрләре Тукайны, вакытлыча, кибетнең арткы ягында келәт хезмәтен үти торган иркен урынга кертә, чәй тәкъдим итә, шунда китаплардан бушаган тартмалар ярдәмендә, ятак кебек нәрсә дә әтмәлләп бирә. Кайнар чәй эчеп, бераз йоклап, хәл җыеп алгач, Г.Тукайга бу урын ошап китә. Кунакханә номеры тәкъдим итсәләр дә, шушы гади генә почмакта калуны хуп күрә Казан кунагы.

Г.Тукайның Уфага килү хәбәре тиз тарала. Иң беренче булып аның янына инде танылып өлгергән шагыйрь Мәҗит Гафури килә. Беренче очрашулары бер-берсенә сынаулы карашлар белән, бик тыенкы һәм аз сүзле үтә. М.Гафури Казаннан килгән каләмдәшенә кайда да булса барып сөйләшеп утырырга тәкъдим ясый. Икенче-өченче көнне дә Мәҗит Гафури белән шәһәр әйләнәләр, ял бакчаларына кереп кымыз эчеп, гәпләшеп утыра ике әдип. Шулай якынаеп китәләр, сүзләре килешә, әдәбият, шигърият хакында рәхәтләнеп фикер алышалар. Әлбәттә, Г.Тукайны күрергә һәм аның белән сөйләшергә башка зыялылар да агыла. Гаҗәп тә түгел, һәммәсенең тере Тукайны күрәсе, аңа сүз катасы килә. Шулай Уфада берничә көн булганнан соң, Тукай Петербургка барып килү теләген әйтә. Төньяк башкалада ике атна булганнан соң, Г.Тукай янә дә Уфага әйләнеп килә. Юлда бик нык арыган шагыйрьгә биредә хәл алу өчен мөмкинлек була. Уфада бу вакытта бакчаларда агачлар яфрак ярган, җир өсте яшел хәтфә үләннәр белән капланган, тәмле, шифалы кымызлар әзерләнгән... Кымыз эчеп, бакчаларда саф һавада ял итү Тукайның сәламәтлеген кайтарган кебек була. Бакчада яшел үлән өстендә йоклап киткән чаклары да була аның.

Мәҗит Гафури хәтерләвенчә, Уфа җәмәгатьчелеге ул чакта, Тукайның дәрәҗәсенә туры килерлек олы хөрмәт күрсәтә алмый. «Тукайның Уфага килү хөрмәтенә һичбер мәҗлес-фәлән тәртип кылынмады. Аның Уфага килгәнен күп кеше белми дә калгандыр. Тукайның Уфада үткәргән ун-унбиш көн гомере «Сабах» көтебханәсе артындагы бүлмәдә үтте. Аның күңелен ачып, рухын күтәрерлек һичбер эш эшләнмәде. Бер гаиләдән башка, хосусый дәгъват итеп, күңелен ачучы булмады», — дип яза М.Гафури.

Уфа шәһәрендә яшәп, М.Гафури белән аралашып күңеле булгач, Г.Тукай, баштан ук үзе ниятләп чыккан Троицк каласына юллана. Шулай итеп, аның Уфа сәфәре тәмамлана. Уфада үзе булганда зурлап хөрмәтли алмасалар да, вафатының берьеллыгын билгеләгәндә, Уфа яшьләре «Ту-

кай кичәләре» оештыра, мәдәни чаралар үткәрә.

Башкортстан татар җәмәгатьчелеге милләтебезнең асыл улын онытмый. Аның хөрмәтенә апрель аенда төрле хәтер чаралары оештырыла. Галимнәребез Г.Тукайның тормышын һәм иҗат юлын өйрәнеп гыйльми хезмәтләр дә яза. Башкортстан дәүләт педагогия университеты профессоры Рәиф Әмиров та Г.Тукай иҗатын төпле өйрәнгән, гыйльми хезмәтләр язган галим. Рәиф Әмиров, 1990 нчы елларда «Мәгърифәт» фондын җитәкләгән чакта, Уфада 1912 елда Г. Тукай яшәп алган «Сабах» кибете һәм китапханәсе урнашкан бинага истәлек ташы урнаштыру өчен башлап йөрүче һәм бу эшкә зур тырышлыклар салган шәхес тә. Свердлов урамының 98 нче санлы йорты диварына истәлек тактасын башта республика рәсми даирәләре түгел, ә нәкъ менә Башкортстан татар иҗтимагый үзәге вәкилләре әзерли һәм аны татар телендә яза. Ул истәлек ташын урнаштыруга Уфадагы татар җәмәгатьчелеге, милләт зыялылары җыела. Искитмәле рухи күтәренкелек, зур канәгатьләнү кичерә милләттәшләр бу игелекле гамәлдән. Әмма хәтер ташының язмышы күңелсез булды. Аның татар телендә язылуы республиканың ул чактагы түрәләренең саруын кайнаткан булып чыкты. Шуңа күрә, өстән төшкән күрсәтмә белән, татарча язылган истәлек ташы алып ташланды һәм анда башкорт телендә язылганы менеп кунаклады. 1996 елның 22 апрелендә республиканың рәсми затлары да катнашкан чарада беркетелде башкорт телендәге хәтер ташы-тактасы. Сез аны фотосурәттә күрәсез. Шулай итеп, Габдулла Тукай истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләсе дә гарип милли сәясәт корбаны булды.

Элекке «Сабах» ширкәтенә караган бинаны бүген төрле сәүдә үзәкләре, кибетләр биләп, арендага алып тора. Биредә юл аша гына татар байлары Кәримовлар төзеткән борынгы искиткеч матур биналар сакланган. Аларда да универмаг, кунакханә һәм башка оешмалар урнашкан. Биредән ерак түгел Чернышевский урамында «Галия» мәдрәсәсе бинасына барып чыгасың. Анда Русия ислам университеты урнашкан, шәкертләр дини белем ала. Тагы да янәшәдәге Гоголь урамында Мәҗит Гафуриның йорт-музее тирә-якны ямьләп тора. Анда М.Гафури гаиләсе яшәгән. Берара шунда ук күренекле татар шагыйре Сәйфи Кудаш гаиләсе дә гомер кичерә. Алдарак әйтелгәнчә, Тукай урамында борынгы Җамигъ мәчете тирәләре дә милләтебезнең олы әдипләре йөргән сукмакларны саклый. Уфаның борынгы үзәгендәге шушы тарихи биналар, яшел хәтфә үләнле ял бакчалары бүген дә Габдулла Тукайның рухын саклый кебек.

Гыйнвар, 2016 ел.
Уфа

«ШИМАЛЬ ЯГЫ» ГАЗЕТАСЫ

Гражданнар сугышы вакытында большевикларга каршы хәрәкәттән саклану өчен В.И.Ленин хакимияте 1918 елның мартында Мәскәүгә күченә, Петроград башкала статусын югалта. Нәкъ менә тарихның хәлиткеч шул дәверендә татар телендә совет режимына оппозициядәге газета – «Шималь *(төньяк)* ягы» басылып чыга. «Татар вакытлы матбугаты» исемле библиографик күрсәткечтә бирелгән мәгълүматка караганда, газетаның барлыгы 8 саны сакланып калган (КФУ Фәнни китапханәсендә – 3, 4, 6, 7; ТРның Тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивында 2, 8 нче номерлары)[1]. Петроград шәһәрендәге «Амәнәт» ширкәте типографиясендә басылган әлеге газетаның мөхәррире Кәрим Сәгыйд булган, ә нашире «татарлар» дип куелган.

Исмәгыйль Рәмиевнең «Татар вакытлы матбугаты» исемле альбомының «Февраль революциясе соңында чыга башлаган милли-буржуа вакытлы матбугаты» дигән бүлегендә «Шималь ягы» газетасы турында түбәндәге юллар бар: *«Фанатик милләтчеләр нашир әфкяре. Шигаре: «Берләшүдә — көч!» Бөтен эше, әлбәттә, большевикларны сүгүдән гыйбарәт булып, Тукайның вафатына 5 ел тулу уңае белән чыгарылган номерындагы шуңа багышлап язылган мәкаләләрне дә бер үк мәсьәләгә китереп ялгый»*[2].

«Шималь ягы» газетасының соңгы дип саналган 17 апрель (№8) саны Тукай вафатына 5 ел тулу уңаеннан чыгарылган. Ул тулысы белән диярлек бөек шагыйрьгә багышланып, аның беренче битендә: *«Мәрхүм Тукайның беренче шагыйрьлек дәверендә хокук вә хөррият дошманнарына каршы язган рәнҗү вә нәфрәтен соңгы әхвәл мөнәсәбәте белән дәреҗ итәбез»*, — дип «Хөррияттә» исемле шигыре бастырыла. Игътибарыгызга газетаның әлеге нөсхәсеннән берничә өзек тәкъдим итәбез.

БУ КӨНГЕ САГЫНУ

Тукайның үлгәненә биш ел вакыт гомер үтте. Үзенең дәүләтен, истиклялын (бәйсезлек) югалтып, 350 ел гомер иткән татар милләте, соңгы биш елны үзенең милли шагыйре булган Тукайсыз үткәрде.

Татарның әдәби, аның шигырь галәме, җыр дөньясы, моннан биш ел элек беренче сафында торган Тукайсыз, халык шагыйрьләренең беренчесе булган Тукайсыз яшәде.

Татар үзенең моң вә зарын биш ел бер буйдан күңел тулганча моңлый алмый яшәде.

Татарның мәктәп балалары, үзләре белән бергә уйнап, көлеп, рәхәтләнеп җырлый торган, *«Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!»* — дип аркаларыннан сыйпый торган Тукайсыз, биш ел беррәттән матәм тоттылар.

Ямьле, матур татар кызлары, мәхәббәтнең газабын-михнәтен сизгән вә шуны үзләре белән уртаклашкан, шигырьләреннән матур-матур бакчалар ясаган, ямьле-ямьле чәчәкләр биргән Тукайсыз саргайдылар.

---

[1] Гайнанов Р.Р., Мәрданов Р.Ф., Шәкүров Ф.Н. Татар вакытлы матбугаты (1905-1924): библиографик күрсәткеч. — Казан: Рухият, 1999.

[2] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (1905-1925): альбом. — Казан: Гажур, 1926. — Б.70.

Татарның иренчәк, сүлпән ялкау көчләре:

«Зур бәхетләр сызганып,
эшкә бирелгәннән килә,
Аһ! Оят, хурлык,
түбәнлекләр иренгәннән килә!» —

дип, эшкә өндәлмичә, бу ел беррәттән ялкаулык иттеләр.

Татарның милли-мәдәни эшләре, соңгы вакытлардагы сәяси вә иҗтимагый хәрәкәтләре Тукайның үткер каләменең очы төртелмичә узмый торган бөтен барышы Тукайсыз дәвам итте. Татарның бөтен тугры эшләре, ялгыш хәрәкәтләре, кәкре юллары Тукайның пычкысы белән тырналмыйча, ышкысы белән төзәтелмичә үтәлә барды.

Татарның иҗтимагый-сәяси тормышында, милли бөтенлек төзүендә комачау булган башбаштаклар, ахмаклар һәм җүләрләр, халык эше белән уйный торган каргалар, үз эшен вә үз туганын ташлап читләргә өмәгә йөрүчеләр, Тукайның ачы тәнкыйтьләреннән, кискеч сатирасыннан, пакь көлүләреннән котылып азгынлык иттеләр.

«Син мөкатдәс, мөхтәрәм
гыйндемдә барлык нәрсәдән,
Сатмазым бу кяинатә
милләтем миалиятем» —

дип, татарлык рухын гарше әгъляга[3] күтәрергә Тукай юк вакытта, аның пакь күңелен тәнкыйтьчелек сыйфаты белән керләргә теләгән егетләр, татар милләтен төрле вакыйгалар белән әвәрә итә башладылар.

Татарның киләчәге, аның якты истикъбале өчен Тукай белән бергә күкрәк черетеп милли әдәбиятка нигез салган милли мөхәррирләр Тукай юк вакытта «трибунал» мәхкәмәсенә чакырылды.

Иманлы Тукай агызыннан тәкъдис *(мөкатдәс)* ителгән, пакь йөрәкле Тукай күңеленнән ихтирам ителгән милли матбугат, Тукай юк вакытта бизәкле егетләрнең зарбәсенә *(зыянына)* очрады. Тукайның:

«Монда хикмәт, мәгърифәт һәм
монда гыйрфан, монда нур,
Монда минем нечкә билем,
җәннәтем һәм монда хур», —

дип, бөтен милли хиссияте белән бәйләнгән вә шунда нурын чәчкән чәчәген аткан җире, милли мәркәз булган Казан Тукай юк вакытта мәсхәрә ителде.

Һич шөбһә юк ки, бу тупаслык, бу шәфкатьсез вә бу мәрхәмәтсез дорфалыкларның һәммәсе өчен дә Тукайның рухы, үзенең сөйгән милләте белән, аның өчен җанын аткан татар милләте белән бергә рәнҗи торгандыр.

Әйе, Тукай үлгәнгә инде биш ел үтте. Шагыйрь булганлыгы өчен галимнәрдән, хакимнәрдән, диктаторлардан өстен булган, көчле булган шагыйрь Тукай бүгенге көндә юк.

Әгәр дә ул булса, бу көн татар милләтенә каршы пулемет куеп, күкрәгенә мылтык төзәгән «каһарман иптәшләр», Шаһгали ролендәге язгы кояшта куырылган тәти егетләр, ике сүзне бергә оештыра алмый торган ораторлар, автомобильдә сәхра чигүче чиновиниклар, мәгърур Швецария кунаклары шагыйрь Тукайның ике юллык шигыре каршысында баш иярга, тез чүгәргә мәҗбүр булырлар иде.

Шагыйрьлегенең сабыйлык дәверендә, татарның мәдәни хәятенә, гамәл дәфтәренә зур милли байлыгын мирас калдырган Тукай, бу көндә дә сәламәт булса, ниләр язган булыр иде? Нинди шигырьләр, нинди сатиралар белән татар әдәбиятын бизәкләгән булыр иде? Матбугат дөньямыз, китап базарымыз бушап калган бу вакытта ул милли әдәбиятның тәхетендә утырган шаһы булыр иде.

[3] Гарше әгъля — күкнең югары катлавы.

نومر ٨ یوش کون (سه‌شنبه) (٤) ١٧ آپریل، ١٩١٨ یل
شمال یاغی
برلـشوده ــــ کوچ!
یازلو بهٔه‌سی
بر یللق ٢٥ صوم، یارطی یللق ١٣ صوم، اوچ آیلق ٧ صوم.
بردمله‌ب ٤٠ تین.
آدریس: Петроградъ. Верейская, 13-а, кв. 5
газета „Шемаль-Ягы“.
غزته‌که یازلور اوچون شوشی آدریس بلن آقچه یبرورگه.
شوشی آدریس بلن کیلورگه کیره‌ک.
وفاتینه ـ ٥ ـ یل طولو مناسبتی بلن شاعرمز توقای‌نک روحینه فاتحه.

شمال یاغی
پیتروغرادی ملی ولایتدگی مسلمانلرغه!

«Шималь ягы» газетасы һәм аның мөхәррире Кәрим Сәгыйд

Аның «Шүрәле»се артыннан ияреп тагын әллә никадәр иске әкиятләр, яңадан яңа «Кисекбаш»лар мәйданга килер, күңелне, рухны мөсәххәр итә *(сихерли)* торган милли хикәяләр, аның шигырь чишмәсендә бизәнеп чәчәк атарлар, бөтенлек алырлар, каһарман бабаларыбыз гәүдәләндерелеп татар дөньясының алдына бастырылырлар иде. Аның энҗе кебек төзелгән шигырьләре, безнең бу көнге-кайгы хәсрәтләремезне йоттырыр иде.

Ләкин боларның берсе дә юк, чөнки Тукай кабердә! Ул бездән, без аңардан аерылган. Без аны барлык милли хәятемез, бөтен милли әмәлемез белән ихтирам иткән хәлдә еглый-еглый сагынабыз!

Кәрим Сәгыйд

ТУКАЙ — ТАТАР ШАГЫЙРЕ

...Русия мөселманнары: «Без мөселман, без татар түгел!» — дип мәйханә килгәндә, шуның белән исергәндә, шуны гына хөрмәтләп башканы теләмәгәндә, Тукай үзенең татарлыгын, татарлык фикерен хидмәт итәчәген чын-чын муафәкатьле *(яраклы)* шигырьләре белән җырлап бирде. Шунлыктан халык күңелендә гайрәт, хәмиять, батырлык тойгыларын ник-

ландыра торган миллиятне, татарлыкны уртага салды.

Тукай татар теленә право, гражданство институты бирде. Татар теле дә башка телләр кебек үк бер дәрәҗәдә, шундый ук хакка малик (ия) әдәби, мәдәни бер тел икәнлекне мәйданга куйды. Тукай бөтен милләткә татарча әдәби иттереп сөйләшү дәртен кузгатты. Шулай сөйләшергә өйрәтте. Телнең онытылган, кысылган йирләрен тудырды. Шул сәбәпле Тукай татар тарихында мәңге онытылмаслык бер исем!

Җамал Вәлиди[3]

5 ЕЛ ТУЛГАНДА

Татар милләте! Син дә моннан соң шагыйрең, гомумән бөек адәмнәрең исеменә бөек уку йортлары, зур хәйрат мөәссәсәләре тәэсис итеп *(оешмалары төзеп)*, шул мөәссәсәләрдә милләт балаларын бөек шагыйрь вә бөек адәмнәрнең бөек, гали идеясе вә фикерләре белән таныштырып, аларны өмид йолдызларына таба юнәлдерергә сәвекъ итәргә *(алга этәрергә)* тиешсең!

Әй, кадерле шагыйрь! Арабызда булсаң, татар милләтенең читләрдән күргән бу көнге золым вә җаберләре хакында ни генә әйтер идең дә, ничек кенә тасвир итәр идең?! Беләм ки, милләтнең бу көнге хәле сине яткан урыныңда борчый вә әрнетә торгандыр. Ләкин борчылма, тыныч бул! Татар милләте һичбер вакыт изелмәячәк, ул тиз вакыт аякка калкып имин вә мәсгуд *(бәхетле)* яши башлаячактыр.

Фазылҗан Биккенә

***

Тукайсыз татар ятим. «Золым вә җәберләр»гә дучар ителгән милләт Тукай кебек көрәшчегә мохтаҗ. Тукай — өмет. Тукай милләтне берләштерергә тиеш. Алдагы мәкаләләрдән шул аңлашыла. «Шималь ягы» газетасының төп мәсләге, анда күтәрелгән проблема, аңлашыла ки, татар халкының милли азатлыгына, аны 1918 елда борчыган проблемаларга бәйле. Газетада Петроград, Казан һәм Россиянең башка шәһәрләрендә яшәүче татарларның мәдәни тормышы яктыртылган. Шул ук Тукайга багышланган санда «Яшь татарлар оешмасы» имзасы белән, Габдулла Тукайның вафатына 5 ел тулу мөнәсәбәтле, Ростов, Мәскәү, Казан, Оренбург, Сембер, Чиләбе һәм Себернең башка шәһәрләрендә искә алу кичәләре буганлыгы турында да мәгълүматлар бар. Газета сәхифәләрендә «Татар дөньясында», «Казан хәлләре» дигән махсус рубрикалар да булган. Шулардан кайбер өзекләр китерәбез:

*«**Милли гаскәр** таратылып, коралсызландырылып, **татар милициясе** туздырылып бетерелгән. Шәһәрнең (Казан шәһ.) татарлар тора торган кыйсемендә вакытлы революционный штаб төзелгән. Халык арасында талаулар беткән. Акырынлап тынычлык урынлаша башлаган. Приказлар берсе артыннан берсе явып кына тора».*

«Мөселман зыялыларының нашир әфкяре булган «Корылтай» гәзите Казан инкыйлаб штабының боерыгы белән ябылган. «Корылтай»ның баш мөхәррире Фуад әфәнде (Туктаров) югалган. Җамалетдин әфәнде Вәлиди тәүкыйф ителеп (кулга алынып), допрослар ясалганнан соң гына ирекккә йибәрелгән».

*«Казаннан алынган хәбәрләргә караганганда, большевиклар белән татарлар арасындагы мөнәсәбәт һаман әле юлына төшеп бетмәгән. **Татар солдатлары**ның бик күбесе китеп беткәнгә, Хәрби Шураның көче беткән, ләкин **Казан татарлары үзләре коралланганнар.** Мәхәлләләрдә **мөселман полклары** төзелгән».*

[3] Газетада мәкаләнең авторы күрсәтелмәгән.

«Казан большевикларының ишаны Гайнан Вәисине күмүдә татарлар иштиракъ итмәгәннәр. Аны казаклар белән Кызыл гвардия күмгән һәм урыслар мәзаратына дәфен иткәннәр (җирләгәннәр)».

Газетада, иҗтимагый-сәяси вакыйгалар, Беренче Бөтендөнья фронтындагы хәлләр яктыртылу белән бергә, милли үзбилгеләнү мәсьәләләренә дә зур игътибар бирелгән. *«Бөек татар милләте, 350 ел дәвамындагы караңгылыктан соң, милли мохтарият дип, шанлы, шәүкәтле вә үзенең шанына (дәрәҗәсенә) муафикъ милли байрак күтәрде, Милли мәҗлес төзеде, халык шуны таныды»*, — дип яза «Шималь ягы». Петроград «милли вилаять идарәсе» милли мохтәрият кануны нигезендә җамигъ мәчетне, аңа караган йортны, мал һәм милекне, татар мәктәп-мәдрәсәләрен, милли-мәдәни мәсьәләләрне, мәчетләрне, аларга караган вәкыф милекләрен идарә итүне үз кулына алачагы турындагы карарны мәгълүм итә. Карарга «Милли вилаять идарәсе рәисе могавине *(ярдәмчесе)* Кәрим Сәгыйд» дип имза куелган. Ә махсус «Милли вилаять идарәсенең хәбәрләре» дигән рубрикада әлеге идарәнең мәгариф бүлеге яңалыклары белән танышырга мөмкин. Аларда, Петроградтагы татар мөгаллимнәрен, укыту программасын берләштерү белән бергә, «нәшер мәгариф», «җәмгыяте хәйрия» исемендә булган бөтен мәдәни байлыкларны берләштерү, хосусый куллардагы китапларны җыеп милли китапханәгә китерү, Петроград яшьләр түгәрәген, әдәбият-сәнгать өлкәсендә эш башлаган көчләрне, милли сәхнә, милли театр һәвәскәрләрен берләштерү, гомумән «мәдәни көчләрне бергә җыю», «мөкәммәл бер куәт мәйданга китерү» турында да фикерләр бар. Әмма чынбарлыкта милли вазгыять шактый кискен һәм әлеге юлларның авторы да шуңа сызлана: «Ни өчен безгә тияләр? Ни өчен безнең гаскәри шураны таралар? Ни өчен безнең милли-мәдәни эшләремезне кулымыздан тартып алалар да, үз тәкъдиремезне үзебезгә тапшырмыйлар? Ни өчен Идел-Урал штатын игълан итәргә ирек бирмиләр? Татарлар — контрреволюционер түгел! Татар милләте чын хөрриятче, чын демократ! Шулай булгач, **350 ел элеккеге тарихны тәкрар итәргә урын юк!**»

***

Газетаның баш мөхәррире, татар мәдәнияте, журналистикасы тарихында саллы эз калдырган шәхес, күренекле тюрколог һәм җәмәгать эшлеклесе Кәрим Сәгыйдов турында да кыска гына мәгълүмат бирү урынлы булыр. Санкт-Петербург Милли китапханәсенең библиографы Энҗе Сәгыйдованың 1990 елгы «Казан утлары»ның 11 нче санында әтисе Кәрим Мөхәммәтша улы Сәгыйдов (1888-1939) турында язган мәкаләсе бар[4]. Кызы язган мәгълүматка караганда, К.Сәгыйдов Буа мәдрәсәсен тәмамлый. «Кояш» газетасының Петербургтагы рәсми хәбәрчесе булган, мәкаләләре «Вакыт», «Әл-ислах», «Сүз», газеталарында, «Шура», «Ак юл», «Мәктәп» журналларында да басылган. 1920-1930 елларда Казанда татар телендә фәнни эчтәлекле китаплар язу белән шөгыльләнә, «Игенче», «Безнең юл» журналлары белән хезмәттәшлек итә. 1934 елда Ленинград шәһәренә күченә, СССР Фәннәр академиясенең Тарих-археография институтында эшли, шәрык кулъязмаларын тикшерә. 1936 елда, нахакка гаепләнеп, кулга алына, 1939 елда төрмәдә һәлак була.

Кәрим Сәгыйдов Тукай белән аралаша һәм «Тукайның Петербургта үткән көннәре» дигән истәлекләрне дә язып калдырган.

Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

[4] Сәгыйдова Э. Галим, педагог, журналист… // Казан утлары. — 1990. — №11. — Б.185-186.



Подписная цѣна на газету „СЮЗЬ“:

12 м. 6 р.	11 м. 5—50.	10 м. 5 р.	9 м. 4—50.	8 м. 4 р.	7 м. 3—50.	6 м. 3 р.	5 м. 2—60.
4 м. 2—20.	3 м. 1—80.	1 м. 50 к.	заграницу вдвое. Отдѣльные №№ 6 коп.				

Цѣна объявленій:

Впереди текста за строку петита 50 к., позади текста 25 к. Мелкія объявленія предлож. труда позади текса 10 коп. строка петита.
За объявленія въ видѣ вкладн. прилож. къ газетѣ: вѣсомъ до 1 лота 10 р., за кажд. слѣд. лот. по 2 р. 50 к. съ тысячи.
Адресъ конторы и редакціи: Москва, Мещеринское подворье, редакція газеты „СЮЗЬ“. Телефонъ № 4-67-01.

4-67-01.

контора и редакція газеты „СЮЗЬ“.

آياولى قبر

Москва. Трубная ул., д. № 5. Магаз. Бр. Карамышевых.

Тукайның вакытсыз үлеме татар дөньясы, татар зыялылары тарафыннан зур фаҗига буларак кабул ителә. Шул елларда нәшер ителгән татар вакытлы матбугаты Тукайга игътибарын тагы да көчәйтә, аерым саннарын аңа багышлый. Замандашлары, шагыйрьне югалту хәсрәтеннән, кулларына каләм ала. Тукайның бөеклеген, яки үлемен ачыкларга омтылып, мәкаләләр, аның турында истәлекләр язалар. Шагыйрьләр исә аның иҗатына булган ихтирам, хөрмәтләү сүзләрен шигъри юлларга салалар.

«СҮЗ» ГАЗЕТАСЫНЫҢ ТУКАЙГА БАГЫШЛАНГАН БЕР САНЫ

Берсен-берсе дәвам иттереп, 1913-1918 елларда Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә чыгып килгән «Ил», «Сүз» газеталары да бу вакыйгадан читтә калмаган. Тукайның үлеменә бер ел тулу уңаеннан, «Ил» газетасының 1914 елгы 2 апрель (23нче) саны тулысы белән шагыйрьгә багышланган. Газетаның эшчәнлеге 1915 елның 29 март (89 нчы) санынннан «сәяси яктан зарарлы» дип табылып, ябыла. Шунлыктан шагыйрь вафат булуының ике еллыгына махсус саны чыга алмый кала. Эшнең шулай килеп чыгасын алдан күреп булса кирәк, Исхакый газетаның соңгы санына үзенең «Тукай мәрхүм» исемле мәкаләсен урнаштыра. «Сүз» газетасының 1916 елгы 3 апрель (41нче) санында да шул традиция дәвам иттерелә. «Вафатына өч ел тулу мөнәсәбәте белән шагыйремез Тукай рухына фатиха» дип, Тукайга багышланган әлеге санда да шагыйрьгә шактый урын бирелә. Газетада баш мәкалә буларак, Гаяз Исхакыйның «Мәрхүм Тукай» исемле язмасы, Шакир Мостаевның (Шакир Мостафа) «Рәхмәтле Тукай» мәкаләсе һәм Гыйффәт туташның (Заһидә Бурнашева) «Хатирә» исемле шигыре дөнья күрә. Әлеге әсәрләрнең беренчесе, безнең тарафтан әзерләнеп, унбиш томлы Г.Исхакый «Әсәрләр»енең 7 нче томында басылды. Калган икесе хәзерге матбугатта беренче мәртәбә тәкъдим ителә.

РӘХМӘТЛЕ ТУКАЙ

Шакир Мостаев

Бөтен, барлык дөньясына берьюлы яки берәмләп, кирәк тышкы күренешенә, кирәк эчке рухи хәлләренә күз салсагыз — каршыгызда, күзләрне камаштырган, хыялыгызга иксез-чиксез мәйдан ачкан, фикерегезгә тиңсез азыклар биргән тәгъбире өчен *(фразасы өчен)* санаулы хәрефләрдән ясалма сүз җиткерә алмаслык бер хәл, бер мәгънә барлыгын күрерсез, тоярсыз.

Бу хәл, бу мәгънәне күрүче, тыючы, үзе мәнсүб булган *(караган)* мәсләге, мәнсүб булган сыйныфы, сыйдыра алган кадәр хәвасләсе *(хисләр)* даирәсендә, каршысындагысын аңларга, тәгъйин итәргә *(ачыкларга)* көчләнә.

Үзенең санаулы белеме, чикле мие, тарафдар мәсләге, сыйнфый мәгълүматы арасындан мөнасиб *(яраклы)* мохит тәгъбир таба алмыйча җөдәп исергәнгә, иң мөкатдәс белгән исем белән ятлап, шул исемне аңар тагып юанмакчы була. Я бөтенләй гыйсъян итә. Һәр барлыкны инкарь итәргә тотына.

Күктәге йолдызлар, җир йөзендәге матур табигать, матур киенгән гүзәлләрне күргән бер илаһи, «кайда карасам Алланы күрәм, башкаларны буш хыял, я күзгедә гакесләр *(чагылышлар)*, я җиргә төшкән күләгәләр генәдер», ди башлый.

Җаны үзенә татлы булган бер динче, бу мәгънәдә чиктән тыш бернәрсә табып куркына, ут газабыннан сакланыр өчен Аллага сыгына башлый.

Бер фән мөтәхассыйсы *(белгече)*, кирәк табигатьче булсын, кирәк риязы *(математик)* булсын, берсе каршысындагысының гәүдәсендәге кисәкләрне җентекләргә керешә, икенчесе аның аркылысын-буен үлчәргә башлый. Ләкин берсе дә шуңар мөнасиб *(яраклы)* мохит, бер тәгъбир белән күз алга ясап чыгарып бирә алмыйлар. Берсе дә табигать галименең һәммәсенә бертигез мөнәсәбәттә тора алмыйлар. Һәркайсы үзенә якыныракны, хәвасләсенә *(күңеленә)* сыйганыракны, тормышы өчен файдалыракны сайлый, шуны гына аңлый, шуны гына тәкъдир итә.

Барлык галимнең һәммәсенә: зурысына, кечесенә, көчле-көчсезенә барында да туктаган, һәммәсен дә бер күз салу белән эченә кереп күргән, Алланың үз кулы белән, үз табигате белән җитештергән бер шәкерте бар — шагыйрь. Бу шәкерт пакь тойгысы, үзенә аерым бер күрү белән, табигый бер мәһарәт *(осталык)* белән әлеге санлы сүзләр теземеннән ад *(исем)* бирә. Күзгә күренми, кулга тотылмый торган әйберләрне мөҗәссәм иттереп *(гәүдәләндереп)* күрсәтә ала.

Гади күзләр төшке кояш, я шуның кебек ялтыравыклы, шалтыравыклы әйберләргә генә, һәрьягы килгән, киенгән гүзәлләргә генә сәҗдә итсә, шагыйрь күзе сулгач, аяк астына ыргытылган букетка сәгатьләрчә туктальп, йөзләрчә сәхифәгә җитәрлек дәһшәтле нәрсәләр күрә.

Урам чатында сөялгән ташландык татар кызына карап, бер сания *(секунд)* эчендә бөтен мәнсүб булган халкының рухи, иҗтимагый тормышларын иң назик *(гүзәл)*, иң тирән почмакларын күз алга китереп сала.

Бер фән кешесе чикерткәнең ботын «дүлә»ләп *(доля)* үлчәсә, бер чебеннең күзен җентекләсә, канатындагы төсләрен тәхлил итсә *(аерса)*, бер мачының тырнаклары эчкә батуындагы серләрне уйласа, бер сәүдәгәр аның тиресен кайда күбрәк сатарга мөмкинлеген эзләсә, шагыйрь бөтен җир шарын оясына ташыр дәрәҗәдә комсызлык күрсәткән кырмысканы сөйләтә. Язып утырган җирендә кибеп бетмәгән язуларыннан карасын суырырга юлышкан чебен белән иптәшләрчә сохбәт итә *(әңгәмә кора)*.

Мачының йомшак түшәп, каты йоклатуындагы интригаларын бер карауда үзеннән игътираф иттертә *(гаебен таныттыра)*. Һәммә бу сүзләрне, җанлыҗансыз телле-телсез әйберләрне халык теле, халык аңы, аның садә, табигый, эч-керсез аңына ягымлы рәвештә сөйләтә. Гади күзләрнең гакылларын шашырган көч белән үзләшә, аның телен, рухын төшенә, соңыннан аны адәм баласы аңларлык калыпка куеп ясап чыгара.

Шагыйрь табигате белән һәр галим, һәр мөтәфәннин *(энциклопедист)*, һәр хаким, һәр мөтәсәллитъдан *(изүчедән)* өстен, көчле булганга күп вакытта көчсез якка чыгып, көчлеләргә каршы мәйдан укый. Аларга һөҗүм укларын яудырырга башлый.

Буның белән шагыйрьнең көче кимеми. Сауган саен килгән сөт кебек өстәлә генә бара. Шуңар күрә җан көйдергеч туп утларына каршы күкрәк киергән командан, бөтен мәхәлләсенә фиргавен ролен уйнаган кама якалы дамелла, кечкенә бер капризы өчен кибеттәге приказчикларын пыр туздырган, ияк асты түшенә тоташкан зур корсаклы купец, мәгърур аксөяк, аполитлы *(искитмәүчән)* бер чиновник шагыйрьнең ике юллык шигыре каршысында баш иярргә мәҗбүр булалар.

Адәм углы җир шары хәятындагы тарихтан элекке дәверләрдән бирле, көчлеләр белән тартышкан шагыйрьләрдән буш тормады. Бу кыйсем шагыйрьләр табигать сөреше белән араларындагы дәһшәтле хәлләрне азмы-күпме тәгъдил итә *(йомшарта)* килделәр.

Шигырь – садәлек *(гадилек)* эчендәге нәзакәттән *(матурлыктан)* гыйбарәт булганга шагыйрьләрнең рухларындагы нәзакәт тә садәлектән гыйбарәт була. Шуңар күрә шагыйрьләр табигатькә якын булган «халык» аталган сыйныфка якын торалар. Халыкның садә рухы шагыйрь рухы өчен, җир шарын вакытлыча мескен итеп, ихтыяр иттерә. Шагыйрь аның хыялына киләчәктә хакыйкатькә әйләнәчәк иттереп көч, азык бирә.

Башук рухы шигырьдән башка хыялга китерү мөмкин булмаганга, җанлы вә җансыз һәр әйбер шигърияттән буш түгелдер.

Табигый хәяттә бу шулай булган кебек. Мәдәни-иҗтимагый хәрәкәтләрнең, инкыйлаб дәверләренең башын, гамәлен, җеп очларын җентекләсәк, тарихларын тикшерсәк, сүнәр-сүнмәс шәм янында төн уртасында сулган йөзле шагыйрьнең нәзек бармаклары арасыннан түгелгән сәтырларга *(юлларга)* килеп терәлгәнен күрерсез.

Татар әдәби, милли инкыйлаб дәверендә дә бу җепләрнең бер очы «Ислах» идарәханәсендә һәм «Болгар» мосафирханәсенең 40 нчы номерында баркадәр гәүдәсе бер рухтан гыйбарәт Тукайның каләм очына килеп тукталадыр.

Тукай — бер шагыйрь. Бер сәнгатькәр булудан өстен бер татар милли шагыйре иде. Дөрест, аның татар рухын сугару юлындагы шигырьләрен санамаганда да, бер сәнгатькәр булуы гына да, Тукайга XX гасырда Идел буе шагыйрьләренең таҗын кияргә хак бирәдер. Чөнки Тукайның язган шигыре генә түгел, гади сөйләгән сүзендә, хосусый мәктүбләрендә, 24 сәгать эчендә йөз кат телгә кереп чыккан гади сохбәтләрендә *(әңгәмәләрендә)* дә бер аһәң, үзенә аерым бер шигърият, бер нәзым табигыйлык бар иде. Буның өстенә ул татарның мәдәни уйгану дәверенә тәсадеф иткәнгә *(кагылганга)*, яшь татарга аның мәктәпле, телле, әдәбиятлы, мәгарифле татар милләте булып борынлавы өчен нык өмид орлыклары чәчте.

Тарихта онытылыр дәрәҗәгә төшкән бетә-батам дип чайкалып торган татарның бу фаҗигасенә сәбәп булган гамәлләренә каршы кискен вә парлак *(данлыклы)* сугыш ачты.

Гаиләләрдәге иҗтимагый дорфалыкларны мәйданга куйды.

Мәдрәсәләрдәге Бохара калдык-постыкларын селкеп салды.

Мазыйсыннан *(үткәненнән)* сукыр татарга тарихын, шан вә шәүкәтен исләтте.

Яшь татарның өмет гөлләрен сугарды, гая әмәл *(ышаныч)* тудырды, рухын сыйпады.

Татар үз шагыйрен һәммәдән элек шул ноктадан таный. Аны бер пәйгамбәрдән, бер реформатордан көткән кебек халык хамисы *(яклаучысы)* итеп күрә.

Үз рәтендә Тукай боларны, аңар татарның сыгынуын күрсә дә, сизсә дә мәгърур булмады. Ул «башыннан сыйпап үстергән милләтенә» каршы үзендә бер вазифа шинаслыктан *(белгечлектән)* артык әйбер, «бер татар углы» булудан өстен нәрсә танымады.

Һәр шагыйрь кебек Тукай да бөеклекне, матди бөеклектә, дәрәҗә зурлыгында, акча күплектә дип ышанмаганга, бәлки хөлусда *(ихласлылыкта)*, сафлыкта, садәлектә икәнен нык сизгәнгә, борынгы черегән татар гонсыры *(токымы)* карашында «бөек» танылган һәйкәлләргә исе китмәде. Җаннарына сугылмады. Үзләре кагыла икән «Гадәмең *(юклыкның)* улы!» диде, якын юллатмады *(җибәрмәделәр)*.

Тукай бер татар углы булса да, халис *(чын)* табигать баласы, тирәякның төрле дорфа тәэсиреннән котылырга муафикъ булган, халис табигать баласы, тирә-якның төрле дорфа тәэсиреннән котылырга муафикъ булган хирыс *(комсызлык)* вә тарафдарлык белән күзне сукырайта торган сыйнфый мәсләк тәэсирләреннән югары табигать җимеше иде.

Бәхетенә каршы кечкенәдән үк кем химаясенә *(яклавына)* да сыгынырга туры килмичә, чикләнгән канат астында калмыйча рухан ялгыз җитешү аңарда һәрнигә сынап карау, ышанырышанмас карауны тудырган. Булачак шагыйрьгә, кечкенә башыннан ук үзенә генә таяну, үзеннән генә көтү игътикадын *(ышануын)* нык беркеткән.

Тирә-яктагы кара көч, гәүдә көчләренә ышанычсызлык тойгысын үстергән. Аз сүзле, уйчан, шыпырт кына, тавышсыз-нисез генә һәммә тирә-ягын, бара торгач, бөтен хәят агымын каш астыннан сынап торучан, барысы хакында үзенә аерым бер караш асраучан итеп хәзерләгән.

Ата-анасыз җитешкәннәрнең берәр юлда каһарман булып чыгулары, киресенчә әйтсәк, каһарманнарның күп чакта ата вә аналарсыз үскән булуы тәрҗемәи хәлләрдә очралган кебек татар инкыйлаб дәверендә дә Тукай тәрҗемәи хәлендә очраладыр.

Икенче апрельдә рәхмәтле Тукайның сөйкемле рәсеменә карап, талып утырган чактагы тәэсириятемне шагыйрьнең гали рухына багышлыйм.

Гыйффәт туташ
(Заһидә Бурнашева)
(1895-1977)

ХАТИРӘ

(Мәрхүм Г.Тукаевка багышлыйм)

Ниндидер ак рух безем күктә сихерле
кой көйләп,
Йөзде, ялкынлы йөрәктән тәңренең
вәхиен сөйләп.
Моңлатып айны вә йолдызлар нәфис
чулпанны ул,
Уйгатып, йокларга яткан, изге саф
вөҗданны ул.
Серләшеп моңлы күңелләр мәрьҗигы
ал таң белән,
Тирбәтеп мәгъсүм йөрәкләрне сихерли
наз белән.
«Дөньяда һәрнәрсә дә үз аслына бер
әйләнә»
Бер йөзеп алгач та очты Тәңрегә ул
рух янә.
Калды ләззәтле, гүзәл моңлар безем
күңелдә тик,
Тибрәнеп калды күңелнең кыллары
тик, әллә ник!..

*Кереш мәкаләне һәм текстларны басмага **Эльмера Галимҗанова** әзерләде.*

ТУКАЙ — ЯДКЯРЛӘРДӘ

Текстны һәм искәрмәләрне басмага *Рәмил Исламов* һәм *Җәүдәт Миңнуллин* әзерләде.

Истәлекләрнең авторы Гариф Латыйф (1886-1962) – Г.Тукайның замандашы, журналист. Аның зәңгәр кара белән кириллицада 1946 елның 2 апрелендә язган бу истәлеге хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас фондында саклана: 9 ф., 4 тасв., 76 сак. берәмлеге. Зур булмаган өлеше «Кызыл Татарстан» газетасының 1935 елгы 15 апрель санында басылган. Текст кулъязмадан алынды һәм беренче мәртәбә тулысынча басыла.

ТАТАР ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕК

Гариф Латыйф

БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУ

1907 нче елның җәй ахырлары иде. Драматург Г.Камал, Солтан Рахманкулов, мин һәм татар яшьләреннән тагын берничә кеше «Йолдыз» газетасы редакциясендә утырып тора идек. Шулчакта кечерәк буйлы, ябыграк, шәкерт сыман бер егет килеп керде. Печән базарындагы «Болгар» номерларының кечкенә бүлмәсендә урнашкан редакциягә бик күп кеше килә иде. Аларның кайсылары газетага язылалар, кайсылары газетага хәбәр китерәләр, кайберәүләр адрес яздырырга керәләр. Сотрудникларга күбрәк

таныш булган кешеләр исә болай, сөйләшеп утыру өчен генә киләләр иде. Шунлыктан яңа килеп кергән егеткә игътибар биреп торучы булмады.

Без төрле политик һәм тормыш мәсьәләләре турында сөйләшә идек. Яңа кергән егет: «Исәнмесез?» — дип әйтте дә бер кырыйдагы өстәлгә куелган газеталарны карый башлады. Ул газеталарны караса да, безнең сүзләргә колак сала, елмаеп куя иде. Бераз вакыт үткәч, яшь егет безнең сүзгә кушылып китте һәм акыллы гына сүзләр әйтте.

Безнең күзләребез аңа текәлде.

Г.Камал аннан:

— Сез кем буласыз соң? — дип сорады.

Кунагыбыз кызарып китте һәм акрын тавыш белән:

— Мин Габдулла Тукай булам, — диде.

Бу сүз безгә электр тогы кебек тәэсир итте. Барыбыз да урыннарыбыздан сикереп тордык. Г.Тукай белән кочаклашып күрештек.

«Фикер» газетасында һәм башка газеталарда басылып чыккан гүзәл шигырьләре белән Г.Тукай үзенең исемен бик яхшы таныткан иде инде. Шунлыктан без аны күтәреп алдык. Хәлен сораша башладык. Г.Тукай солдатка каралырга авылына кайту өчен Уральскидан килгәнлеген әйтте.

Г.Камал, звонок басып, хезмәтче малайны (официантны) чакырды. Пәрәмәч белән чәй китерергә кушты. Берничә минут үтүгә, Г.Тукай белән күптәнге танышлар кебек булып киттек. Мәҗлесебез бик күңелле булды. Без Г.Тукайга, гаскәри хезмәткә алынмаса, Казанга килергә киңәш бирдек. Ул Уральскидагы авыр тормыштан бик туйганлыгын әйтте. Исән-сау булса, Казанга килеп торырга риза икәнлеген аңлатты.

ЧӘЧӘК АТУ ЧОРЫ

Г.Тукай, гаскәри хезмәткә барудан азат ителгәч тә, Казанга килеп тора башлады. Аның шигырьләре газеталарда еш кына басылып чыга иде. Шул ук вакытта төрле китап сәүдәгәрләре һәм наширләр шагыйрьне, бал янына җыела торган шөпшәләр кебек, сырып алдылар. Аларның һәрберсе Г.Тукайның әсәрләрен бастырырга тели. Ләкин ничек тә арзан түләргә, үзенә күбрәк табыш алырга тырыша иде. Садә күңелле бичара Тукай алар белән сатулашуны үзенә кимчелек саный. Ни бирсәләр, шуңа риза булып, шигырьләрен бастырырга бирә иде. Шунлыктан Г.Тукай бик мохтаҗлыкта яшәде. Ләкин аңа карап, ул рухын төшермәде. Казанда яшәгән берничә елы аның иҗады чыннан да чәчәк аткан чор булды. Ул елларда «Әлислах», «Ялт-йолт», «Аң» журналларында күп шигырьләре урнаштырылды, аерым китаплары басылып чыкты.

Тукай Уральскида торган вакытында үзенең әсәрләрендә гарәп, фарсы сүзләрен бик күп куллана иде. Беркөнне мин аңа Уральскида 1906 нчы елда язган «Пушкинә» исемле шигырен укыдым һәм:

«Нәзыйрсыз шагыйрь улдың (афәрин), Пушкин Александр!
Бәнем дә дәрде шәүкым һәм сәнең дәрдеңлә якъсандыр[1], —

дигән сүзләр бик матур язылган, ләкин аларны күп кеше аңламый.

[1]Тәрҗемәсе: Тиңдәшсез шагыйрьсең (афәрин), Пушкин Александр! Минем дәрт-омтылышым синең дәртең белән бер үктер.

Татарча сүзләрне күбрәк кулланып язсагыз яхшырак булыр иде», — дидем.

Г.Камал һәм башкалар да аңа шул киңәшне бирделәр.

Г.Тукай безнең киңәшне хуплап каршы алды. Шуннан соң шигырьләрен татар массасына аңлаешлырак итеп яза башлады. Ул үзенең шигырьләрен язу өчен уңайлы өстәл һәм кабинет булуны көтеп тормый. Чәйханәдә чәй эчеп утырганда яки редакциягә безнең белән күрешергә кергәндә дә үзенең энҗе бөртекләре кебек шигырьләрен язып ала иде.

Бервакыт мин Г.Тукайдан шигырь язарага ничек өйрәнгәнлеге турында сораштым. Ул болай җавап бирде:

— Мин кече яшемнән үк ятим калдым. Һәр җирдә мине кыерсыталар иде. Шунлыктан мин моңаеп йөрим, әтиемне, әниемне, туган җиремне сагынам, моңаеп җырлап йөрим. Язу таный башлагач, минем кулыма «Бакырган» һәм «Мөхәммәдия» китаплары килеп керде. Мин алардан шигырьләрне бик яратып укыдым, матур итеп төзелгән касыйдәләрне ятлап алдым һәм көйләп йөри башладым.

Аннары, Уральскидагы мәдрәсәдә укыганда, Төркиядән качып килгән революционер, шагыйрь Габделвәли Әмрулланың миңа зур ярдәме тиде. Беренче шигырьләремне мин аның киңәше буенча яза башладым...

Г.Тукай чыннан да көйләп, җырлап йөрергә ярата иде. Ул кайчакта «Мөхәммәдия» көенә җырлый, кайчакта «Краковяк»ны[2] да көйләп куя иде. «Хасият» исемле шигырен язганнан соң, көйләп укып йөргәнлеге әле дә күз алдымда. Ул аны «Мөхәммәдия» көенә җырлый, үзе шатланып көлә иде.

1908 нче ел башларында Г.Тукай Московский урамда аптека каршындагы йортның (хәзерге Киров[3] урамы, 53/6 нчы йорт) ишегалдына караган караңгы бүлмәдә торды.

Беркөнне мин аның янына бардым. Ул миңа, материаль яктан авыр шартларда торуыннан зарланып, болай диде:

— Хозяйка бүлмәдән куа: «Акча түләмисең», — ди. Ярый әле «Караван» чәй фирмасы игъланын шигырь белән тәрҗемә итеп бирдем. Бәлки, 10-15 сум бирерләр. Бирәр айга хозяйканың сүзләреннән котылырмын...

Шулчакта ул миңа шигырь белән язылган «Чәй фирмасы «Караван» дигән игъланны укыды. Анда: «Бу фирманың чәйләре бик яхшы, аны сатып алыгыз», — дип шактый озын шигырь язылган иде.

Мин Г.Тукайга:

— Без каләм хезмәте белән көн күрүчеләрдә акчасыз булу гаҗәп түгел инде, — дидем.

Ул:

— Синең дә акчаң юкмыни? — дип сорады.

Мин кесәмнән портманетымны чыгардым да:

— Акчасызлык турында минем ике юллы гына бер шигырем бар. Рөхсәт итсәң, укыйм, — дидем.

Г.Тукай:

— Бик яхшы, укы, — диде.

Мин, портманетны күрсәтеп:

[2] «Краковяк» («Krakowaiak») — поляк халкының киң таралган биюе. Краков воеводасында яшәүчеләр арасында барлыкка килгән.

[3] Хәзер янә Мәскәү урамы.

Ни булган соң минем бу портманетка?
Түләргә калмаган бер манет та.

Г.Тукай бик кычкырып көлде һәм миннән үз янына ешрак килеп йөрүемне сорады.

Берничә көн үткәч, мин тагын аның янына килдем. Ул мине бик шат каршы алды. Хозяйканы чакыртып, самовар китерергә кушты. Хозяйка ачык чырай белән: «Ярый, хәзер китерәм», — дип чыгып китте. Г.Тукай елмаеп көлде дә, миңа карап:

— Акча шулай йомшарта ул. Бер айлык квартира хакын алдан ук түләгәч, хозяйка бөтенләй үзгәреп китте. Әле күптән түгел самовар да бирми башлаган иде. «Караван» фирмасыннан акча алгач, мин аның авызын томаладым. Хәзер берәр йомыш кушсаң, «Сию минуту», дип йөгереп китә, — диде.

Чәй эчкәннән соң, урамга чыгып киттек. Ул көннәрдә русларның «Масленица» бәйрәме бара иде. Урамнарда кеше бик күп. «Май чабарга» килгән татар һәм рус крестьяннары үзләренең кыңгыраулар таккан, чуклар, тасмалар, җиз төймәләр белән бизәлгән һәм төрле чаналарга җигелгән атларында кешеләрне утыртып йөртәләр иде.

Без дә бер ат ялладык. Татар кучер безне шәһәр урамнары буйлап йөртте. Аннары безнең кушуыбыз буенча атны Яңа ашлык базары[4] (хәзерге Ухтомский[5]) урамына китереп туктатты. Анда бәйрәм уңае белән хәзерге бакча урынында берничә карусель, 3-4 балаган корылган иде. Күп халык җыелган. Балаганнар алдында башларына зур маскалар кигән клоуннар халыкны «Кәмит»кә чакыралар иде.

Г.Тукай миңа:

— Әйдә, бүген без дә гулять итәбез, — диде.

Иң элек каруселькә утырып берничә тапкыр әйләндек. Аннары «Кәмит»кә кереп, клоуннарның кыланышларын, акробатларның төрлечә сикерүләрен карадык. Г.Тукай, аларны карагач, сабый балалар кебек шатланды, кычкырып көлде. Аннан без минем квартирама киттек. Мин вокзалга якын Мещанский һәм Аркылы Владимирский (хәзерге Нариман һәм Пионер) урамнары чатындагы йортта тора идем. Г.Тукай бераз торгач та үзенә «илһам» килгәнлеген әйтте һәм шунда ук кәгазь, карандаш алып шигырь язарга тотынды. Хозяйканың самовары өлгергәнче, ул берничә шигырьне язып алган иде инде. Шуннан соң Г.Тукай минем яныма еш кына килеп йөри башлады.

«ПЕЧӘН БАЗАРЫ, ЯХУТ ЯҢА КИСЕКБАШ»

1908 нче елда җәй ахырына таба Казан циркында көрәшләр башланды. Көрәшчеләр арасында Карәхмәт исемле бер төрек көрәшчесе дә бар иде. Печән базары татарлары аны зур шатлык белән каршы алдылар. «Мөселман пәһлеван килгән» дип, Карәхмәтнең көрәшкәнен карарга бик кызыксынып йөриләр. Цирк хуҗасы Никитин татар сәүдәгәрләренең бу нечкә кылларыннан бик оста файдалана. Башка көрәшчеләр белән килешеп, Карәхмәтне һәр көн «батырга» калдырып киләләр. Печән базары халкы шау килә. Чираттагы көрәшләрдән соң һәр көн Печән базары кибетләре алдында төркем-төркем халык җыела.

[4] Ашлык һәм Агач базары — хәзерге Бауман районы Колхоз базары һәм Борһан Шәһиди урамы биләп торган урыннар.

[5] Хәзер бу урам Борһан Шәһиди исемендә.

Алар Карәхмәтнең «батырлыклары» турында сөйлиләр. «Бүген Карәхмәт белән Зайкин[6] арасында кискен көрәш була. Барырга кирәк», — диләр Печән базары халыклары. Ләкин ул көнге «кискен көрәш»тә бер як та җиңә алмый. «Кискен көрәш»нең киләсе җомга көнгә кичектерелгәнлеге игълан ителә. Карәхмәт тагын берничә батырны ега. Печән базары татарлары аңа чиксез куанып акча җыялар һәм Карәхмәткә алтын сәгать бүләк итәләр.

Ләкин печән базары татарларының бу шатлыгы озакка бармый. Русларның батыр көрәшчеләреннән берсе Карәхмәтне хур итеп ега. Карәхмәт аренада биш минут чамасы хәлсезләнеп ята.

Тукай үзенең поэмасында:

Пәһлеванга бирделәр алтын сәгать,

Чылбыры юк, белмимен, нидер сәбәп... —

дигән сүзләре белән Карәхмәтнең соңгы көрәшләрдә җиңелгәнлегенә ишарә ясады.

Г.Тукай бу вакыйгаларга нык колак сала, төркем-төркем җыелган халык арасында йөреп, үзенең «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» исемле поэмасына материал туплый.

Шагыйрь үзенең бу поэмасында дини хорафатлардан, Печән базары татарларының мещанлыкларыннан көлә, бозык элементларның азгынлыкларын, җәмәгать «эшлеклеләренең», корсак артыннан куып, халыкны алдауларын фаш итә.

Көзге көннәрнең берсе иде. Артист Габдулла Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппа[сы] Вознесинский урамдагы «Купеческое собрание» дигән клубта (Островский урамында хәзерге Яшь тамашачылар театры бинасы[7]) әдәби-музыкаль кичә үткәрергә билгеләде. Бу кичәдә шагыйрь Габдулла Тукайның «Печән базары...» поэмасын беренче тапкыр буларак тамашачылар алдында укыячагы игълан ителгән иде. Клуб залы тамашачылар белән шыгрым тулы булды.

Габдулла Кариев ул көнне мине кичәнең администраторы итеп билгеләде. Кичә башланыр алдыннан Г.Тукай минем күземә каушаган төсле булып күренде. Бераздан ул минем яныма килде дә:

— Син тикшереп кара әле. Клубка Карәхмәт үзе килмәде микән? — диде.

Мин аңа:

— Килсә ни булган соң? — дигәч, Тукай:

— Син аның йозрыкларын күрмәдеңмени? Һәрберсе су чүмече кебек бит. Сәхнәгә кереп берәрне кундырса, көлең күккә очар. Андый көрәшчеләр хулиганлыклар эшләүдән курыкмыйлар. Ресторанда булган вакыйганы оныттыңмыни? Полицейскийлар барыбер аның ягында булганнар, — диде.

Чыннан да, шул чакларда Казан рестораннарыннан берсендә булган вакыйга минем хәтеремә төште. 4-5 көрәшче, ресторанга кереп, күп кенә ашаганнар, эчкәннәр. Соңыннан официант акча сорый башлагач, савыт-сабаларны, кайбер мебельләрне ватып бетергәннәр.

Мин тикшереп карагач, Карәхмәтнең клубка килмәгәнлеге мәгълүм булды.

— Карәхмәт килмәгән, — дип әйткәч, Тукай тынычланып китте.

Җыр, музыка номерлары тәмам булгач, Г.Тукай сәхнәгә чык-

[6] Зайкин Иван Михайлович (1880-1948) — рус көрәшчесе, очучы, цирк артисты.

[7] Островский урамы, 10 нчы санлы йорт: Казан дәүләт яшь тамашачылар театры.

[8] Г.Тукайның «Төрекчәдән»

ты. Халык аны көчле алкышлар белән котлады. Шагыйрь «Печән базары...» поэмасын зур дәрт белән укыды. Һәр куплетны укыган саен, көлгән тавышлар яңгырап торды. Тамашачылар Тукайга бик нык кул чаптылар. Якын танышлары, сәхнәгә кереп, шагыйрьнең кулын кыстылар.

«БОЛГАР»ДА

Шагыйрь Г.Тукай берничә еллар буена Печән базарындагы «Болгар» номерларында торды. Аның кечкенә бүлмәсе өченче катта аш һәм чәй залы белән янәшә, тәрәзәсе Кабан күленә караган иде.

Аның бүлмәсенә һәрвакыт кеше килә. Күңел ачар урыннары булмаган яшьләр, эшсез кешеләр кичләрен карта уйнарга җыелалар, бүлмә эчен тәмәке төтене белән тутыралар. Ләкин Тукай үзе аларга кушылып уйнамый. «Болгар» коридорында моңаеп, җырлап йөри, шигырьләрен иҗат итә. Кайвакыт бүлмәгә кереп, карта өстәленә күз сала. Әгәр дә банк тотучы үзенә ошаган кеше булса:

— Миңа да бер сумга карта өләш, — ди.

Әгәр отса, отышны алып чыгып китә, бүтән уенга катнашмый. Оттырса, аңлырак кешеләр аннан акча түләтмиләр. Бүлмәсендә уйнаткан өчен, шуны «квартира хакы» дип уйлаганнар булырга кирәк. Картачылар уйный бирәләр. Тукай шул арада залда ашап, чәй эчеп яки бераз «пирәшләп» ала.

Төн урталары җиткәч, «клуб» халкы тарала. Тукай бүлмәсенә кайтып яза башлый яки шул төтенле һавада йокларга ята. Шундый күренешләрне миңа күп тапкырлар очратырга туры килде. Мондый һавада тору, һичшиксез, Тукайның сәламәтлегенә зур зыян китерде.

Мин Тукайдан кайчакта:

— Нигә бу картачыларны куып чыгармыйсың? — дип сорый идем.

Тукай миңа:

— Ялгыз калсам, эчем поша. Мин кешеләрдән башка тора алмыйм, — дип җавап бирә иде.

***

Элекке вакытта яшьләр арасында 1 нче апрель көнне берберсен алдашу гадәт булып киткән иде. Бервакыт искечә 1 нче апрель көнне Галиәсгар Камал, мин һәм тагын берничә кеше «Йолдыз» газетасы редакциясендә утырып тора идек. Шул арада Г.Тукай килеп керде дә Г.Камалга:

— Сезне телефонга чакыралар, — диде.

Г.Камал ашыга-ашыга «Болгар» номерларының икенче башындагы 7-48 нче номерлы телефон буенча сөйләшергә дип китте. Чөнки редакциянең үз телефоны юк иде. Бераз вакыт үткәч, Г.Камал башын бөгеп әйләнеп керде. Г.Тукай исә:

— 1 нче апрель! — дип кычкырып көлде.

Шуннан 1-2 сәгать үткәч, Г.Камал Печән базарыннан әйләнеп кайтты да, ишектән керүгә, җитди кыяфәт белән:

— Урамнан үтеп бара идем. «Көфер» чатына каршы чатта күп халык җыелганын күрдем. Якынрак барсам, ни күзем белән күрим: Шакир Мусин күлмәген салып, магазины алдына чыгып утырган. Үзе нәрсәдер мыгырдана, куллары белән күкрәгенә суга. Җүләрләнгән булырга кирәк, — диде.

Шакир Мусин Печән базарының иң юан сәүдәгәре иде. Ул бик азапланып йөри. Күп вакыт магазины алдында урындыкка утырып, узган-барганны карап тора. Г.Тукай аны «Габделкафа» (ягъни җилкә колы) дип йөртә иде.

Шулчакта редакциядә утырып торган Г.Тукай Г.Камал сүзләрен ишеткәч тә аны-моны сорашып тормады, тиз генә кепкасын киде дә, «кызыкны» карарга дип урамга чыгып китте. Озак та үтмәде, ул әйләнеп кайтты һәм Г.Камалга:

— Ник алдадың? Шакир Мусин фил шикелле үзенең урынында утыра ич, — диде.

Г.Камал аңа:

— Бәйрәм ашы кара-каршы. 1 нче апрель икәнен оныттыңмыни? — диде.

Г.Тукай шул чакларда үзенең:

Тән үстерсәң — җиһанда, һич тә шиксез фил булу мөмкин;
Укып рухыңны гали әйләсәң — Җибрил булу мөмкин[8], —

дигән шигырен язган иде.

Буржуаз наширләр Г.Тукай шигырьләрен басарга талашып алсалар да, аңа бик аз акча түләделәр. Ул ачлы-туклы тора иде. Шунлыктан иҗат эше белән бергә Әхмәт Урманчиев һәм Якуб Хәлилинең «Китап»[9] ширкәте нәшриятында экспедитор булып та эшләргә мәҗбүр булды.

Г.Тукайның бер күзенә тары бөртегеннән бераз зуррак ак төшкән иде. Мин аннан аның сәбәбен сорагач, ул болай диде:

— Кечкенә чагымда Яңа бистәдә мине тәрбиягә алган Мөхәммәтвәли гаиләсендә торганда күзләрем бик авырта башлады. Мине врачка күрсәтүче булмады. Тик бер им-том итүче карчыкка күрсәттеләр. Ул шикәрне чүкеч белән ваклады да минем күзләремә салды. Шуннан соң күзләрем бигрәк тә авырта башлады. Чак кына сукыраймыйча калдым. Шуннан бер күземә ак төшеп калды...

НӘФРӘТ ҺӘМ МӘХӘББӘТ

Реакционерларга һәм ысулы кадимчеләргә каршы, эксплуататорларга һәм ишаннарга каршы Г.Тукай килешмәүчән көрәш алып барды. Ул үзенең әсәрләрендә карагруһларны, ялагайларны, хыянәтчеләрне, сатлыкҗаннарны каты тәнкыйть итте. Ләкин аның иске режимга каршы язган күп кенә әсәрләрен цензура кыркып кыскарта иде. Г.Тукай «Бәянелхак» газетасын, аның редакторы Әхмәтҗан Сәйдәшевне бигрәк тә яратмады. Ул, безнең белән бу газета турында сөйләгәндә, «Бәянел кх тфү» дип куя иде. Түнтәр авылында яшәгән Ишми ишаннан[10], Троицкидагы Зәйнулла ишаннан[11], ысулы кадимче Мөхәммәтҗан Хафиздан, «Госмания»[12] мәдрәсәсендә күп еллар буена хәлфә булып яткан, соңыннан төймә, тарак белән сәүдә иткән, шулчакта ысулы

(«Тән үстерсәң...») дигән шигыреннән. Басмаларында беренче юлда «һич тә» түгел, ә «бер дә».

[9] Автор ялгыша. Чөнки «Китап» ширкәте, билгеле булганча, Габдерахман Галләм улы Дәүләтшин (?-?) тарафыннан оештырыла.

[10] Ишми ишан — Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев (1842-1919) — Вятка губернасы Малмыж өязе (хәзерге Татарстан Республикасы Балтач районы Урта Көшкет җирле үзидарәсе) Түнтәр авылы ишаны, дин эшлеклесе, традиционализм тарафдары. Большевиклар тарафыннан атып үтерелгән.

[11] Зәйнулла Рәсүлев (Рәсүли) (1833-1917) — дин эшлеклесе, ишан. 1859 елда Троицкида мәдрәсә тәмамлагач, Оренбург губернасы Верхнеуральски өязе Акхуҗа авылында мөдәррис һәм имам-хатыйп була. Рәсми хакимият тарафыннан 1873 елда Кострома шәһәренә сөргенгә җибәрелә. Аннан азат ителгәч, 1884 елдан Троицкидагы 5 нче мәчетнең имамхатыйбы, шунда

җәдиткә каршы «Китабел-хәдид ли ибтилел-җәдид» («Җәдитне юк итү өчен тимер китап») яки «Мисыр каргасы» исемле китап язган аксак Низамидан көлеп, Г.Тукай күп кенә шигырьләр язды.

1905 нче елгы революциядән соң башланган реакция елларында патша хөкүмәтенең кушуы буенча Казанда ысулы җәдидче Галимҗан мулла Галиевнең Указы алына[13]. Карьерист Галимҗан мулла, Указсыз калгач, канаты каерылган кош шикелле аптырап йөри. Үзенең Указын кайтарып алу өчен теше-тырнагы белән тырыша. Шул максат белән ул реакцион «Бәянелхак» газетасын чыгарган Әхмәтҗан Сәйдәшев һәм аның улы Мөхәммәтҗан Сәйдәшев дәүләт Думасына депутат булып сайлану өчен үзенең кандидатурасын куя. Ишан Галимҗан мулла аны сайлату өчен үзенең мөритләре аркылы агитация алып бара. Губернаторлар, полицмейстерлар белән таныш һәм дус булган Сәйдәшев исә аның Указын кайтарту артыннан йөри. Ләкин Мөхәммәтҗан Сәйдәшев Думага сайлана алмый. Менә аларнаң корсак интереслары өчен татар милләтен сатарга йөрүләрен фаш итеп, Г.Тукай «Казан мулласы һәм булачак депутат» дигән шигырен язды. Ул бу шигыренең ахырында:

Очтылар хәзрәт, вәкил — күп очтылар,
Тик, тәэссеф[14], — җиргә егълып төштеләр, —

дигән сүзләре белән аларның хурлыклы рәвештә җиңелгәнлекләрен күрсәтте.

Г.Тукай «Бер газета идарәсе хәленнән» дигән шигырендә «Бәянелхак» редакциясе турында язды.

***

Шул ук вакытта Г.Тукай азатлык сөючеләрне, революционерларны чын күңелдән дус күрде. Ул татар большевигы Хөсәен Ямашевны бигрәк тә яратты. Хөсәен Ямашев аның бүлмәсенә еш кына килә, үзенең ягымлы сүзләре, ачык чырае белән тыңлаучыларны һәрвакыт үзенә тарта иде. Г.Тукай аның турында «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре» һәм «Янә бер хатирәм» исемле шигырьләр язды.

«Янә бер хатирәм» дигән шигырендә Г.Тукай болай ди:

Мин — кунакчыл бер җыручы, миндә — бар ярлы-гидай,
Ханәмә яшьләр килә һәм сәүдәгәр, бай угълы бай.

Ул бәлӛнд[15] мәрхүм дә килсә, мин сизә торган идем:
Күктән иңгән, ханәмә килгән шикелле тулган ай.

Бервакыт Г.Тукай миңа болай диде:

— «Бәянелхак»та эшләүче Исхак Бикчуриннан[16] сак була күр. Юк-бар сүзләр ычкындырма. Ул провокатор икән. Үзенең байтак танышларын охранкага тотып биргән. Аны миңа Хөсәен әйтте...

Аксак Исхак Бикчурин чыннан да шулай булып чыкты. Ахырдан ул үз-үзен асып үтерде. Аның бүлмәсеннән «Төкерәм мин дөньяга» дип язылган кәгазь табылды.

Г.Тукайга үзенең әсәрләрен укучылардан һәрвакыт бик күп хатлар килә иде. Кайсылары гүзәл шигырьләре өчен аңа рәхмәт белдерәләр, кайберләре шигырь язып, Г.Тукайдан төзәтеп бирүне үтенәләр иде.

Беркөнне ул миңа чит шәһәрдәге бер кыздан хат алганлы-

ук «Рәсүлия» мәдрәсәсен нигезли.

[12] «Госмания» мәдрәсәсе хәзерге Тукай урамындагы 3 нче санлы ике катлы кирпеч йортта була. Аны 1867 елда сәүдәгәр Җиһанша Бикмөхәммәт улы Госманов (1817-?) төзеттерә. Совет хакимияте вакытында анда ир балалар мәктәбе эшли.

[13] Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Баруди (Галиев) (1857-1921) үзе нәшер иткән «Әд-дин вә-л-әдәб» (1906-1917) дини һәм әхлакый журнал битләрендә панисламистик фикерләр таратуда гаепләнеп, 1908 елда ике елга Вологда губернасына сөргенгә җибәрелә.

[14] Тәэссеф — үкенеч.

[15] Бәлӛнд — биек.

[16] Исхак Хәлил улы Бикчурин (1886-1913) — журналист һәм тәрҗемәче.

[17] «Амур» номерлары — элекке Печән базары комплексында кунакханә тибындагы бина (Мәскәү ур., 70). 1864 елда сәүдәгәрләр бертуган Ибраһим (1806-1886) һәм Исхак (1814-

гын сөйләде. Г.Тукай аңа җавап язган. Бу татар кызы Г.Тукайга энҗедәй шигырьләре өчен, бигрәк тә хатын-кызлар турында күңелгә бик ягымлы сүзләре өчен рәхмәт әйткән. Тагын бер хатында, әгәр шагыйрь риза булса, аңа гомерлек юлдаш булырга (кияүгә чыгарга) теләгәнлеген аңлаткан иде.

Г.Тукай бу турыда дулкынланып болай диде:

— Бу кыз күңелгә бик ягымлы сүзләр яза. Аның белән якыннан танышсаң да ярар иде. Үземә гомерлек юлдаш табасым килә. Номерда торудан да туеп беттем инде. Ул чакта квартирада торыр идем. Биредә һава бик начар, сәламәтлеккә зарар китерә...

Берничә вакыттан соң теге кыз Г.Тукайга үзенең рәсемен дә җибәргән. Ул аны миңа күрсәтте. Матур гына татар кызы иде.

Г.Тукайның татлы хыялы тормышка ашмады. Г.Тукай әсәрләрен бастырып күп табышлар алган буржуаз наширләр аңа бертөрле дә ярдәм күрсәтмәделәр. Аны үз вакытында бер башкорт авылына булса да кымызга җибәрә алмадылар. Курорт турында сөйләп торасы да юк инде.

БӘХИЛЛӘШҮ

1912 нче елда Г.Тукайның сәламәтлеге бик начарланган иде инде. Бервакыт мин аны врач Зарницын квартирасына алып бардым. Ул туберкулёз авыруларын дәвалый торган оста врач иде. Бервакыт врач Зарницын «Шәрык» клубында туберкулёз авыруы һәм аңа каршы көрәш турында лекция укыган иде.

Зарницын Г.Тукайның күкрәген тыңлап карады, кайбер дарулар алырга рецепт язып бирде. Май, сөт һәм башка туклыклы азыклар ашарга, күбрәк яхшы, саф һавада йөрергә киңәш бирде.

Аннары Г.Тукай: «Кымызга барам», — дип, Уфа, Петербург (Ленинград), Троицк якларыннан әйләнеп кайтты.

1912-1913 нче ел кышында мин аны «Амур»[17] номерларында (Киров урамында Сталин район Советы башкарма комитетының хәзерге бинасы[18]) очраттым. Ул аның бер бүлмәсендә[19] тора иде. Үзе тагын да ябыккан. Ләкин яшәүдән өметен өзмәгән иде. Г.Тукай:

— Бу арада үземә бераз көч килгәнен сизәм. Тереләмме икән? — диде.

Ләкин, кызганычка каршы, аның авыруы көчәйгәннән-көчәя барды. Ахырдан ул Клячкин больницасына (Островский урамында Яшь тамашачылар театры каршындагы хәзерге бала табу йорты[20]) керде һәм 1913 нче елның 2 (15) нче апрелендә шунда үлде. Бу кайгылы хәбәр халык арасына бик тиз таралды. Сөекле шагыйрьне кояшлы матур көндә күмделәр. Аның гәүдәсен татар каберлегенә илткәндә ун меңнәрчә халык озата барды.

Татар дөньясы горизонтында туган якты йолдыз сүнде. Ләкин аның эше сүнмәде.

Г.Тукайның гүзәл әсәрләре, аның иҗади традицияләре безнең арабызда мәңге яшәр. ■

1885) Гобәйдулла уллары Юнысовлар акчасына табыш йорты буларак төзеттерелә. 1886 елда, мирас буларак, Габделкәрим (1853-1928) Исхак улы Юнысов милкенә күчә. Бертуган Мөбарәкша һәм Гарәпша Рамазановлар тарафыннан арендага алынып төзекләндерелә һәм 1912 елның 26 октябрендә рәсми рәвештә мосафирханә итеп ачыла. Зәкәрия Садретдин улы Садретдинов(1880-1930) наширлегендә һәм мөхәррирлегендә 1912 елның 10 декабрендә чыга башлаган бер партия программасына да иярми торган көндәлек тәрәккыйпәрвәр «Кояш» газетасының редакциясе шунда урнашкан була (өченче кат, 40 нчы бүлмә). Анда Г.Тукай 1913 елның февраль аена кадәр эшли.

[18] Хәзер анда төзекләндерү эшләре алып барыла.

[19] 9 нчы бүлмәдә.

[20] Хәзерге вакытта ул бинада Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы.



«ҮЗЕМ ДӘ, БАЛАЛАР ДА ЯЛАНГАЧ...»

Лена Тябина,
Г.Тукай әдәби музееның өлкән фәнни хезмәткәре

ТР Милли музее фондында Зариф Бәширинең бер хаты

Габдулла Тукай әдәби музеена килүчеләрне шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты гына түгел, аның даирәсе һәм фикердәшләре дә кызыксындыра. Музейда Тукай замандашлары – Ф.Әмирхан, Г.Коләхмәтов, Г.Камал, Г.Ибраһимов, М.Гафури, С.Рәмиев, Х.Ямашев, С.Сүнчәләй, Я.Моради, Ш.Әхмәрев, М.Бигиев, Г.Исхакый турында азмы-күпме мәгълүмат бар. Соңгы елларда фәнни хезмәткәрләр шагыйрь белән бәйле башка шәхесләрне өйрәнүгә дә зур игътибар итә, экскурсантларга моңарчы исемнәре бик азларга гына билгеле булган Кәбир Бәкер, Николай Ашмарин, Иван Харитонов, Исмәгыйль Рәмиев, Зариф Бәшириләр турында да сөйләп узалар. Г.Тукай әдәби музеена килүчеләр Зариф Бәшири белән бәйле бер генә экспонат күрә алалар – бу 1916 елда Оренбургта төшерелгән фоторәсем. Фотода «Шура» журналын чыгаруда катнашкан язучылар – Н.Думави, З.Бәшири, С.Рәмиев, С.Сүнчәләй, М.Гафури.

Габдулла Тукай замандашлары белән бәйле һәр экспонат музейга килүчеләрдә зур кызыксыну уята. Шундыйларның берсе ТР Милли музее фондларында саклана, ул Габдулла Тукайның замандашы, шагыйрь һәм язучы Зариф Шәрәфетдин улы Бәшири (1888-1962) хаты. Хат 1944 елның 12 ноябрендә Уфа шәһәрендә язылган, адресаты — Гази Кашшаф (1907-1975), язучы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче. 1944 елда ул «Совет әдәбияты» журналының баш мөхәррире булып эшли, шул ук вакытта Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе вазифасын да башкара.

Хатның тулы эчтәлеге:

«Гази иптәш!

Сез Уфадан киткәч, мин картны бөтенләй онытгыгыз. Минем әлеге Гафури һәм Тукайлар турында язган истәлекләр турында да, «Ил карты» турында да бернәрсә дә язмадыгыз. Минем әхвәл болай тора: Язучылар союзы «Ил карты»н ике кешегә рецензиягә биргән иде. Яхшы рецензия бирделәр. Аннары союзның шагыйрьләр секциясендә укылды. Анда да нигезендә яхшы табып, беркадәр төзәтеп, үзгәртеп бастырырга булдылар. Шунда бирелгән киңәшләр буенча мин аны өчкә бүлеп, өч китап иттереп яңадан эшләдем. 1 — «Ил карты», 2 — «Ил мәхәббәте» (аерым шигырьләр рәвешендә), 3 — «Ил баласы» (балалар өчен).

Совет, партиянең законы, установкасы буенча инде мин Союзга восстановить ителүгә хаклы булсам да, Сәйфи Кудаш һаман да «тегә-бу» дип сузып, читкә этеп килә.

Тормышым һаман да шулай: көненә өч йөз грамм икмәктән башка бер төрле дә паек ала алмыйм. Утыртып, алган бәрәңгем дә юк. Бер полин утын юк. Үзем дә, балалар да ялангач.

Саулык мәсьәләсе шулай: йөрәк авыруы өстенә ачлык та кушылгач, инде бөтенләй шешенеп аяктан егылдым. Докторлар: «Яхшы ашау, җылылык, тынычлык кирәк», — диләр, нык дәваланырга кушалар. Ләкин миндә аларның берсе дә, бер генәсен булдыруга көч тә, шараит тә юк. Шуның өчен дә якын киләчәктә үлемнән башка нәрсә күренми дә, көтә дә алмыйм.

Өч балам 1939 нчы елдан бирле фронтта. Берсенең үлүе турында рәсми хәбәр алынды. Берсе 1941 нче елда пленга төшкән булган икән. Ул немец лагереннан качып, Одесса областена килә дә өч елга якын шунда партизаннар арасында эшли. Одесса областен Кызыл Армия алгач, ул шуларны каршы алып, тагын сугышка керешә. Ләкин, ни сәбәпледер, үзе хат язса да, үз адресын җибәрми. (Шул улым Казанда фин.-эконом. вузны бетергән иде.) Өченче, зур улым — старший лейтенант, алдагы позициядә артиллерист булып батыр сугышуы өчен, өч тапкыр орден ала. Ләкин хәзер каты контужен булып госпитальгә керә. Алардан, мәгънәви шатлыктан башка, матди ярдәм юк. Һәрхәлдә Ватан сугышының, шул өч геройның кырык ел буена әдәбият өстендә булган карт аталары бүген кайбер аерым личностьләрнең капризлары аркасында ачлык-ялангачлык белән салкын кухняда үлем көтеп ята.

Мин Сездән шуны үтенәм, Сез мөмкин булса, әгәр минем Тукай һәм Гафури турындагы нәрсәләрем ярарлык табылган булсалар, институт белән сөйләшеп, шулар өчен акча җибәртә алмассыз микән. Ул акчаның гына мине үлемнән коткаруына, килеп өлгерүенә түзем җитмәсә дә, бәлкем, алар балаларыма укуга йөрүләренә ярдәм итәр иде. Чөнки алар ялангачлыктан укуга йөри алмыйлар.

Бәшири З.Ш. 12/XI. 1944
Уфа»

Зариф Бәширинең бу хаты аның советлар чорындагы тормышын һәм иҗатын күз алдына тулырак итеп китерергә мөмкинлек бирә.

Хатта исеме аталган Сәйфи Кудаш (1894-1993) Ватан сугышы чорында Башкортстан Язучылар берлеге идарәсенә җитәкчелек итә. Авторның *«...мин Союзга восстановить ителүгә хаклы булсам да»* дигән юллары аның 1938 елда гаепсезгә хөкем ителеп биш елга хезмәт белән төзәтү лагерена эләгүе, аннан кайткач та рәсми оешмаларның әдипкә булган мөнәсәбәте үзгәрмәве турында искә төшерә.

«...минем Тукай һәм Гафури турындагы нәрсәләрем...» — бу хатирәләрнең Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич турындагы бүлекләре Уфада «Агыйдел» журналында басыла. 1961 елда З.Бәшири кулъязмасын Татарстан китап нәшриятына тапшыра. Ләкин китап аның үлеменнән соң гына дөнья күрә. Бик нык кыскартылган бу истәлекләр, Гали Халит тарафыннан эшкәртеп-редакцияләнеп, «Замандашларым белән очрашулар» исеме белән 1968 елда Татарстан китап нәшриятында 7000 данә тираж белән аерым китап булып басылып чыга. Әлеге истәлекләр, тулыландырып, 2014 елда Зариф Бәширинең шул ук нәшриятта чыккан «Сайланма әсәрләре»нә (төзүчесе Ркаил Зәйдулла) дә кертелгән.

...Габдулла Тукайның үзе исән чакта басылмаган шигырьләреннән берсе — «Җавап» шигырен әдәбият белгечләре нәкъ менә Зариф Бәширигә мөнәсәбәтле дип саный.

Шигъре Лермонтов вә Пушкин — олуг саф диңгез ул.
Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул.

Син дә шул диңгез ярында, и агу йоткан көчек!
Телләрең сузган буласың, җитми, җитми, кит күчеп.

Кит хәзер, ләкин китәрдә, сал колак бу сүзгә бер:
Барчы, эт, гомрең буе шул күктә өч йолдызга өр!

Шигырь Тукай кулъязмалары арасында табыла, беренче тапкыр 1926 елда «Г.Тукай шигырьләре» җыентыгында басыла. 1930 елда «Яңалиф» нәшриятында чыккан «Г.Тукай әсәрләре»нең 2 нче томында да, 1955 елгы «Г.Тукай әсәрләре»ндә дә шигырьнең язылу елы итеп 1911 ел күрсәтелә. Шигырь узган гасырның 70 нче елларына кадәр Галимҗан Ибраһимовка атап язылган, дип санала. XX гасыр башы татар матбугатын фәнни тикшерү нәтиҗәсендә, Тукайның 1975, 1985 еллардагы әсәрләрендә, 2011 елгы академик басмасында шигырьнең язылу вакыты итеп 1908 ел күрсәтелгән һәм аның Зариф Бәширигә мөнәсәбәтле булуы турында язылган.

Егерме ике яшьлек Тукайны үз иҗатына әүлиялардай бәя бирергә этәргән Зариф Бәширинең әлеге ике битлек хатын асыл нөсхәдә күрергә теләсәгез, Г.Тукай әдәби музеенда эшли торган «Без сугышта юлбарыстан көчлебез...» дигән күргәзмәгә рәхим итегез. Бәшири хаты, бәхәссез, музейның яңа экспозициясендә дә урын алырга лаек. ■

/Түгәрәк өстәл/

«ТУКАЙНЫ ӨЙРӘНГӘНДӘ СЕНСАЦИЯ АРТЫННАН КУАРГА ЯРАМЫЙ!»

9 февраль көнне «Безнең мирас» журналы редакциясендә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу уңаеннан «түгәрәк өстәл» оештырылды. Чарада Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИның Язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчесе **Илһам Гомәров**, тукайчылар төркеме башлыгы, профессор **Зөфәр Рәмиев**, филология фәннәре кандидатлары **Рифә Рахман**, **Заһир Шәйхелисламов**, «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директор урынбасары **Сөмбел Таишева** һәм «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директор киңәшчесе, шагыйрь **Равил Фәйзуллин**, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон**, тарих һәм текстология бүлеге мөхәррире **Ленар Гобәйдуллин** катнашты .

Ләбиб ЛЕРОН. Без Тукайдан ераклашкан саен Тукайга якынаябыз. Бу киләчәктә дә шулай булыр, чөнки Тукай — милләтебезнең титаник шәхесе.

Илһам ГОМӘРОВ. ТФАнең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Тукайның 130 еллыгына билгеле бер әзерлек белән килде. Габдулла Тукайның энциклопедиясен эшләү, аның академик басмасын алты томда чыгару, юбилее көннәрендә Халыкара төрки академия белән берлектә конференция үткәрү һ.б. эшләрне санап үтәргә мөмкин булыр иде. Берничә ел дәвамында институтның Язма һәм музыкаль мирасны өйрәнү үзәге карамагында тукайчылар төркеме эшләп килә. Алар шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын, аның даирәсен, чордаш әдипләрнең иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнә. Төп максатыбыз — Тукай энциклопедиясен басмага әзерләү. Ул инде төгәлләнеп килә һәм тиздән, юбилей көннәрендә китап укучыларыбызга ирешер, дигән өметтә калабыз.

Зөфәр РӘМИЕВ. Тукай энциклопедиясе турында сүз моннан 22 ел элек башланды, ләкин ул вакытта әлеге эш институт планына кертелмәде, эш акрын барды. Нил Юзиев исән вакытта энциклопедиядә урын алырга тиеш дип табылган мәкаләләрнең исемлеге төзелә башлаган иде. Анда 2800 мәкалә исеме аталды. Нил Юзиев 1996 елның сентябрендә бакый дөньяга күчте һәм үзенең бер хатында бу эш сиңа кала инде, дип язып калдырды. 1998 елда исемлекне редакцияләп, кулъязма хокукында бастырып тараттык. Әгәр дә эш 1998-2005 еллардагы темпта гына дәвам итсә, ел саен 100ләп мәкалә язылачак, шулай итеп бу эш дистә елларга сузылачак иде. 2007 елдан соң бу мәсьәләгә ныграк игътибар итела башланды һәм 2015 елга мәкаләләр язылып бетте. Аларны язуда безнең институт, КФУ галимнәре — барлыгы 140лап белгеч катнашты. Аларның кайберсе 2-3, кайберсе 4әр, ә Рифә Харрасова, мәсәлән, 150ләп мәкалә язды. Мәкаләләрдә яктыртылган һәр мәгълүматның Тукайга мөнәсәбәте булырга тиешлеге шарт итеп куелды.

Энциклопедия 8 тематик юнәлешкә караган материалны эченә ала. Беренчесе — Тукайның һәр әсәрен шәрехләү, аларга төпле анализ бирү. Әсәр кайчан язылган? Ничек язылган? Тематикасы, пафосы, поэтикасы нидән гыйбарәт? Шагыйрьнең 780ләп әсәре бар. Монда шигырь дә, поэма да, мәкалә, хатлар, истәлекләр һәм сәяхәтнамәләр дә — ба-

рысы да кирә. Бу юнәлеш иң җитдие, дип уйлыйм, чөнки монда әдәбиятны белергә, әдәби әсәргә бүгенге көн югарылыгыннан фәнни анализ да ясарга кирәк, Тукай совет чорындагы кебек социалистик реализм кысаларында түгел, ә яңача шәрехләнә. Икенчедән, Тукай иҗаты белән бәйле бай әдәби процесс, әдәби проблемалар бар. Жанрлар системасы, дин, балалар әдәбияты һ.б. Өченче юнәлеш — Тукайның замандашлары һәм туганнары. Шагыйрьнең туганнары күп…

Илһам ГОМӘРОВ. Туганнары буларга теләгән кешеләр дә күп…

Зөфәр РӘМИЕВ. Әйе, теләгән кешеләр дә күп, ләкин инде без энциклопедиягә бары тик Тукайның үзе белән мөнәсәбәттә булган һәм аның турында истәлекләр язган туганнарын гына тәкъдим иттек.

Дүртенчесе — Тукай һәм татар әдәбияты. Йөзләгән шагыйрь Тукай турында шигырь-поэма язган, пьесалар бар. Бу бүлек — каләм әһелләренең Тукайга мөнәсәбәте турында. «Бәдәвам» һәм Тукай, Каюм Насыйри һәм Тукай кебек темалар да биредә яктыртылды.

Бишенчесе — Тукай башка телләрдә һәм чит телле авторларның Тукайга мөнәсәбәте. Азәрбайҗан, Казакъстан, күрше мари, чуваш, башкорт булсын, барысын да чагылдырырга тырыштык.

Алтынчы юнәлеш — Тукай һәм музыка, Тукай һәм театр, Тукай һәм рәсем сәнгате. Сәнгать белгечләренең күбесе татарча язмау сәбәпле, байтак мәкаләләре рус теленнән тәрҗемә кылынды. Терминнарны тәрҗемә итү, аны татар укучысына аңлаешлы итүдә дә проблемалар килеп туды.

Тукай һәм истәлекле урыннар. Нил Юзиев 1981 елда басылып чыккан Лермонтов энциклопедиясе үрнәгендә эш итәргә, дип әйтеп калдырган иде. Әдәби топография дигән төшенчә бар. Әйтик, Тукай Англия, Төркия, Җаек, Арчаны телгә ала. Бу топонимнарның Тукайга бәйләнешен дә чагылдырырга тырыштык.

Соңгы бүлек Тукайны өйрәнүче галимнәр турында. Шагыйрьне өйрәнүнең йөз еллык тарихы бар. Аларның Тукай фәненә керткән өлешен билгеләп үтү дә зарур.

Энциклопедия бөтенесен дә хәл итте, бар әйбергә дә ачыклык кертте, дип әйтергә ярамый. Ул Тукайны өйрәнүнең бүгенге дәрәҗәсен чагылдырырга тиешле иде. Һәр мәкалә ахырында библиография бирелде, ягъни бу укучыга нидер эшләр өчен юнәлеш биреп тора.

Рифә РАХМАН. Энциклопедиянең бөтен нәрсәне хәл итеп бетерә алмавы, беренче чиратта, әлеге хезмәткә әзерлек елларында төзелгән белешмәлеккә кайтып кала. Ул ахыргача уйланып бетә алмаган, чөнки һәрвакытта да, теге яки бу тикшерү объектын махсус өйрәнми торып, аның сүзлеккә керергә хаклымы-юкмы икәнлеген ачык кына әйтү мөмкин түгел. Үзеңә алынган тема буенча мәкалә язу эшенә әзерләнә генә башлыйсың, материалның бөтенләй юклыгы ачыклана да куя. Кайчак шагыйрьнең Тукайга багышланган бер шигыре генә бар, ә исеме белешмәлеккә кертелгән, шул ук вакытта йөзләп текст иҗат иткәннеке — юк. Моның объектив сәбәпләре дә бар. Зур күләмле бу хезмәт озак еллар дәвамында төзелгән. Шул арада яңа буын каләм ияләре иҗат һәм фән мәйданына аяк баскан, Тукай хакында берсеннән-берсе матур әсәрләр иҗат итәргә өлгергән. Без вакыт мөмкинлек биргән дәрәҗәдә яңа исемнәргә тукталдык, шулар хакына кайбер мәкаләләрне кыскарттык.

Энциклопедияне әзерләү барышында шактый галимнәребезнең дөньядан китүен истән чыгарырга ярамый. Алар белән алган темалары да киткән… Язып тапшырганнарына исә өстәмәләр, төзәтүләр кертергә туры килде. Чирек гасыр эчендә фәнебезнең алга сикерешен дә күз угында тотарга туры килә. Болар барысы да соңгы елларда төзелгән хезмәт коллективының

эшен катлауландырып җибәрде. Әле бит үзебезнең дә заманыбыз фәне ирешкән яңалыкларны ныграк чагылдырасы килә. Шулай итеп, кайчандыр әзерләп куелган текстлар да кат-кат эшләнде. Төркемебезнең кечкенәлеген исәпкә алыгыз. Әнә шул берничә кешелек төркем, әлбәттә, институт һәм академия, бүлек җитәкчелеге, башка бүлекләрнең гаять зур ярдәме белән, йөзәр кеше хезмәт иткән энциклопедия институтлары озак еллар дәвамында башкара торган персоналийны эшләп чыкты.

Энциклопедия төзегәндә иң кыены — материалларның бит, юл саны белән чикләнүе. Әлбәттә, ике-өч юл, хәтта бит эчендә дә теге яки бу әсәрнең тарихын, әдәби бәйләнешләрен, бүгенге әдәбиятка тәэсирен язып, анализлап бетерә алмыйсың. Проблеманың катлаулыгына бәйле рәвештә, аерым мәкаләчекләргә зуррак урын бирелүгә карамастан, һәр теманы ахыргача ачу — мөмкин булмастай бер эштер.

Тукай төркеменең эшчәнлеге энциклопедия белән генә дә чикләнми бит әле. Анда керми калган фикерләрне аерым мәкаләләрдә чагылдырабыз. Шулай да күләмле язу безнең галимнәргә хас, дип әйтмәс идем. Күп галимнәр бик аз яза, аз язган өстенә дә, кайвакыт анда Тукайга караган сүз табып булмый. Күп язса, кыскартып, Тукайга кагылышлысын аерып алып булыр иде. Инде дә шактый күләмле язып, шуның Тукайга мөнәсәбәтле дип саналырлык ярты яисә бер бите калмаган чаклар да юк түгел. Бу очракта үзеңнән өстәргә туры килә.

Татар фәнендә энциклопедияләр төзү тәҗрибәсе юклык та үзен сиздерә. Бик танылган галимнәр булсалар да, кайберәүләр тасвирдан ерак китә алмый, биография сөйләү белән шөгыльләнә, бигрәк тә иҗат стиле, аерым әсәргә хас үзенчәлекләрне гомумиләштерү, гомумине таркату, мисал белән дәлилләү сәләтенә ия түгел. Бу төр җитешсезлекләрне, нигездә, үзебез юкка чыгарырга тырыштык. Һәрдаим энциклопедиянең, кыскалыкта — осталык, дигән татар халык мәкаленә нигезләнеп төзелсә яхшы икәнлеген дә аңлатырга туры килде. Аның каравы, киләчәктә шушы төр хезмәтләр языла калса, без инде аңа әзерлек баскычын үттек, беренче коймак булса да, хезмәт шактый уңышлы чыкты, дип саныйм.

Энциклопедияне башкару вакытында туган кыенлыкларның чираттагысы — безнең дөресне язарга әзерлексезлегебез. Гасыр дәвамында ялганнарга күнеккән фәнне дөрес юлга бастыру шактый кыен. Бу Тукай фәненә дә карый. Без бит аны гел идеаллаштырырга тырышабыз. Иман юкка чыгып, идеаллар сүнеп барган заманда болай эшләү — начар да түгел кебек, әмма аның зыяны да шактый. Кеше ялганнарга, матурларга өйрәнә, куркакка әйләнә. Зур фәндә дә, матур әдәбиятта да шәхестән җансыз кеше, курчак ясау килешми, шагыйрь моның белән үзе дә ризалашмас иде, дип уйлыйм. Бар яктан камил дип саналган Чехов әнә үзен идеаллаштырып сурәтләүчеләрне күрә алмаган, иң якын дустына, минем хакта тискәре яз, дип фатиха-васыятен әйткән, һәм ул шулай эшләгән дә: аның уңай яклары янәшәсендә барлык җитешсезлекләрен ачкан, тискәре геройларында әдипнең нәкъ менә үзен тасвирлавын әйткән. Онытмагыз: талантлы кеше бервакытта да идеал булмый, чөнки ул һәр идеалның гомере вакытлы икәнлеген бик яхшы чамалый.

Бу ноктадан караганда, гомер буе дөреслеккә омтылган чит ил галимнәре бәхетле: алар хакыйкать өчен бар булганча язган, сөйләгән аркасында, кешегә зыян килә, дип башларына да кертеп карамый. Икенче яктан, нәкъ менә шул сәбәпле аларның Тукай фәненә керткән өлеше дә зур. Мәсәлән, Михаэль Фридерихның «Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы» китабы — капиталь һәм уникаль

хезмәт. Монда Тукай бөтен барлыгы белән ачыла, ә бит шул ук вакытта автор, шагыйрьне тасвирлаудан битәр, аңа мөнәсәбәт тарихын яза. Икенче төрле әйткәндә, автор бөек шагыйрьгә мөнәсәбәткә мөнәсәбәт белдерә, безне, фәнебезне гаделлек үлчәвенә куеп бәяли. Әлеге китапны укыганда, сәясәт тегерменәнә су коеп яшәгән татар әдәбияты гыйлеме өчен бит кызара.

Без бит әле дә һәрнәрсәне дөрес итеп яза алмыйбыз, чөнки алман галименекеннән аермалы иҗтимагый шартларда, рухи кысынкылыкта яшибез. Рухи зәгыйфь каләмнән хакыйкатьне көтеп буламыни?! Аның иясе күзенә бар нәрсә башка төсләрдә күренәчәк. М.Фридерих исә демократик ил кешесе һәм Тукайны идеаллаштырмыйча, реаль тормыштагыча, бары тик документларга, язма мираска таянып бәяли. Кызганыч ки, әнә шундый әсәрләр чыкканда да, без аларны зурлап язмыйбыз, куркабыз, читләп үтәбез.

Энциклопедиянең тулы булмавы революциягә кадәрге татар вакытлы матбугатының тиешле дәрәҗәдә сакланмавына да бәйлелеген әйтмәгәнмен икән. Теге яки бу номерны без чит төбәктән эзләргә тиеш. Казанда кайбер вакытлы матбугатның сакланышы чит илдәгегә караганда да азрак. Шәхси архивларда бардыр яисә булгандыр һәм, бәлки, таралгандыр да инде алар. Киләчәктә әле мөһаҗирлектәге татар гаиләләренең яисә татарны өйрәнгән галимнәрнең шәхси архивлары белән танышып, теге яки бу журнал, газета саннарын эзләп тә табарбыз. Кыскасы, татар тарихына, әдәбиятына һәм вакытлы матбугатына бәйле теге яки бу ак таплар Тукай темасының киләчәктә дә фәндә актив каласын сөйли.

Соңгы вакытта бер кызык һәм сәеррәк тә күренеш күзәтелә. Журналистлар, шушы юбилей уңаеннан берәр сенсацион әйбер тапкансыздыр бит инде, сөйләгез әле, диләр. Яңа әйбер табылган икән, димәк, энциклопедиягә кергән, матбугатта чыккан һәм яңалыгын югалткан инде. Без кеше шаккаттыру артыннан чапмыйбыз — сенсация эзләүне максат итмибез. Чын фән сенсацияләргә корылмый, ул эзлекле өйрәнүләрнең нәтиҗәсен чагыл-

дыра. Сенсация эзләү — сары пресса шөгыле. Дөрес, миңа кайберәүләрнең Тукайгамы, башкагамы карата әйткән яисә язган фикере сенсация кебек тоела, чөнки дәлилсезлеген күрәм. Үз карашымча, шагыйрь теге яки бу кызга атап әсәр язганда да, әлеге кыздан мәхәббәт объекты ясарга кирәкми. Мин менә мондагы теләсә кайсы ирне ышандырырлык итеп яратуымны шигырьдә аңлатып бирә алам, лирик мингә үз холкымны салам һәм башкалар. Язсыннар инде аннан соң киләчәк буыннар, бер «түгәрәк өстәл»дә Рифә Рахман берьюлы биш-алты иргә гашыйк булган да, гомер буе оныта алмыйча үзе генә яшәгән дип. Тукайның шәхси тормышында бу планда казынуларны, күпертүләрне яратып бетермим һәм сенсация эзләү рәвешендә кабул итәм дә.

Табышларга килгәндә, хәзер дә алар була, булыр, ә шулай да бөтен тормышы, язмышы, иҗаты татар халкының күз алдында үткән Тукай турында моңа кадәр әйтелмәгән нинди шаккаттыргыч фикер булсын?! Инде шагыйрь белән бер чорда яшәгән туганнары, дуслары вафат. Бары тик моңарчы мәгълүм булмаган кульязма яки басма материал табылырга, туган-тумачасының биографияләре ныграк ачылырга һ.б.лар мөмкин. Кайберләренең истәлекләрендә бәхәсле урыннар бар икән, әнә аларга үз мөнәсәбәтеңне ачыклау, дәлилләү юлы, мәсәлән, фәндә яңа сүз булып тоела ала. Әйткәнемчә, бу төр табышларны сенсациягә, ягъни Тукайга бәйле теге яки бу карашларны, дөнья картинасын тамырдан үзгәртүче күренешкә кертмим. Тагын бер әйтәм: Тукайны өйрәнгәндә сенсация артыннан куарга ярамый! Күбрәк чын-асыл чыганаклар белән эш итәргә һәм объектив нәтиҗә ясарга кирәк!

Ләбиб ЛЕРОН. Рифә ханым, сез — язучы да бит әле, ике төрле каләмегезне бергә кушарлык эшләр дә планлаштыра алыр идегез.

Рифә РАХМАН. Әлбәттә! Җитәкчеләр белән сөйләшеп, «Тукай һәм татар әдәбияты» дигән китап әзерләүне институт планына керттек. Билгеле, миңа аны энциклопедиянеке кебек коры фәнни тел белән дә башкаруның бернинди авырлыгы юк, әмма ул укучыга кызык булмаячак. Аның өчен мәкаләнең эссе рәвешен алуы, үтә фәнни фикерләрнең яисә бер сызык рәвешендә язылган сүзләрнең шулардан читкәрәк китеп уйланулар белән чиратлашып баруы кызык.

Ләбиб ЛЕРОН. Күрәм, тукайчылар, нигездә — өлкән буын.

Рифә РАХМАН. Гел алай гына түгел. Яшьләр дә бар. Безнең арабызда *(бүгенге «түгәрәк өстәл»дә — **Ред.**)* бик кызыклы яшь галимә, әле ул диссертация дә язмаган, Алия Мөбарәкшина булырга тиеш иде. Ул фәнни командировкаларда булды, Истанбул, Санкт-Петербург шәһәрләрендәге китапханәләрдә саклана торган Тукайга бәйле язмаларны эзләде. Табылган материаллары да киләчәктә матбугатыбызда дөнья күрер, дип өметләнәм.

Ләбиб ЛЕРОН. Соңгы елларда Тукай шәхесе һәм иҗаты буенча нинди яңа фактлар ачылды? Хәл ителмәгән бәхәсле мәсьәләләр бармы?

Заһир ШӘЙХЕЛИСЛАМОВ. Тукайның иҗатын барлыйсыңмы, шәхси тормышын өйрәнәсеңме, документлар булмаганлыктан, нинди дер мөгез чыгарырга ярамый. Истәлекләргә ышансаң, Тукай Яңа Зимничә авылына барып велосипед та калдырган, Башкортстанга барып Зәйтүнәне дә эзләп йөргән. Һәркемнең Тукайны якын итәсе, һәркемнең Тукайны байрак итәсе килә, һәркем Тукайның чабуына ябышырга тели. Андый әйберләрдән, мәкаләләрдән, колак торгызгыч сенсацияләрдән сак булырга кирәк. Башкортстаннан Мирсәй Гариф китап та чыгарды. Ул фәлән-фәлән кешеләрдән ишеткән вакыйгаларны

язган, шуларга үзенең фантазиясен дә кушып җибәргән. Шаккатыризмнардан азат булырга кирәк.

Фаҗигале язмыш кичергән Тукайның публицистик әсәрләренә килгәндә, беренче чыганаклар, кульязмалар сакланмаган. Фәкать «Пожар вакытында кызгану» дигән сатирик мәкаләсенең фрагменты бар. Димәк, без Тукай үзе исән вакытта чыгарылган газета-журналларга таянырга тиеш булабыз. Шуларны укып, сүзен сүзгә өйрәнеп, гарәп, фарсы, төрек сүзләренә аңлатма бирәбез. Аннан ул — мәдрәсә бетергән шәхес, Коръәнне дә, динне дә яхшы белгән. Фикерен куәтләр өчен әсәр эченә гарәпчә берәр гыйбарә кертеп җибәрә. Ул Коръәнчә килеп чыкмас, әмма эчтәлеге ягыннан аять-сүрәләргә туры килер. Андый моментларда безгә тәрҗемә итәргә, татарчасын бирергә, гарәпчәсен төзәтергә, киселгән урыннарын газета нөсхәләреннән табып тулыландырырга туры килде. Алты томлы академик басманың 4 томы басылып чыкты. 3 нче томда 1904-1907 еллардагы материаллар. Монда яңалык дип шуны әйтергә мөмкин: фәндә псевдонимнар астында Тукайныкы дип исбат ителгән 19 әсәр беренче тапкыр шушы томга керде. Шуның 18е ышаныч белән, 19 нчысы, Камил Мотыйгый турындагы биография генә бераз шикле. Фәрит Яхин да, Мәсгут ага Гайнетдин дә бу әсәрне Тукай язган ди, әмма башка фикерләр дә бар. Шунлыктан без аны «Тукайныкы булырга мөмкин», дигән бүлеккә урнаштырдык. 4 нче томны Зөфәр Мөхәммәтшин әзерләде. Ул исә шагыйрьнең хәзерге укучыга мәгълүм булмаган 20 әсәрен тапты.

Рифә РАХМАН. Төшеп калганнары турында да әйтегез әле…

Заһир ШӘЙХЕЛИСЛАМОВ. «Коръән укысам» шигырен Тукайныкы дип язып чыкканнар иде, Н.Юзиев аны Миргазиз Укмасыйныкы булуын искәртте. «Сөй халыкны, сөй гомерне…» дигән шигырь турында ничә еллар инде Тукайныкы дип сөйләделәр, ә ул Сәгыйть Сүнчәләйнеке булып чыкты. Хәтта Бакудан килеп тә бер ханым бу әсәрне Тукайныкы дип доклад укып китте…

Рифә РАХМАН. Без дә онытабыз аны кайчакта…

Заһир ШӘЙХЕЛИСЛАМОВ. «Коръән», «Экспромт» — Нәҗип Думави, «Ах идәрсәм» — Әхмәт бәк, «Кызганыч бабай» — Хөсәен Абушаев Атлаши шигырьләре.

Тукайның нәсел-нәсәбен ачыклый торган бердәнбер документ — ул да булса муллалар язган метрикә кенәгәләре. Анда да сораулар туа. Метрикәдә әнисе Минсафа дип язылган, ә без Бибимәмдүдә дип беләбез. Бабасының ике хатыны барлыгын беләбез, әмма, метрикә кенәгәсенә карасак, бер үк көндә башка исемдә ике хатын аерганлыгын күрәбез.

Зөфәр РӘМИЕВ. Бер көнне ике хатынны аерырга кирәк бит, җәмәгать…

Заһир ШӘЙХЕЛИСЛАМОВ. Зиннәтулла карт турында бер мулладан калган алты балалы хатынны алды, дип яздылар. Мондый фактлар, казына башласаң, искиткеч күп… Мине нәрсә генә сөендерә: энциклопедия басылып чыкса, анда гаҗәеп кызык материаллар бар. Бу киләчәктә галимнәр өчен төпле нигез булып торачак, шуңа таянып алар тагын да алга китәчәкләр. Энциклопедия — Тукай фәненең бер баскычы.

Ләбиб Лерон. Алга таба Тукайга бәйле яңа чыганаклар табылырмы?

Зөфәр РӘМИЕВ. «Фикер» газетасының 1907 елда 15 саны чыга, шуның 3 санының хәзергә кадәр табылганы юк. Күптән түгел Петербургта булдык, анда да эзләдек, әмма ул саннары табылмый. Башка җирләргә дә язып карадык. Уңай җавап юк…

Минем Казакъстандагы Гурьевкага (Атрау) барасым килә. Андагы Абдулловлар Тукайга, Җаекта яшәгәндә, акча белән ярдәм итеп торган. Нин-

ди кеше булган алар? Аннары профессор Нәфыйков Тукайның хатлары Саҗидә Галиевада, Зәйнетдиновада бар, дип язды. Алар 1961 елда Ташкентка күчеп киткән, диде. Менә шуның эзенә төшәсе иде. Гомумән, Тукай чоры кешеләренең нәселләрен табуны дәвам итәргә кирәк. Без менә Кәлтиев турында язарга җыенабыз. Бу шәхеснең нәсел-нәсәбе бардыр бит инде? Аның өчен эзләнергә, Җаекка барырга кирәк. Тукайга мөнәсәбәтле Хәсән Самакаев дигән шәхес бар. Казанда Илгизәр Самакаев дигән рәссам барлыгы мәгълүм, ачыклый торгач, ул аның оныгы булып чыкты.

Илһам ГОМӘРОВ. Безнең үзәктә Тукай фонды бар. Анда Тукайның үз кулы белән язган хатлары, записькалары, кулъязма шигырьләре, чордашлары язган истәлекләр, документлар саклана. Тукай төркеменә эшләргә берникадәр җиңеллек тә булды, чөнки үзебезнең кул астында байтак документ бар. Башка бер генә архив, китапханә дә Тукайның моның кадәр асыл нөсхәдәге язмалары белән мактана алмый.

Нәсел-нәсәпне тикшерүдә дә максатчан эш алып бару шарт. Моның өчен ревизия документларында казынырга, метрикә кенәгәләре белән эшләргә кирәк. Минем уйлавымча, шагыйрь нәсел-нәсәбенең 7-8 буынын өйрәнү әллә ни проблема түгел. Әлбәттә, көч һәм вакыт сорый.

Зөфәр РӘМИЕВ. Тукаев фамилиясенең кайдан килүе әлегә кадәр ачыкланмаган. Энциклопедиядә бу мәсьәлә буенча төрле фикерләр әйттек, әмма төгәл мәгълүмат юк. Кушлавычның 1850, 1858 еллардагы «ревизская сказка»ларын карадым. Анда Тукаев фамилияле кеше юк. Мөхәммәтгарифка указ биргәндә дә аны «Мөхәммәтгалимов» дип язганнар. Аның әтисен «Шәмсетдинов» дигәннәр. Уфада 1830 нче елларның метрикә кенәгәләре сакланган. Анда Кушлавыч авылыныкы да бардыр.

Ләбиб ЛЕРОН. Гомумән, Тукайның шәҗәрәсе бармы?

Зөфәр РӘМИЕВ. Энциклопедиядә шагыйрьнең шәҗәрәсе турында кайда нинди мәгълүмат бар, барысын да искәрттем, әмма Зәкия Рәсүлова 1986 елда чыгарган Тукай шәҗәрәсен, беркадәр искәрмәләр китереп, күчереп басу белән генә чикләндек. Бу шәҗәрәне тулыландырасы, ялгыш урыннарын төзәтәсе бар, ләкин кулыбызда әлегә әзер материал шул. Бу юнәлештә башкаларның да эзләнүләре билгеле.

Рифә РАХМАН. Пермьдәге вариант…

Зөфәр РӘМИЕВ. Пермь вариантын да карадык. Ул Зиннәтулланың Барда ягындагы нәсәл-нәсәбенә караган мәгълүматларны эченә ала. Нәҗип Нәккаш, Сармандагы Дамир Гарифуллин төзегән шәҗәрәләр дә игътибарсыз калмады. Мәкаләнең азагына Марсель Әхмәтҗанов берничә кешедән язып алган, Тукай шәҗәрәсенә беркадәр ачыклык кертә торган мәгълүматларны версия рәвешендә бирдек. Анда Тукайның нәселе ерак Мәгъдән кенәзләргә барып тоташа, диелә. Ә җитди әзерләнгән шәҗәрә юк.

Рифә РАХМАН. Тукайга бәйле нинди генә проблемага килеп терәлсәң дә, һәрберсе бер китап язуны сорый.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Тукай — милләтнең алтын баганасы. Әгәр без аны югалтсак, үзебезнең дә югалуыбыз мөмкин. Тукай бәхетле язмышлы кеше, чөнки йөз елдан артык Тукайны оныттырмадылар. Хәтта Мәскәү дә оныттырмады, менә сезгә Тукаегыз, рәхәтләнегез, сеңдерегез, нурында коеныгыз… «Рус белән гомер кичердек сайрашып…» Шул җиткән…

Зөфәр РӘМИЕВ. Һәм чынлыкта шулай булып чыкты да…

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Шуңа күрә дә бик күп бөек шәхесләр күләгәдә калды. Тукайның дистәләгән замандашлары тиешенчә өйрәнелмәде, хәтердән җуела язды.

Без Тукайны хәзер милләтне саклар өчен нинди формада файдалана алабыз? Хәтерләсәгез, узган гасырның 50-60 нчы еллардагы татар вакытлы матбугатында Тукай турында шигъри бәхәсләр басылды. Әдипләребез Тукайны ничек аңлыйлар? Тукайның асылын, ул күтәргән мәсьәләләрне бүгенге әдәбиятта безнең талант ияләре ничек дәвам итә һәм алга таба ничек дәвам итәргә? Дәвамчанлык булганда гына без Тукайны максималь дәрәҗәдә «сыгып» кала алабыз. Шул юнәлештә эшләгәндә без Тукайны да, халыкны да күтәрә алырбыз, дип уйлыйм.

Сөмбел ТАИШЕВА. Күп яшьләр интернетта утыра. Габдулла Тукайга багышланган махсус сайтның хәле мөшкел, ул искерде, заман таләпләренә җавап бирми. Бүген безгә Г.Тукайның иҗатын профессиональ дәрәҗәдә өйрәнгән кешеләрдән ярдәм кирәк. Порталның рәсемнәр белән булуы шарт. Төрле рәссамнарның, шәмаил осталарының да иҗаты сайтта бирелер. 1913-1920 елларда Тукайның беренче китапларына ясалган рәсемнәр булса да, без кызыксынып карар идек. Балетлардан өзекләр дә сайтның дәрәҗәсен күтәрә. Яшьләрне текст белән генә җәлеп итеп булмый, аларга рәсем, видео, смартфоннан тыңларга аудио да кирәк. Гомумән, Тукайның заманча, затлы сайты булырга тиеш.

Ләбиб ЛЕРОН. Бер идея — «Шүрәлиада». Бу темага байтак әйберләр бар. Шүрәлегә кагылышлы риваять, пьеса, җырлар, шигырьләр, рәсемнәр бик күп. Менә аларны бергә туплыйсы иде. Мәдәният министрлыгы ничә ел «Ягымлы Шүрәле» конкурсын оештыра. Районнарда Шүрәле бәйрәмнәре бар… Болар нигезендә энциклопедик зур китап эшләп буладыр, дип уйлыйм. Бу эшне бергә-бергә башлап җибәрсәк бик яхшы эш килеп чыгар иде, бәлки Тукайның киләчәктәге юбилеенда кунакларга бүләк итәр өчен саллы гына хезмәт тә булыр.

Зөфәр РӘМИЕВ. Бу юбилейга татар галимнәре, җәмәгатьчелек, институт нәрсә белән килде соң? Татар әдәбияты белемендә беренче мәртәбә алты томлы академик басма әзерләнде. Ул — Тукайныкы. Әлегә кадәр бер генә әдипнең дә академик басмасы юк! Икенчедән, татар тарихында аерым шәхес турында беренче энциклопедия төзелде. Бу эшләр текстология, әдәби мирасны өйрәнү фәненең җитди казанышы булып бәяләнер.

Ләбиб ЛЕРОН. Галимнәрне, язучыларны, укытучыларны сөендерерлек бер хезмәт булсын инде.

Рифә РАХМАН. Шулай дип эшләдек, эшлибез. Алай да энциклопедия чыкканнан соң, күп кешедә сорау туарга мөмкин: ни өчен минем исем монда юк? Объектив сәбәпләрен алда да санадым инде. Төркем төзелгәч, мәкалә исемлеген булдыра алганча яңарттык: шәхесләрнең Тукай исемендәге премия алуын, хәзерге әдәбиятта зур урын тотуын, иҗатында Тукайның ни дәрәҗәдә чагылыш табуын исәпкә алдык. Аннан, элеккеге тарихи шәхесләр турында язып бетерүне кайгырту сәбәпле, бүгенге чор әдипләрен тулысынча иңләргә вакытыбыз калмады. Энциклопедиягә өстәмәләрне киләчәктә барларбыз әле. Лермонтов энциклопедиясенең дә 1998 елгы яңа басмасына күпмедер өстәмәләр, үзгәрешләр кергән. Тукай энциклопедиясе чыкты да, бар да өйрәнелеп бетте, әйтәсе сүз әйтелде, шуның белән эш тукталыр, дип уйламыйм. Тукайны өйрәнү — институтның мәңгелек эш юнәлеше булачак, дип өметләнәм.

Ләбиб ЛЕРОН. 130 еллыкка, шөкер, энциклопедиясе дә, томлыклары да әзерләнде, әмма эш тәгәлләнми. Тукай, аның иҗаты чиксезлек булып калыр.

«Түгәрәк өстәл» утырышы барышында яңгыраган чыгышларны, фикер-тәкъдимнәрне, фоторепортажны (сайтта) ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ: «БУ МИЛЛӘТНЕ ХОДАЕМ БӘХЕТЛЕ ИТСЕН»

Шәехҗан Фәния Хуҗахмәт

Тукайга сүз кушарга кыймый озак, бик озак йөргәндер ул. Аның һәр язганын кат-кат кабатлагандыр. Биш томлыгын яттан белгәндер. Ул гел аның белән сөйләшеп йөргәндер. Бөтен җаны, калебе Тукай белән тулгандыр. Моннан нәкъ ун ел элек таң атканда йокысыннан уянгандыр да, госел коенып, ак күлмәген киеп, ният кылып, ап-ак кәгазьгә текәлеп, кулына каләм алгандыр да: «Әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ, хәзрәти Тукай!» – дигәндер.

Нәкъ менә шулай шагыйрь Зиннур Мансуров «хәзрәти Тукай» дип аңа эндәшә. Сезгә Аллаһының сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын дигән сүзләр аның йөрәгенә һәм иҗатына ачкыч булгандыр, Тукай аны үзенә якын җибәрә. Арада нәкъ бер гасыр ята. Аруланып, пакьләнеп төн белән көн аерылганда, кара белән ак тартышканда Аллаһ колын ишеткән кебек, шагыйрь шагыйрьне ишетә. Сәламен ала, әле алай гынамы соң, барлык муллалардан уздырып җавабын әйтеп сала.

«Әсгадәкә Аллаһы фид-дарәйни… (Аллаһ сезне һәр ике йортта да бәхетле итсен)», — ди Тукай. Бу инде җавап кына түгел, бу пароль, бу ризалык, бу инде теләсә ни сора, барысына да җавап бирәм, дигән җаваптыр. Ә бит сорау бирүче белән җавап бирүче бер яссылыкта булганда гына эчкерсез, чын күңелдән сөйләшеп буладыр.

Безнең бүгенге көн муллалары кебек, Мөнкир илә Нәнкир хәзрәтләренең вазифасын үз өстенә алып, Тукай белән әңгәмәләшеп утырган Зиннур Мансуров һич тә сезгә, Тукайга «Раббың кем? Пәйгамбәрең кем?» дип сөальләр бирергә җыенмый. Шулай да… ди. Тукай исә фәрештәләр каршысында гына түгел, шагыйрь каршында да, Аллаһ алдында һәм дә татар халкы алдында үлемсез иҗатында, китапларында йөз ел үтеп эч серләрен ача, сөйләшә, җавап тота.

Исемем — Габдулла — Аллаһ бәндәсемен, Аллаһның барлык колларыннан иң оялчаны мин, ди. Иseме лә исеме — Аллаһының иң яратканнарыннан! Кемгәдер дога кыласы килгәндә дә этисенең исемен онытсалар, Габдулла улы диләр. Кайчандыр Габдулла улы булып та, «Мин кол түгел» иде, диләр. Әгәр болай әйтүчеләр Тукайны белсә, лаек булса да, булмаса да, этием Габдулла дип кычкырып йөрер иде. «…Колларыннан иң оялчаны мин», — ди Тукай. Динебездә оялчанлык иң мактала торган сыйфатларның

Исемем – Габдулла – Аллаһ бәндәсемен, Аллаһның барлык колларыннан иң оялчаны мин, ди. Исеме лә исеме – Аллаһының иң яратканнарыннан!

берседер. Хәдисләрдә, Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең сөннәтендә «Оялчанлык — иманның яртысы», диелгән. Әнә шул изге сыйфат бүген бик күпләргә җитми. Имансызлык арта. Әдәп, әхлак, оят кими. Алар арасында оятлы булып килгәннәргә бигрәк кыен. Бу байтак кына шагыйрьләребез язмышында да күренә. Аларның да кеше арасында кеше буласы килә. Кызарасы да, оясы да, әйтәсе сүзен озак уйлап торасы да килми. Шул халәттән котыласы килә дә соң. Ничек? Ничек икәнен беләбез, әз генә көчен куеп…

Зиннур Мансуров та Тукай кадәр үк булмаса да, оялчан кеше, Тукай кебегрәк. Шулайдыр, Тукай белән сөйләшә башлаганына да ун елдан артып киткәндер. Шулвакыт эчендә ул Тукай белән йөз мәртәбә генә очрашмагандыр. Бер генә сорау бирү өчен дә күпме әзерләнергә кирәк. Зиннурның да, мең шөкер, шагыйрьлеге шикле түгел, киресенчә, мәртәбәле. Тукай икенче, ул бердәнбер, гади түгел, бердән җиде буын мулла нәселе, кечкенәдән, җиде яшьтән дини белем алган. Зиннур да Коръән, дин, шәригать хөкемнәре өйрәнә. Шагыйрь Тукай белән шагыйрь Зиннур югары ноталарда сөйләшә. Аллаһ барын белмичә, аның колы булмыйча шагыйрь булып булмый. Бүген нәрсә ул шагыйрь булу? Әнә, кайбер бәгъзе бәндәләр хәтта мулла булмакчы. Тукайны танымаган башлары белән аларгамы соң инде? Мәчеттә ничә никах укыганнары белән мактаналар да, сәдака никадәр зуррак булса, шулкадәр үзләрен акыллырак саныйлар. Ишеткәнем бар ике, 20, 30 мең җыелганын, бер чит илдән килүчеләр 1 мең доллар биргәннәр, ди мәчеттә никах укыткан өчен.

Тәүбә, тәүбә, әйттем исә кайттым, муллаларның сакчысы бар. Аларга каршы сүз әйтергә дә, алардан көләргә дә ярамый, аларның казыйлары һәм «хәзрәтем» дип кенә торучы күзәтүчеләре бар.

Тукайның да, Аллаһының иң оялчан колы булу белән бергә, «Би-ик усал» дигән тәхәллүсе булган. Әйтсә, әйткән инде, юк, юк, көлмәгән, бары тик «Туры Тукай» булып кала алган. Мин үземне белә башлаганнан бирле Тукайга битараф кеше түгелмен. Инде үземә лаек ярты гасырдан артык гомер иткәндә, һәр язганын кат-кат укыган идем. Беләм, дип уйлый идем, белүен, бәлки, күп шигырьләрен яттан да белгәнмендер. Ләкин аңламаганмын, бөеклеген күрмәгәнмен, Зиннур Мансуров күрсәтмәсә, мин Тукайсыз каласы булганмын. Хәер, күптән, бик күптән булды ул хәл.

Шәех абый* әңгәмәләрнең беренчесен «Татар мөселман календаре»ның 2008 нче елына, апрель аена куябыз дигәч тә, «нинди оят, хурлык» — чытыр-пытыр каршы чыктым. Юк, дигән булам инде, ник, нәрсәгә, Коръән, хәдисләр, догаларны кысаргамы, халык вәгазь сорый... Юк, юк, бирмибез, бик озын да. Укып караганым юк, ә үзем ничек чәпчим, дивана?! Шәех абый (ирем һәм яратып, хөрмәт белән әйтәм — остазым) акыллы кеше иде ул, күп сөйләшми, сүзен сүз итә, буйсындыра һәм эшләтә, ышандыра белә иде. Бер кичне эшләр беткәч, ашагач-эчкәч, икебез диванның ике башына менеп утыргач, сумкасыннан ике нөсхә «Бу милләтне, Ходаем, бәхетле итсен» дигән язма чыгарды да, берсен миңа бирде: «Мә, укы, — диде, — кычкырып». Мин Зиннур булдым, ул — Тукай. Йә, Хода, булса да булыр икән. Вакыт-вакыт борын мышкылдады, күзгә яшьләр килде. Озаклап, тәмләп, ләззәтләнеп укыдык. Икенче көнне: «Әйдә, тагын укыйк әле», — дидем. Бу юлы инде мин Тукай булдым, ул сораулар биреп торды. Шулай итеп Зиннур Мансуровның Тукай белән беренче әңгәмәсе 2008 нче елны тулысынча календаребызның апрель аена кереп ятты. Әй, шатланды Шәех абый. Тукайны бик ярата иде. Ул да оялчан һәм иманлы иде. Хәтта аның вафаты да өйлә намазына азан әйткәндә, Тукай туган көндә, шигърият бәйрәме башланганда булды. Халыкка шул мөнбәрдән җиткерделәр.

Ә инде Тукай белән беренче әңгәмәле календарь кат-кат басылды. Тиражы да 100 мең иде. Бик күп хатлар килде, телефоннар тынып тормады. Татар халкы үз улын — тугры Тукаен таныды, кабул итте, яратты. Үзем дә Зиннур Мансуровны күргән саен: дәвамы буламы, дип бәйләндем. Шигърияте дә Тукай алдында кызарырлык түгел иде, ул Тукай бүләген шигырьләре өчен алды. Әңгәмәләре дә нәкъ Тукай бүләгенә лаек.

Календаремны халык ярату укый икән, әлбәттә, Зиннур Мансуровның да өлеше бик зур. Чөнки календарем иң күп тиражлы, иң күп тарала. Дөрес, соңгы елларда бөек Тукайны атеист (Алласыз) диючеләр дә, Фәхретдиннәребезгә, Мәрҗаниләребезгә йодрык күрсәтүчеләребез дә календарь чыгара. Тукай да: «Мулла да ахрысы фәрештә түгел, аның да остабикәсе бар, бала-чагасы бар, фатир түлисе бар, ни эшләсен, ачка үлсенме?» — дигән. И-и-и, Габдулла-Габдулла, бүгенге нәфселәрен күрсәң иде әле син аларның...

И-и-и, сөекле укучым, Тукай исән булса, дисеңме? Ә кем әйтте сиңа Тукай үлгән, дип. Әнә бит, 2016 елга әзерләгән календаремда «Наданлык сәбәпле көферга төшү җиңел инде», — ди Тукай. Шунда ук: «Динле булып күренү — бик яхшы бер кәсеп ул. Ихтимал, сез дә шул файдалы кәсепкә керешергә кызыга торгансыздыр, котлы булсын, туганкай, сәүдәгез, кот-

*Миншәех Зәбиров (1932-2009) — күренекле журналист.

лы булсын!» — ди. Бу очракта әлеге сүзләр бары тик календарь чыгарган булып, миңа аяк чалып йөрүчеләргә турыдан-туры кагыла. Чөнки алар календарь укымый, Тукайны белми. Алты ел буена календарьның апрель ае Тукай белән сөйләшүдән генә торды. 2015 елда апрель, май айларында «Тукайча татар кодексы» басылып чыкты. «...Без бөек шагыйребез Габдулла Тукайның бөтен язганнарын халкыбызга мирас кылынган яшәеш дөреслегенә тиңли алабыз, — ди Зиннур Мансуров, — мондый затның классик әсәрләрендәге барлык сүзе генә түгел, хәтта һәрбер ым-ишарәсе газиз милләтенә хезмәт итәргә тиеш». Зиннурны әйтәм, тырышып та караган. Бу хезмәт күп көч, вакыт, аң-белем сорый. Зиннурдан күрмәкче янә бер шагыйрь Тукай белән очрашмакчы булды. Гәзиттә дә чыгарып карады. Бер иҗатташы шундый итеп тез астына китереп типте. Ярый әле, аягында басып калды, егылмады. Иҗатта һәрвакыт оятлы, Тукайлы булырга

«Тукайлы язмышыбызга рәхмәтләр белдерик. Пәйгамбәргә торырлык шагыйребез...»

кирәктер. Ә Тукай бүләгенә лаек булучылар нишли? Тукайны беләме? 80-90-100әр мең тираж белән календарь чыгарган Фәния Хуҗахмәтне беләме? Зиннур Мансуровның Тукай белән сөйләшкәнен беләме? Әйтә алмыйм. Бу апрель аенда тагын халык календарь укый. Укый да, телефоннан шылтырата. Әнә, Арча районыннан бер ханым, исемен дә сорамадым: «Шуларны китап итеп чыгар әле, бер айлык пенсия акчама сатып алып, балаларыма, оныкларыма таратыр идем», — ди.

«Ярар, ярар, чыгарырбыз, — дим. — Аннан соң чыкты бит инде», — дим. Әйе, чыкты, Татарстан китап нәшрияты чыгарды, рәхмәт яусын, бик аз булса да. 2 мең данә нәрсә инде, 5не кибеттән алып кайткан идем, күзгә дә күрсәтмәделәр. Шунысы куанычлы, бер китапта русчасы да бар. Бөек Тукайчы остазыбыз Мөхәммәт Мәһдиевнең кызы Гәүһәр тәрҗемә иткән. Ярыйсы ук күңелгә ятышлы. Ростов-Доннан Салихҗан абый шылтыратты. «Календарьдагы әңгәмәләрне урысчага аударып җибәрегез әле», — ди. «Ярар, ничәне?» — дим. «Ун ярап торыр, күрик, карарбыз...»

Зиннур әйтә: «Тукайлы язмышыбызга рәхмәтләр белдерик. Пәйгамбәргә торырлык шагыйребез...» — ди.

Моннан остарак әйтеп булмастыр. Рәхмәт Сезгә, шагыйрьләр. Тукайның безгә теләгән теләкләре, догалары кабул булсын. «Татарларның бөеклеге, даны сигез кат күкләргә китсен, мәңге, һәрвакыт бу милләтне Ходаем бәхетле итсен!» Галимнәр дә, Шиһабетдин Мәрҗани дә, «Ходай» дип әйтергә ярамый, ди. Ходай урынына Аллаһ дип язасым бик килә. Ярамый, Тукай белән Коръәнгә каләм тидерергә ярамый. Аллаһым безне гафу итсә иде. ■

Рөстәм Килдебәков. «Тукай шигъриятеннән»

Сурәтләрдә – Тукай образы



Е.Шулик. «Габдулла Тукай»

Илдар Әхмәдиев. «Шагыйрь. Тәфтиләү»



Шамил Шәйдуллин. «Тукай әкиятләре»



Бакый Урманче. «Халык шагыйре Г.Тукай»

Павел Бердников. «Тукай»



Нәүфәл Адылов. «Тукай»

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ БЕЛӘН КҮРЕШҮЕМ

Мөхәммәт Гали
(1893-1952)

1911-1912 елларда мин Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укыдым. Шунда укыганда, без иптәшләр белән хәлфәләрдән качып-посып кына «Шәрык клубы»на һәм янган шәһәр театрына спектакльләргә йөри идек. Шулвакытта мин бер-ике тапкыр читтән генә Тукайны күрдем. Беренче тапкыр миңа иптәшләр антракт вакытында «Шәрык клубы»ның фойесында кыска буйлы, чандыр гәүдәле, бөдрәрәк җиткән чәчле яшь бер егетне «менә Тукай шул инде» дип читтән төртеп күрсәттеләр. Ул Фатих Әмирхан коляскасы* янына җыелган яшьләр белән көлеп сөйләшеп тора иде. Аның өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә үк төшеп торган озын тар чалбар, аягында тәбәнәк үкчәле, балтырыннан тотып кия торган шнурсыз резинлы ботинка иде. Без аны иптәшләр белән антракт беткәнче читтән карап тордык.

Икенче тапкыр без аны антракт вакытында театр фойесында кешеләр белән йөргәндә күрдек. Ләкин таныша алмадык.

Минем белән бергә мәдрәсәдә укучы шагыйрь Габдулла Харис, үзенең язган шигырьләрен укып консультация алу өчен, Тукайның номерына баргалап йөри иде. Тукай белән танышасым бик килгәнгә, алып барып таныштыруны аннан үтенергә туры килде. Кешегә әйтмәү шарты

белән, бер барганда ул үзе белән мине дә ияртеп барды.

Без барганда «Болгар»ның өченче катында Тукай тора торган 41 нче номерның ишеге ярык кына булып ачылып тора иде. Г.Харис шакылдатмый-нитми ишекне зуррак ачып башын тыкты да:

— Мөмкинме, Габдулла әфәнде? — диде.

— Ә, синмени әле бу, Харис? Әйдә, кер! — дигән тавыш ишетелде эчтән.

Ишекне яртылаш ачып, ул кереп китте, мин ишек төбендә калдым.

Бераз торгач, Харис:

— Минем бер иптәшем дә бар иде әле анда, — диде.

— Кая соң ул, ник әйтмисең аңа, керсен, — диде Тукай.

Харис, ишектән башын тыгып, мине чакырып алды.

Бер кровать, бер-ике урындык сыярлык кечкенә генә бүлмә. Ашъяулык япкан өстәл, җыелмаган кровать һәм ишек янындагы чөйгә элгән кыска сөлге белән вак-төяк киемнәр һәм ике урындыктан башка бүлмәдә бер җиһаз да юк.

Без килгәндә Тукай яткан булган икән. Мин кергәндә ул, яңа урыннан торып, өстенә ябынып яткан пальтосын чөйгә элеп маташа иде. Туҗуркасын иңбашына салып, урынын рәтләп куйды да:

— Мәдрәсәдәшме? Шәрик үкме әллә? — дип, Хариска карап алып, минем белән күреште.

— Ул миннән бер сыйныф түбән, мин игъдади өчтә, ул игъдади икедә укый, — диде Харис.

— Син дә шигырь язмыйсыңдыр бит? — диде Тукай миңа карап.

— Юк, Габдулла әфәнде, — дидем мин.

— Ярый әле андый гөнаһың юк икән. Менә Харис сабагын да укымый, кыш буе шуның белән саташып йөри бит, — диде көлеп Тукай.

— Алай дәрес ташлап ук йөргән юк ла, Габдулла әфәнде. Менә Мөхәммәт белә инде минем ничек укыганны, — диде Харис, миңа күрсәтеп.

— Юк, сине, малай, начар укый, диләр, ялкауланасың, — ди. Алай ярамый бит ул. Русча да бер дә белмисең бугай син? Частный урок алып булса да, русча укырга кирәк. Болай синең каләмең өметле генә күренә. Укымасаң, рәт чыкмас бит, малай, — диде Тукай.

Харис башын иеп дәшми торгач, ул тагын өстәп:

— Пушкинның берәр шигырен булса да русча оригиналыннан укыганың бармы синең? — диде.

— Бар, — диде бик әкрен генә Харис.

— Ай-һай, бик әкрен әйтәсең, укыганың юктыр. Ичмаса, тәрҗемә аша булса да мәшһүр рус шагыйрьләренең әсәрләре белән танышырга кирәк, шунсыз рәтле шигырь язу буламыни ул, — диде Тукай.

Шул арада ишектән без белмәгән ике кеше килеп керделәр дә, без, урыннарыбыздан кузгалып, аларга урын бирдек. Тукай безгә үзенең кроватена утырырга әйтсә дә, без утырмадык.

Күрешеп чыкканда, Тукай безгә:

— Тагын килегез шулай. Мин әйткәнгә үпкәләмә син, Харис! Минем шундый турырак әйтә торган гадәт бар. Һәрвакыт килеп йөр! — дип калды.

Без чыгып киттек. Шуннан соң мин Тукайны бүтән күрә алмадым. ■

---

* Аяклары йөрмәгәнгә, Фатих Әмирханны, коляскага утыртып, малайлар этеп йөртәләр иде. (М.Гали искәрмәсе.)

ЧЫН КЕШЕ КАДЕРЕ

Мөдәррис Вәлиев

Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!
Габдулла Тукай

Сүзебез – күренекле тукайчы-галим, тирән мәгълүматлы әдәбиятчы-текстолог, үткен каләмле журналист һәм тәнкыйтьче Рашат ага Гайнанов турында. Аның төп язмышы итеп фән юлын сайлавы Фоат Ганиев, башка танылган шәхесләр ватаны булган (гомеренең кичке шәфәгын Казандагы күршебез булып каршылаган галим, язучы Мәхмүт Әхмәтҗанов та әлеге сала егете иде), энциклопедист-галим һәм әдип Нәкый Исәнбәт рухы яшәгән атаклы Нәсибаш авылында (Башкортстанның Салават районы) тууы да сәбәпчедер, мөгаен. Фольклорчы галим, гомерен кыргыз халкына хезмәт итүгә багышлаган Каюм Мифтахов та дөньяга аваз салган нигез нәкъ менә шушында... Әле тагын да гыйбрәтлерәк язмышлар бар: аларның берсе, мәсәлән, Рашат аганың авылдашы, гомерләре буе аралашып, хөрмәт итешеп яшәгән аркадашы, танылган рус шагыйре Михаил Давыдович Львов (Рифкать Дәүләтша улы Габитов).

Рашат Гайнановның нәсел тамыры — мәгърифәтчеләр: бу заманга килсәк, әлеге шәҗәрәнең иң куе ябалдашы укытучылардан гыйбарәт икәнлеген күрербез. Гомумән, үткән гасырның 30—40 нчы елларында да гаиләдә Сталин культы түгел, ә уку культы көчлерәк була. Унбер баланың җидесе югары белем, калганнары махсус урта белем алып, һәркайсы үз өлкәсендә намус белән хезмәт куеп, горурланырлык уңышларга ирешә. Хәер, бу гаҗәпмени: әтиләре Габдерәшит күрше Лаклы авылындагы атаклы ахун Әхмәтсафа мәдрәсәсе шәкерте булган, әниләре Тәкыя инкыйлабка кадәр үк Нәсибаштагы Земская школада укыган (М.Львовның әтисе Дәүләтша агай шунда Рашатның әнисен укытканын да әйтү артык булмас, мөгаен, әле анда ук Нәкый аганың «школьник» булып йөрүе мәгълүм). Сүз уңаеннан, Нәкый Исәнбәт (әнисе — Нәсибаш мулласының кызы) — Рашат Гайнановка ата ягыннан, җырчы Зилә Сөнгатуллина ана ягыннан туганлык җепләре белән бәйләнгән. Аның балаүсмер чагыннан тагын бер нур тамчысы: Тәкыя апа белән Мәхмүт аганың әнисе Рабига апа, шул заманның күркәм йоласы буенча (безнең мишәр якларындагы кебек), «сандугач» кушылганнар, ике якның да балалары каршы якның әнисен «Сандугач апа» дип йөрткәннәр. Югары әхлак мәктәбе менә кайчан ук узылган! Рашатның әтисе исә колхозның беренче бригадиры була. Сугыш башлангач, безгә мәгълүм Сослангир тибындагы хезмәт армиясендә хезмәт итә. Шуннан кайткач, аны колхоз рәисе итеп сайлыйлар. Бу вакытта унсигез яшеннән фронтка киткән кызлары Мөкатдәсәнең

Рашат Гайнанов хатыны Фәния белән. 1975 ел

өчпочмаклы хатларын ут йотып көтсәләр, аннары әле генә урта мәктәп тәмамлаган унҗиде яшәр уллары Рашатны сугыш эченә озатып калалар.

Рашат ага Донбассны азат итү яуларында каты яралана. Унсигез яшендә, Ватан сугышы ордены тагып, гарипләнеп кайткач, туган ягында төрле вазифаларда эшли, шуннан соң (1945-1950) Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Укуын тәмамлау белән, аның, ерак Башкортстаннан килеп, Казанда бернинди «йонлач кулы» (блаты) булмаган яшь егетнең, «Совет Татарстаны» газетасына эшкә җибәрелүе очраклы хәл булмагандыр. Тагын ике елдан ул — «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасының баш редактор урынбасары. Анда да озак эшләргә туры килми, Р.Гайнановны кабат университет чакырып ала, бу юлы инде — аспирант сыйфатында (1954). Рашат студент чагында ук башланган хирыслыгы белән, гасыр башы газета-журналларына кереп чума, архивларны актара, үзе табынган Ф.Әмирхан иҗаты буенча бай материал туплый, мәкаләләр бастыра. Әмма 30-40 нчы еллардан килүче вульгар социологизм тарафдарларының әдәбиятны «сыйнфый күзлектән» генә бәяләве яңадан баш күтәргән чор була бу, әдипне «либераль буржуа вәкиле, милләтче» дип мөһерләгән караш өстенлек ала. Шуңа күрә җитәкчесе Хатип ага Госман булачак галимне алдагы гарасатлардан саклап-яклап: «Әлегә Ф.Әмирханны калдырыйк әле» дип, үзе үк раслаган теманы куеп торырга киңәш бирә. Аспирантураны тәмамлауга, Рашат Гайнанов кабат «Совет Татарстаны»на кайтып эшли. Тиздән (1958-1961) ул — «Азат хатын» журналында җаваплы секретарь, аннары (1961-1965) «Татарстан коммунисты» журналында да шундый ук вазифага күчә. Әйтергә кирәк, бу елларда Р.Гайнанов, туган җанлы абый буларак, алты энесенә һәм сеңлесенә Казанга килеп сыенырга булыша: алар, төрлесе төрле уку йортларына кереп, югары белем ала.

Абруйлы журналист ни өчен алдагы 20 ел гомерен Г.Ибраһимов исемендәге институт белән бәйли соң? Әдәбият, мәдәният буенча туплап килгән

хәзинәсе тынгылык бирми аңа. Фәнни институтта шуларны китап итеп бастырып чыгарып булыр иде дип өметләнә. Ул бит 1905 елдан башлап, чирек гасыр буе нәшер ителгән гарәп язулы газета-журналларны тоташ өйрәнеп чыга, төп өч юнәлештә материал туплый: 1) классиклар иҗаты, 2) XX гасыр башында каләм тибрәткән затлар био-библиографиясе, 3) милли матбугат тарихы. Р.Гайнанов, «беренче кул» чыганаклар белән генә эш итүче текстолог-галим буларак, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан һ.б.ларның

Нәкый Исәнбәт (әнисе – Нәсибаш мулласының кызы) – Рашат Гайнановка ата ягыннан, җырчы Зилә Сөнгатуллина ана ягыннан туганлык җепләре белән бәйләнгән.

яңа күптомлык басмаларын әзерләп бастыру турында хыяллана. Ул төзегән био-библиографик сүзлек 800гә якын каләм әһелен эченә ала. (Бу зур хезмәт институт бастырып чыгарган белешмәлекләрдә, төп чыганак итеп, киң файдаланылса да, әле дә булса тулысынча дөнья күргәне юк... Остазыбыз Мөхәммәт ага Мәһдиев бу очракта әйтер иде: «Бездәме?! Әйе, бездә — булган байлыкка, тарихка, мираска мөнәсәбәт шундый!»).

Текстолог хезмәтенең хикмәтле дә, катлаулы да булуын язып-сөйләп-аңлатып бетерүе кыен. Һәрхәлдә, гарәп язуын танымаган, үз гомерендә архивка аяк басмаган, әдәбият һәм мәдәният тарихын югары кимәлдә белмәгән «галим»нәрнең берсе дә бу хезмәтне башкара алмый.

Үзеннән шактый яшь Миркасыйм Госмановка: «Гомерем җитсә, — ди Рашат ага, — революциягә кадәр татар телендә чыккан барлык гәзит-журналларның тулы исемлеген төзергә дигән ниятем бар... Бөтен Русия империясендә чыкканнарын» («Казан утлары», 2006). Гомере кыскарак булса да, Рашат ага шул хыялына ирешә: басылган урынын, елларын, барлыгы ничә сан булуын, редакторы, нашире кемлеген, кайда саклануын ачыклап, йөзләгән газета-журналның «митрикә»сен тутыра. «Халыклар төрмәсе»ндә милли матбугатның колачы биниһая киң була бит: ул Казан, Уфа белән генә чикләнми, Мәскәү, Әстерхан, Ырынбур, Петербур, Троицк, Сембер, Самар, Җаек, Ташкент, Харбиннарны колачлый... Шул хезмәтен бастыра алмый өстәл тартмасында саклап торганда, — 50 елдан соң гына! — талантлы яшь коллегалары — инде хәзер үзе тирән мәгълүматлы, киң карашлы галим буларак танылган Раиф Мәрданов һәм Фәрит Шәкүров белән берлектә «кибәне очлап» куелган әлеге бибәһа хезмәт «Татар вакытлы матбугаты (1905-1924)» дигән исем белән — «Рухият», соңрак «Милли китап» нәшриятында аерым китап булып дөнья күрә (1999-2000). Хронологик кысалар Рашат аганың тәкъдиме белән киңәйтелә. «Юашрак рәвештә булса да, милли матбугат һәм сүз иреге өчен көрәш 1923-1924 елларда да дәвам итә әле», — дип нигезли ул бу фикерен. Аның канаты астында тагын ике егет «юлга чыгып», инкыйлабтан соң — әле милли матбугатның бугазына Сталин итеге басканчы чыгып өлгергәннәрен дә кушып, җәмгысе 310 исемдәге газета һәм 89 журнал хакында иң кирәкле белешмәләрне туплауга ирешәләр. М.Госманов бу хезмәткә бәя биреп: *«татар тарихы, аның мәдәнияте, катлаулы язмышка ия басма сүзе белән кызыксынучыларның һәммәсе, китапны кулларына алуга ук «Р.Р.Гайнанов» дигән фамилияне укыячаклар. Үзенә күрә истәлек, хәтта һәйкәл дә»*, — дип язган иде. Ә инде әле генә китерелгән саннарга карасаң, бүгенге көнебезгә гыйбрәт тә, дип өстәргә мөмкин...

Рашат ага Г.Ибраһимовның 1 нче

томыннан алып 6 нчысына кадәр (1974-1986) төзүче, искәрмәләр һәм аңлатмалар авторы буларак, хәзергечә әйтсәк, төп рольне уйный. Г.Ибраһимов күптомлыгын фәнни нигездә беренче тапкыр чыгару өчен төзелгән баш редакциянең гыйльми секретаре итеп билгеләнгән Рашат ага «Социалистик Татарстан» газетасында «Олы мирасны барлаганда» дигән концептуаль мәкалә язып бастыра (1972): аның төзелешен билгели һәм «иң тулы җыелмасы булачак» дип игълан итә. Башта 10 том дип уйланылган булса да, соңыннан ул 8-9 томга калдырыла, сәбәбе — хәтта «нык үсеш алган социализм» елларында да шул тормыш өчен көрәшнең башында торган күренекле әдип һәм галимнең хезмәтләрен «сөннәтләп» чыгарталар. Бу хезмәткә галим-голәма, язучылар даирәсендә, матбугатта югары бәя бирелә. Мәсәлән, М.Мәһдиев һәм Р.Мөхәммәдиев: *«Әлеге томнарга кергән хезмәтләрнең... тупланып басылуы... беренче һәм кыю адымнардан саналырга тиеш»,* — дип язалар («Социалистик Татарстан», 1979).

Бу уңайдан, үз вакытында Рашат ага белән «бер сукмактан йөргән» Р.Мәрданов сүзләрен искә төшерү урынлы булыр: *«ул татар әдипләренең күптомлыкларын төзүнең эш принципларын һәм системасын булдырган галим... Рашат ага сокландыргыч дәрәҗәдә фәнгә бирелгән, шуның белән яши торган, уникаль хәтергә ия зур галим иде... Чын галим... (Ассызык безнеке. — М.В.). Фән даирәсендә хөкем сөргән тупас мөгамәләләр, кода-кодагыйлык һәм куштанлык кебек эчпошыргыч мәгънәсезлекләрне күреп, үз җилкәсендә татыган... Тукай әйтмешли, «милләт микроблары» аны да аз тинтерәтмәгән...»* («Шәһри Казан», 2006 ел).

Хезмәттәше, күренекле галим Марсель ага Әхмәтҗанов аны болай искә ала: *«Эшкә бик пөхтә киенеп... йөрүе белән хәтердә калган. Кешеләр белән аралашуы бик җылы, ихлас, һич вакытта тавышын күтәреп сөйләшкәнен хәтерләмим... Милли мираска тискәре мөнәсәбәт хакимлек иткән илдә Г.Ибраһимов һәм Г.Тукайларның академик басмаларын әзерләүгә керешкән татар текстологына кимендә академик дәрәҗәсе бирү кирәк, дип саныйм... Рашат ага 1986 елда институттан... китте. Инде ул... төп эшне эшләгән, татар әдәбиятының текстологиясен югары фәнни дәрәҗәгә күтәргән иде...»* («Шәһри Казан», 2005).

«Сугышта яраланган, бер аягын урый төшеп атлаучы» Рашат агадан «күпләр теге яки бу мәсьәлә буенча аңлаешсызлык килеп чыкса... мөмкин кадәр тулы, төгәл җавап алалар иде, ...хәтта хөсет кешеләр дә», дигәннән соң, Миркасыйм ага аның институттан «китүен» болай тасвирлый: «Көннәрнең берендә «Р.Гайнановны эшеннән чыгарганнар икән», дигән хәбәр килеп җитте. Имештер, вакыт-вакыт эшкә рәтләп йөрмәве сәбәп булган. Бу хәбәр мине бик гаҗәпләндерде. XX гасыр башы татар әдәбияты, татар культурасы тарихы буенча энциклопедик белемгә ия, ...һаман иҗади эшкә сәләтен саклаган шундый кешенең эшеннән чыгарылуы акылга сыймаслык хәл иде... Берәр кеше өчен урын кирәк булса, институтта көн саен эшкә тәртипле йөреп, ...файдалы бер эш тә башкармаган бәндәләр дә буа буарлык бит ләбаса!» — дип ачынып яза ул алда телгә алынган мәкалә-хатирәсендә.

Шулай итеп, Рашат ага, М.Госманов чакыруы белән, юл башына — университетка әйләнеп кайта, 1986-1990 елларда (вафатына кадәр) археография лабораториясендә хезмәт куя. «Татар вакытлы матбугаты» китабы шунда әзерләнә. Тик намус белән хезмәт иткән оешмадан «китү» мәрәкәләре аның гомерен шактыйга кыскарткандыр, дип уйлыйм...

Ниһаять, Рашат аганың иң мөһим хезмәте — ул төзегән Тукай әсәрләре,

дүрт томлык тупланма рәвешендә — 1975-1977, ә биш томлыгы 1985-1986 елларда нәшер ителә. (Игътибар итегез: нәкъ шул 1986 елны аны эшеннән чыгаралар. Кирәксез кешегә шулай җиңел генә әйләнәсең икән ул... Артыңнан гайбәт сөйләп калучылар булганда — бигрәк тә.)

Сибгат ага Хәким, дүрт томлыкның тәүге «карлыгач»лары күренә башлагач ук: *«Г.Тукай үлгәннән соң ул кульязмалар (ягъни әлегәчә табылмаган әсәрләре. — М.В.) 60 ел буена архивта яткан икән, дим, үзләреннән-үзләре табылмаган, дим... Бүген без шушындый бәхеткә ирешкәнбез икән,... Рашат Гайнановка бурычлы, аңа рәхмәт...»* — дип яза («Социалистик Татарстан», 1975).

Рашат ага бу томнарда һәр алынма сүзнең мәгънәсен биреп, шагыйрь әсәрләренә тәфсилле искәрмә һәм аңлатмалар язып, аларның «тәрҗемәи хәл»ен тасвирлый. Боларның бик күбесе беренче тапкыр эшләнә!

Шагыйрьнең аз санлы кульязмаларын яки аларның күчермәләрен табу, шул чор газета-журналларын өйрәнү, Казанда чыгып килгән китапларны һәм көндәлек матбугатны «Теркәү дәфтәре»н «казып чыгару» һ.б.ш. эзләнүләр нигезендә Р.Гайнанов бу әсәрләрнең язылу һәм басылу тарихын өчтән бер өлешкә (!) үзгәртә. Чыннан да, шуңа кадәрге Тукайны өйрәнү фәне ни дәрәҗәдә торган һәм шуннан соң нинди ачышлар ясалган, дигән сорау тууы бик урынлы. Югыйсә, бер буш чиләкне икенчесенә аударып, күпме хәсрәт мөтәгалимнәр дан-дәрәҗәгә үрмәләгән... Башкаларның башына төкерү өчен генә нииндидер кабинет-кәнәфигә ирешү турында уйламау — фәнгә хезмәт итүнең иң намуслы юлы, дип санаган шул тыйнак Рашат ага.

Тукайның 100 еллыгына хәстәрлек башлангач, ул, үзе туплаган материалларга таянып, институт җитәкчелеген яңа басманы биш томда чыгару мөмкинлегенә ышандыра һәм, әлбәттә, «камыт»ын үзе теләп «кия». (Биш томлыктагы әсәрләрне текстологик әзерләүдә галимнең бертуган сеңлесе текстолог Лена Гайнанова да катнаша.) Р.Гайнанов төзегән биш томлыкның саллылыгы хәтта саннар белән дә раслана: ул Тукайның 30га якын тәхәллүсен ача, томнарга 170 «яңа» әсәр өсти.

Искәрмә-аңлатмалар исә — үзләре бер томлык. Рашат аганы шул заманда ук, татарда текстологияне тудырган галим, дип бәялиләр.

Әлеге биш томлык уңаеннан мантыйкка сыя алмаган бер гаҗәп хәлне генә әйтеп китәргә кирәктер. Дүрт томлыкта һәр китапның титул битендә «төзүче» дип акка кара белән язылган булса да, шуңа тагын бер том өстәп чыгарылган яңа тупланмада исә Рашат Гайнанов «текстларны, искәрмәләрне хәзерләде» дип кенә аталган. Бу басманың бары тик иң соңгы — 5 нче томында гына аның төзүче булуы күрсәтелгән. Хәзерләүче — техник хезмәт башкаручыны аңлатса, төзүче — ул бит авторлык хокукына ия зат. Бүген, билгеле, элгәреләрнең хезмәтеннән файдаланып, классикларның бер яки күбрәк томлыкларын чыгарган кешеләр, аңлапмы-юкмы, үзләрен «төзүче», хәтта «идея (проект) авторы» дип атарга оялмыйлар. Асылда бу — фәндә һәм нәшрият гамәлиятендә вакытлыча дилбегә каккан кемсәләрнең йөгәнсезлеге, хезмәтне чынлап та башкарган кешенең йөзенә төкерүе бит!

Рашат аганы рәнҗетүгә өлеш кертү өчен сылтау табылып тора. Әйтик, язучы-галим И.Нуруллинның «Тукай» китабы кульязмасын ул, нәшрият соравы буенча, махсус редактор сыйфатында җентекләп укый, «хаталар өстендә» эшли: Тукайдан китерелгән шигырьләрдәге бихисап хаталарны, шагыйрьнең шәхесенә, замандашларына күләгә төшерү ихтималы булган дәлилсез фикерләрне төзәтә, тарихи фактларда киткән җитди ял-

гышлыклар, аерым сүзләр һәм исем-фамилияләрнең дөрес язылмавы да аны битараф калдырмый. Боларның һәммәсен нәшрият һәм автор үзе рәхмәт әйтеп кабул итә. Китап басылып чыга, тик без анда «махсус редакторы Рашат Гайнанов» дигән сүзләрне генә күрмибез. Нәшриятка язган хатында ул болай диярг мәҗбүр: *«Махсус редактор булмаса, архив документлары белән кем чагыштырып утырыр иде?.. Гомере буе «җыйнап туплаган «байлыгы» булмаса, чагыштыру-тикшерү өчен күпме вакыт китәр иде?! Башкаларга карата гаять тә таләпчән тукаевед-профессорның үзеннән дә «ычкынып киткән» бу кадәр төгәлсезлекләрне кем тотар да, кем төзәтер иде?.. Фараз итик, монда күрсәтелгәннәрнең уннан берсе генә... дөньяга чыкса, авторга да, нәшриятка да... барыбызга да никадәр йөз кызыллыгы килер иде! Ә бит китапның русчасы нәкъ менә шундый хәлдә»*. Тагын шунысын да искә төшерик: «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә чыккан бу хезмәте өчен И.Нуруллин Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була (1982).

Р.Гайнановның зур фәнни тикшеренү нәтиҗәсе булган бай эчтәлекле, өр-яңадан эшләнгән шәрехнамәләрендә Тукай чорының мәдәни тормышы ачыла, күп кенә затларга тулы һәм гадел бәя бирелә. С.Хәкимнең алда телгә алынган мәкаләсендәге сүзләр шул турыда сөйли: «Комментарийлар үзләре генә — бер фәнни диссертация!..» Дүрт томлык чыкканнан соң, язучыларның мәшһүр Тукай клубында бу турыда фикер алышу уздырыла (1977). Әлеге җыенда язучы-галим Мөхәммәт ага Мәһдиев: «Тукайның бу басма томнарын мин арткы яктан укый башладым, — искәрмәләрдән... Бу бит кече бер энциклопедия!» — дип чыгыш ясый. Н.Исәнбәт тә: «Рашаттан башка Тукай буенча белемлерәк кешене күрмим бүгенге көндә,» — дип өсти. Әлеге хак сүзләр кичә генә әйтелгән кебек.

Билгеле, Рашат ага үзендә булган хәзинәне тулысынча «чыгарып салу» мөмкинлегеннән гаҗиз була: кемнәрнеңдер (әйтик, Г.Исхакыйның) хәтта исемен дә телгә алырга ярамый, ә Тукайның очлы каләменә эләккән замандашларын «искелек калдыгы, буржуй» дип кенә тамгаларга рөхсәт ителә. Шулай да «Туган тел»нең соңгы «дини» дүртьюллыгын («...иң элек кыйлган догам...») дистә еллардан соң иң элек Р.Гайнанов «яңгырата». «Китмибез!» шигыренең язылу тарихын, аңарчы булган фаразларны юкка чыгарып, беренче булып дөрес аңлатучы да — ул бит, ул!

Узган елның октябрендә Рашат Гайнановка 90 яшь тулган булыр иде. Инде арабыздан китүенә нәкъ чирек гасыр вакыт үткән икән. Юбилеен беребез дә «сизми калдык». Сәбәбе «пүчтәк» кенә: исәннәрнең – кадерен, үлгәннәрнең каберен белмәгән мохиттә гомер кичерүебез аркасында.

Гүзәлия Тархановaның «Мәдәни җомга» газетасында басылган бер мәкаләсенә игътибар иткән идем (2011). Ул анда, Рашат ага хезмәтләре белән бәйләп, болай яза: *«Хәзерге көндә галимнәр шагыйрь әсәрләренең академик басмасының ике томын әзерләп чыгарды... Рашат абыйның биш томлыгы буенча үземә күптән таныш булган искәрмәләрне күреп сөендем. Димәк, аның тырыш хезмәте бүгенге көндә бастырыла торган томнарның төп нигезен тәшкил итә... Яңа басмада төзүчеләрнең исемнәре арасында Рашат Гайнановныкын күрмәдем. Ә бит аның исеме томнарны төзүчеләр арасында беренче булып торырга тиеш иде,* — ди дә, — *урыс галиме С.Ожегов төзегән аңлатмалы сүзлек һәрдаим тулыланып тора. Бу эш... Н.Шведова тарафыннан башкарыл-*

са да, төп автор буларак, С.Ожегов исеме беренче тора», — дигән чагыштыру китерә. (Шәхсән үзе белән таныш түгелмен, әмма бу юлы әлеге ханымны галимәгә тиң мөгаллимә дип сөйләүләренә ихлас ышандым). Руста авторлык хокукының күптән кануни нигезгә салынганлыгы, ә безнең исә авторлык хокукыннан бихәбәр булуыбыз турында сөйли бит бу.

Тукай энциклопедиясе өчен аз сүзле, әмма дәлилле, саллы мәкалә («Безнең мирас», №1, 2016, 86-87б.) язган Фоат ага Галимуллин моннан утыз еллар элек үк: *«Г.Тукайның әдәби мирасын ачыклауны бөтен фәнни эшчәнлегенең буеннан-буена алып баручы бу галимебез (Р.Гайнанов — М.В.) башкарган эш үзенең камиллеге, киңкырлы булуы белән игътибарны җәлеп итә...»* — дип билгеләп үтә («Социалистик Татарстан», 1984).

Бөек шагыйрьнең 110 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә исә, чит мәмләкәтләрнең танылган фән эшлекләләре дә катнашкан зур җыенда (ул чакта институтның яшь хезмәткәре) Рәмил Исламов, Р.Гайнановны «текстология тармагында эшләүче галимнәргә өлге-үрнәк булып тора» дип бәяләп, аның хезмәтен Тукай исемендәге бүләккә тәкъдим итү идеясен күтәреп чыга («Шәһри Казан», 1996). Халыкара конференция бу фикерне бердәм хуплый. Әмма... Дәүләт исеменнән премия таратучылар, «үлгәннән соң бирелми» дигән булып, Г.Камалның мәгълүм комедиясендәге хәйрия акчасын өләшүчеләр кебек, «отказ» сугып утырудан артыгын эшләми дә, эшләргә теләми дә.

Хәер, Рашат ага төзегән Тукай һәм Г.Ибраһимов томнары «хәреф таныган» кешеләргә 30 ел буе иң тулы фәнни басма сыйфатында хезмәт итеп килде, — бәлки, алар моннан зуррак бәягә мохтаҗ да булмагандыр.

50 яше тулган көнендә аңа хезмәттәшләре юллаган, тирән хөрмәт хисләре белән сугарылган самими, ихлас котлау да бар ул архивта:

...Егетләрнең галимлеген,
Галимнәрнең егетлеген
Тарих әле абайлар;
Сине: «Егет!» — ди бүген үк
Ибраһимов, Тукайлар!

Г.Тарханованың алда телгә алынган мәкаләсендәге *«Мактанырлык затларыбыз бар икән, алар белән горурланыйк, эшләренә тиешле бәябезне бирик. Бу дөньядан бакыйлыкка күчкәннәр рухына догабызны шул рәвешле булса да җиткерик»* дигән мәгънәле сүзләре белән кем килешмәс?!

Шул уңайдан бөек шагыйрьнең мәгълүм юллары искә төшә: *«Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү?! Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!»*

Исән чагындагы рәнҗетүләр җиле әле дә булса исә шикелле...

Узган елның октябрендә Рашат Гайнановка 90 яшь тулган булыр иде. Инде арабыздан китүенә нәкъ чирек гасыр вакыт үткән икән. Юбилеен беребез дә «сизми калдык». Сәбәбе «пүчтәк» кенә: исәннәрнең — кадерен, үлгәннәрнең каберен белмәгән мохиттә гомер кичерүебез аркасында.

Үзләреннән акыллырак шәхесләрне вакытлыча булса да кимсетеп яшәүдән тәм табучылар... Алардан нинди эз кала һәм калачакмы әле?

Ә Рашат ага үлеменнән соң да шул бәндәләрне узып яши һәм яшәячәк.

Килер бер көн, фән агачына ябышкан мәшкәкләр (гөмбәләр) кубып төшәр, һәм һәркем чын бәһасен алыр. Остазыбыз Миркасыйм аганың яраткан әйтеме бар иде: «Ялган данның киләчәге — яман дан». Аңа шуны гына өстәргә мөмкин: чын кешенең эше һәм гомере — ташкүмер, аны күмәр кара туфрак, басар чуар еллар, әмма ул, саф алмазга әйләнеп, кабат калкып-балкып чыгар.

Гафу ит безне, кичер, Рашат ага. ■

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ОЛЫ МӘҢГӘРДӘ

Марсель Әхмәтҗанов

Татар халык шагыйре Габдулла Тукай тормышында Олы Мәңгәр (Әтнә) белән бәйле истәлекләр бар.

Тукай 1907 елның октябрендә Жаек шәһәреннән армия хезмәтенә каралу өчен Казан артына килә. Монда ул Олы Мәңгәр авылында Вәли Хәкимов йортына төшә. Бу очраклы хәл булмый. Вәли Хәкимовның (Чәпәли Вәлие) әнисе Мәчтүрә җиңги вак-төяк сәүдә эшләре белән Жаекка барып йөргән. Анда ул Тукайның танышлары белән дус булган һәм шулар аркылы шагыйрьне белгән. Шунлыктан Габдулла Тукайның Олы Мәңгәргә килүе алдан үк сөйләшеп, килешеп эшләнгән булган. Чәпәли Вәлиенең Тукай белән бер елгы Хуҗи исемле улы булып, алар бергәләп йөргәннәр. Моннан тыш Олы Мәңгәрдә Габдулла Тукай белән дуслашып йөргән егетләрдән Вәлиулла Мөсәллимов та була. Соңыннан ул шагыйрь турындагы истәлекләрен сөйләп йөргән, тик вакытында язып алучы булмагач, ул хәбәрләр онытылган. Тукайның кордашы Хуҗи гармунчы булган, бу һөнәре аларны тагын да якынлаштырган.

Моннан тыш, Габдулла Тукайның Олы Мәңгәрдә булуын, соңгы гомерләрен Иске Мәңгәрдә уздырган Бикбау Йосыбының кызлары Гайшәбикә (1887–1994) һәм Хәдичәбикә (1889–1982) апалар хәтерли иде. Алар хәтерендә Тукай сүзгә тапкыр бер егет буларак калган. Бу апалар, Хәкимов Вәлинең күршеләре булу сәбәпле, Габдулланы еш күреп торган. Алар аңа шаяртып: «И беткән җан, беткән җан, кем сине солдатка алсын инде!» дип әйткәч, Тукай аларга: «Мине дә алмагач, кемне генә алырлар соң анда»,–дип шаярта торган булган. Бу сүзләрдән шагыйрьнең бик юка гәүдәле, ябык кына бер егет булганлыгы аңлашыла.

Вәли Хәкимовның Тукай кунак булган йорты 1940 елларга кадәр исән була әле. Шуннан соң ул сүтелгән. ■

Габдулла Тукай

(1886-1913)

Габдулла Тукай, бәхеткә, бик җентекләп, тирәнтен, яхшылап өйрәнелгән әдип. Аның бөеклеген замнадашлары да таныган һәм милләтебез асыл угылын югалткач та, бу кайгылы вакыйганы тәфсилләп язып калдырырга, ташка басарга тырышкан. Шуңа күрә, сөекле шагыйребезнең ни рәвешле сырхаулавын һәм бакыйлыкка кичүен сөйләр өчен сүзне шул чор каләм ияләренә, Габдулла Тукайның дусларына, ягъни, турыдан-туры шаһитләрнең үзләренә бирик, аларның истәлекләре ярдәмендә бөек шагыйребезнең соңгы көннәрен күздән кичерик.

Фатих Әмирхан «Тукай үлем алдында» мәкаләсендә (автор үзе күрсәткәнчә — «хатирә»дә) болай дип яза: «Тукай 1913 елның кышында (март башына кадәр) «Амур» номерларында[1] торды. Аның номеры белән минеке күрше иде. Аның көне-төне «горык-горык» йөткергәне миңа аермачык ишетелеп тора иде. <…>

Һәрбер көн генә түгел, бәлки һәрбер сәгать, һәрбер йөткерүнең аның гомереннән бер кисәген кубарып алынганлыгын без генә түгел, ул үзе дә белә һәм аңлый иде. Ләкин бу турыда ул теле белән сөйләргә яратмады. Соңгы көннәрдә ул ялгызлык сөя һәм ялгыз минутларда тирән бер уйга батып утыра һәм шул уйланудан үзенә бер күңел тынычлыгы таптан була иде ки, уйлану минутларыннан соң тереклек һәм дин хакында якты һәм өмидле нәрсәләр сөйләп куя иде. <…>

Төннәрнең берсе иде, Тукайның озак-озак сузылган йөткерүе, минем бүлмәдәге тынлыкны ярып, бөтен төнге дәһшәтле һәм куркынычлыгы белән колагыма керде, менә, менә шул йөткерүләр аның үпкәләрен тәмам-тәмамга өзеп ташларлар да, Тукай дөньядан сәфәр иткән булыр шикелле тоела башлады. Минем бүлмәмнән бер стена белән генә аерылган җирдә дөньяның иң зур серләреннән булган вакыйга (үлем) менә хәзер вакыйг булыр шикелле хис ителде, мин урынымнан торып утырдым, киенеп, Тукай янына кермәкче булдым. Ләкин ике-өч минут үткәндә инде Тукай үзе минем янымда иде. Ул йөткерә-йөткерә сүз башлады:

— Үлемнән качып, синең янга кердем әле! Юк, үлемнән түгел, ялгызлыкта үлемнән качып…

Төнге лампаның зәгыйфь кенә як-

[1] «Амур» номерлары — Казанның хәзерге Мәскәү урамы, 70 нче йорты. Тукай анда 1912 елның икенче яртысында урнашкан була.

[2] Клячкин хастаханәсе. Хәзерге Островский һәм Кави Нәҗми урамнары чатындагы бина.

тысы астында «ялгызлыкта үлемнән» качып кергән Тукайның зәгыйфь тормышы минем күзләремә үлемнең нәкъ үзе, шул серле үлемнең нәкъ үзе булып күренде, йөрәк сикеренде, җан куркынды, бугазга яшьләр килеп тыгылдылар. «Мә, Тукай, ал минем таза үпкәләремнең берсен, берәр үпкә белән дә дөньяда торырбыз әле», — дип кычкырасы килгән шикелле булды. Бу төннән соң инде Тукай «Амур»да озак тормады. Аны больницага илттеләр.

«Мондый вакытта рәсем алдырып калу гадәте бар, бу нәрсә сәламәтләнсәгез үзегез өчен, тәкъдир җитеп, үлсәгез, дусларыгыз өчен бер ядкарь булыр иде...»
Тукайның соңгы фотоларыннан берсе.
1 апрель 1913 ел

Иртәгә иртә белән больницага илтеләчәк дигән төнне ул минем белән күрешергә кергән иде. Сабыйларчарак шат йөз белән ул:

— Мин иртәгә Клячкинга[2] керәм, мин киткәндә, син тормаган булырсың. Моннан соң күрешмәсәк... хуш инде! — диде.

Докторлар аркылы миңа инде аның бер ай, күп булса, ай ярым гомере калганлыгы мәгълүм иде. Бу «хуш»ның да ахыргы «хуш» икәнлеге билгеле иде. Алай да мин аңар:

— Тиз терелеп чык, тиз күрешик! — дидем.

«Ике позада: берсе караватта утырган, икенчесе аркасына мендәрләр куеп яткан хәлендә Тукайның рәсемнәре алдырылды. Бу рәсемнәр Тукайның үлүеннән 28 сәгать кенә элек алынган соңгы хатирәләре булып калдылар...»



Ул, бүлмәдән чыга башлап:

— Юк, тиз күрешмик әле, син озаграк яшә! — диде һәм чыгып китте».

Инде сүзне Шиһап Әхмәровка бирик («Габдулла әфәнде Тукаевның авыруы» мәкаләсе): «Гакыйбәт[3] соңгы вакытларда аның «Кояш» идарәсенә кереп, авыр хезмәтләр илтизам итәргә[4] мәҗбүр булуы[5] вә үзенең басылачак мәҗмугаи асарен тиз вакыт эчендә тәртипкә салу[6] кебек авыр хезмәтләр аны бастылар, ул тәмам хәлсез калды, йокысызлык, тынычсызлык пәйда булып, аны бик тарландыра башлады. Шуннан соң ул, бәгъзе берәүләрнең киңәше илә, дәваланыр өчен Кырымга бару фикеренә төшеп, 22 нче февральдә китәргә карар биргән иде. Фәкать якын иптәшләре, Кырымга баруны беркадәр һавалар төзәлгәнче калдырып торып, анда барганчы, бер шифаханәгә кереп, беркадәр хәл җыярга киңәш бирделәр. Ул үзе дә шуны мәслихәт табып, үзе сайлавы буенча, 26 нчы февральдә, айга 150 сум хак илә, Казанда Клячкин шифаханәсенә куелды. <...>

Шифаханәдә ахыр көннәргә кадәр Казанда чыга торган татар матбугатын укый килде. Барганда, һәрвакыт матбугат хакында сүз ача вә төрле мөлахәзәләр булына иде; рус газеталарын да моталәга иткәли[7] иде. Фәкать соңга таба, күзем арый, ятып каршы тотып укыганда кулларым тала, дип зарлана башлады.

Шифаханәгә хәлен белергә баруны бик ярата иде, барган вакытта яткан булса, торып утыра вә янындагы кеше киткәнче, утырып сөйләшә иде. Бәгъзе, сау вакытындагы дусларының, шифаханәгә кергәч, килмәүләреннән зарланган төсле, үткен сүзләр әйтеп куя иде.

Соңгы көннәргә кадәр ашау-эчүендә бер дә алмашыну булмады, яхшы ашый һәм эчә иде. Температурасы 38 илә 38,5 араларында, пульсы 100-105 тирәләрендә йөри иде. Мәрхүмнең бу хәле 31 нче мартка кадәр сузылып килде. Фәкать 31 нче март кич сәгать биштән хәлендә зур бер үзгәреш күренде: бердән авыраеп, ашау-эчүдән вә йоклаудан тәмам киселде. Шуннан соң үзенең хәятыннан өмет өзгәнлекне аңлата, хәлен белергә килүчеләр илә бәхилләшә, аз сөйләшә, вә сораган сөальләргә дә бер сүз яхуд баш ишарәсе илә генә җавап бирә башлады.

1 нче апрель иртә сәгать унбердә барып «хәлегез ничек» диеп соравыма «әҗәл» диеп, бер генә сүз илә җавап бирде дә, бераздан соң «хәлем авыр, болай булса, өч көннән артык чыдый алмам», диде. Шул ук көндә доктор да: «Авыруның хәле начар, озак торса, өч көн торыр, алайга да бармас, сез инде аны ташламагыз, дуслары җыелышып, бер тәртип илә һәрвакыт берегез янында булыгыз», — дия тәнбиһ итте[8]. Шуннан соң чиратлашып янында торыла башлады.

1 нче апрель өйләдән соң сәгать өчтә «Габдулла әфәнде, хәлегезне үзегез дә начар дисез һәм шулай күренә дә, мондый вакытта рәсем алдырып калу гадәте бар, бу нәрсә сәламәтләнсәгез үзегез өчен, тәкъдир җитеп, үлсәгез, дусларыгыз өчен бер ядкарь булыр иде», — дия, рәсемен алдырырга рөхсәт сорадым. Моңар каршы: «Беркадәр хәл алгач алдырсак, ничек булыр икән, бер дә хәлем юк бит», — дисә дә, мин: «Сез шул урыныгыздан кузгалмассыз, сезгә мәшәкате булмас», — дигәч, рөхсәт итте. Фотограф чакыртып, утырган һәм яткан

[3] Гакыйбәт — нәтиҗә.

[4] Илтизам итү — башкару.

[5] ... авыр хезмәтләр илтизам итәргә мәҗбүр булуы... – Бу раслау хакыйкатькә туры килеп җитми. «Кояш»ның җаваплы секретаре Фатих Әмирхан шагыйрьгә ярдәм йөзеннән айга 40 сум эш хакы белән аны газетага язышучы итеп алуга ирешкән.

[6] ... мәҗмугаи асарен тиз вакыт эчендә тәртипкә салу... — Габдулла Тукай больницага керер алдыннан бер көн элек истәлек авторына: «Ике-өч төн йокламыйча, мәҗмугаи асаремне тәртипкә салдым, шул мине бөтенләй эштән чыгарды», — дип сөйләгән.

[7] Моталәга итү — уку, тикшерү.

[8] Тәнбиһ итү — кисәтү.

«Зариф хәзрәт Әмирхани тарафыннан җеназа укыла. Җеназа соңында табутны имамнардан күтәртеләә вә шунда аның янә дә рәсеме чыгартыла...»

көенчә рәсемнәре чыгартылды. (Шул ук авторның «Тукай турында исемдә калганнар (Тукайның үлеме)» исемле язмасында бөек шагыйребезнең соңгы мәртәбә фотосурәткә төшү вакыйгасы тәфсилләбрәк язылган: «Шифаханәдә тәрбияче яшь докторлар бик дикъкать белән карыйлар, дәвалыйлар, Хадимәләр дә соң дәрәҗә саклык белән, ягымлылык белән мөгамәлә итәләр иде. Шифаханәгә кергән көненнән алып иптәшләреннән икешәр кеше нәүбәтләшеп дежурить иттеләр, кичә-көндез бер минутка да ялгызын гына калдырмадылар. 31 нче март көнендә көндез сәгать берләр-икеләр тирәсендә доктор Лурье килде, авыруны бик дикъкатьләп карап, сорашып, аны өметләндерә торган сүзләр белән юатты. Тукай яныннан чыккач, без: мин, Әмин Мостафин, Габдулла Кариев, Урманчиев Әхмәт, докторны чолгап алып, авыруның хәле ничегрәк дип сораша башладык. Ул тирә-янга карады да, чит кешеләр юк икәнен күргәч: «Сездән яшерүне кирәк тапмыйм, авыруның хәле яхшыдан түгел, бик күп торса, өч-дүрт көн торыр, авыруның үзенә белдермәгез, ялгызын гына калдырмагыз», — диде дә башын иеп чыгып китте. Без, дүртебез дүрт җиргә баскан килеш, бер-беребезгә бер сүз дә дәшә алмаенча, катып калдык. Арадагы тынычлыкны башлап Кариев бозды. Ул, стенага сөялгән килеш, кулларын күзенә куйды да үксеп-үксеп елый башлады: «Шулай ук Тукайны югалтабызмыни», — диде. Башкаларның да күзләре яшьләнде, һәркем үзенә иң кадерле, мөкатдәс булган бернәрсәсен төшереп югалткан кебек хис итеп таралыштык. Бу хәбәр киң бер катлауга фаш ителмәсә дә, Тукайга якын торган иптәшләреннән моны яшереп булмады. Алар бик саклык белән генә хәл белергә килгән булып, Тукайны соң мәртәбә күреп калырга, күңелләре белән генә булса да, Тукай белән соң мәртәбә саубуллашырга ашыктылар. Шулвакытта иптәшләр арасында Тукайның соңгы рәсемен алып калырга кирәк иде, дигән фикер кузгалды. Ләкин моны ничек эшләргә? Тукайның үзенә белдерми моны эшләп булмый, ә белдерсәң, Тукайны шиккә төшерергә мөмкин, бу аңа

начар тәэсир итәчәк. Озак киңәшкәннән соң, бу мәсьәләне Тукай белән җайлап сөйләшеп хәл итүне миңа тапшырдылар. Беренче апрельдә көндез сәгать икеләрдә Тукай белән икәү генә калып, мин тышта һаваларның матураеп килүен һәм тиздән моннан чыгып, Кырымга китәргә мөмкин булачагын бик саклык белән генә сөйләп, ахырдан иптәшләренең аның монда яткан вакытын истә калдыру өчен рәсемен алдырырга теләүләрен һәм моның үзе өчен дә бер хатирә булачагын сөйләп, шуңар рөхсәт сорадым. Тукай каршы килмәде: «Кирәк дип тапсагыз, эшләрсез», — диде. Шуннан аның белән тагын бераз сөйләшеп утыргач, мин чыгып, тиз генә Ленин (ул вакытта Воскресенский) урамындагы Рембрандт фотографиясенә барып, фотограф чакырдым. Сәгать дүрттә фотограф килде, ике позада: берсе караватта утырган, икенчесе аркасына мендәрләр куеп яткан хәлендә Тукайның рәсемнәре алдырылды. Бу рәсемнәр Тукайның үлүеннән 28 сәгать кенә элек алынган соңгы хатирәләре булып калдылар.)

Икенче апрельгә каршы төндә хәле беркадәр яхшыланды: кыска-кыска, өзелеп-өзелеп булса да, йоклады. Үзе дә: «Бу көн беркадәр йоклый алдым, кәефем ярыйсы», — дип сөйләде. Иртә илә чәй эчәргә утыргач: «Бергә эчик», — диеп, безгә (кичләрдә янында торуны Әхмәт әфәнде Урманчиев илә икәү илтизам иткән идек) чәй сорарга кушты вә беркадәр сүзләр сөйләшеп чәй эчтек. Чәйдән соң: «Без китәбез», — дигәч, «Кичкә тагы килсәгез, бик яхшы булыр иде, бүген уңай булды», — диеп саубуллашып калды. Фәкать шул көнне кич сәгать сигез дә чиректә *(тугызынчы унбиш минутта — **Р.М.**)* дөньядан үтте. Без барганда, Габдулла әфәнденең рухы яңа гына ашкан, аның җылы тәне карават буенча сузылып ята иде».

«Аң» журналының нашире, баш мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәни Габдулла Тукайны исән күрүче соңгы кешеләрнең берсе була. Ул шагыйрь янына 2 апрель көнне кичке сәгать алтыда килә. Соңрак ул болай дип искә алачак («Тукаев үлем көткәндә»): «Габдулла әфәнде ак күлмәк-штаннан, соры оектан, яланбаш хәлдә караватка аякларын җыеп, куырылып кына яткан иде. Авыр-авыр мышнап сулу алуы, күзләрен бер ачып тегәлеп карап, бер йомып ятуы кызганыч иде. Аның өстенә битләренең, кулларының ап-аклыгы, шабыр тиргә батуы, арыклыкның чигенә чыгып, тәмам бетерешкәнлеге карарга бигрәк тә аяныч иде. Габдулла әфәнде шулай ята торгач, әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп, күкрәкләре тугрысына китереп укмаштырган кулларын кузгаткалый, читкә алып яисә башы астына тыгып куя, кайвакыт торып, тезләрен чәнечтереп, куллары белән тезләренә тотынып утырып тора иде. Ара-тирә җиңелчә генә йөткерә, савытка төкерә, шулай итеп, күптәннән дучар булган чахотка хәстәлегенең җәфасын чигә иде.

Мин, билгеле, бу авыр хәлне күреп, Габдулла әфәнде белән күп сөйләшмәдем, фәкать: «Габдулла әфәнде, сәламәтләнәсезме?» — дип, хәлен генә сорадым. Соравыма Габдулла әфәнде җавап бирмәде. <...>

Мин кереп чирек сәгать кадәр торгач, Габдулла әфәнде көтмәгән җирдә миңа бер сөаль бирде, авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс кенә, карынкы вә зәгыйфь бер тавыш белән:

— Актык корректура кайчан? — диде.

Габдулла әфәнде «Аң»да бастырган шигырьләренең соңгы корректураларын үзе караучан иде. Бу юлы да 8 нче сан «Аң»да дәрҗ ителгән[9] өч шигыренең матбага хаталарын тәсхих итәргә[10] теләп соравы иде.

Шулхәтле авыру, авыр хәлдә яткан Габдулла әфәнденең бу соравыннан мин бик тәэсирләндем, аңар ни дип

[9] Дәрҗ ителән — басылган.
[10] Тәсхих итү — дөресләү, төзәтү.

җавап бирергә бераз аптырап та тордым. Ул сораган корректура ул вакыт минем янымда булса да бирсәң, йә шул минутта ук торып төзәтә башлар да, үзенең сәламәтлегенә тагын да зарар итәр дип, бирмәскә уйладым.

— Корректура иртәгә була, — дидем.

Ул шуның белән бетте. Габдулла әфәнде, минем җавабыма канәгатьләнеп, сөкүт итте[11].

Без сөйләшеп бераз вакыт үткәч, Габдулла әфәнде әлегечә торып, өстәлдәге стаканлы чәйгә кулын сузды. Ләкин чәй күптән ясалып куелганга күрә, салкынча булганга, Әмин әфәнде *(Әмин Мостафин, ул Әхмәтгәрәй Хәсәни килгәнче үк Габдулла Тукайны саклап торган була — **Р.М.**)*:

— Бу суынган, икенчене сорыйкмы? — диде.

Габдулла әфәнде аңар баш белән генә ишарәт итте.

Икенче чәй китерелде.

Тагы бераз вакыт үтү белән, шифаханәдәге авырулар янында йөри торган бер марҗа бүлмәгә керде. Габдулла әфәнденең йөзендәге тирләрен сөртеп алды. Кулыннан тотып, берничә минутлар чамасы тамыры типкәнне тикшерде дә:

— Дару эчәсезме? — дип сорады.

Габдулла әфәнде моңар ни ишарә, ни тел белән җавап бирмәде. Марҗа уртачарак бер рюмкага бер төрле дару салып бирде. Габдулла әфәнде, марҗа һәм Әмин әфәнденең ярдәмләшүләре белән, урыныннан торып утырып, рюмкадагы даруны үз кулы белән тотып, төбенә кадәр эчеп бетерде.

Габдулла әфәнденең, болай көчләнеп-көчләнеп, бирелгән даруны рюмка төбенә кадәр эчеп бетерүен карап тору минем күз алдыма бик кызганыч күренешләр китерде. Габдулла әфәнде үзенең тиздән үләчәгенә ышанып та, сәламәтләнү өмете белән болай дару эчүе аның һич үләсе килмәгәнен, үлем белән иң актык чиккә кадәр көрәшкәнен, никадәр көрәшсә дә, никадәр дәваланса да, залим әҗәл аны якасыннан тоткан, ул аңар бүген бирелмәсә, иртәгә дигәндәй, биреләчәк, җиңеләчәк икәне күренеп торганга күрә, карарга бик аяныч иде…

Даруны эчкәннән соң, Габдулла әфәнде янәдән ятты. Мин, бераз утыргач, сәгатемне карадым — җиде ярым иде. Габдулла әфәнде янында үткән бер ярым сәгать вакытны мин тоймый да калдым, вакыт бик тиз үткән; шулай да сәламәт түгел кеше янында бик озак тору ялыктыру, тартындыру булмасын дип уйлап, мин китәргә ният иттем. Габдулла һәм Әмин әфәнде белән күрешеп чыгып киттем. Габдулла әфәнде, бу юлы миңа кулын сузмады, мин аның кулын тотып күрештем.

Габдулла әфәнде Тукаев белән минем бу күрешүем актык мәртәбә булды. Шул кичне мин китеп, өч чирек сәгать *(кырык биш минут — **Р.М.**)* вакыт үтүгә, Габдулла әфәнде вафат итте».

Татарның сөекле улын гүргә иңдерү «Мәктәп» журналында («Казанда 4 нче апрель» мәкаләсе) бик тәфсилләп бәян ителгән: «Габдулла әфәнденең җеназасы өйләдән соң сәгать бердә Клячкин шифаханәсеннән чыгачагы бөтен шәһәр халкына таралып өлгергән; һәркем диярлек аның илә соң мәртәбә видаглашып[12] калырга хәзерләнә, ешеш сәгатен карап, вакыт көтә. Сәгать ун җитә. Һәр тарафтан халык Клячкин шифаханәсенә агыла башлый; мәдрәсә шәкертләре төркем-төркем, урам тутырып кайгылы кыяфәттә вәкарь илә генә килә башлыйлар. Озак та үтми, урам халык илә тула. Укучы яшьләр, зыялылар, картлар, яшьләр, туташ вә ханымнар, рус, татар, һәр милләттән диярлек халык ябырылып ала. Бу вакытта инде Габдулла әфәнде юылып кәфенләнгән, тирә-ягына тезелгән чәчәкләргә күмелеп, үзенә махсус эскәмиядә ята. <…>

Җыелган халыктан Габдулла әфәндене күреп калырга теләүчеләргә кереп, күреп чыгарга рөхсәт бирелә.

[11] Сөкүт итү — тик тору, тукталу.
[12] Видаглашу — хушлашу.

Халык берсе артыннан берсе керә, Габдулла әфәнде илә видаглашып, авыр сулап чыгып китә. Габдулла әфәнде чәчәк эчендә көлгән кыяфәттә, үзенә махсус булган бер голүвият[13] илә ята, ул гүя дөньядан китүенә бер дә кайгырмый, ул аны көлеп кенә каршы ала төсле тоела.

Халык чыгып бетә, шул урында Габдулла әфәнденең йөзе ачык хәлдә ахыргы рәсеме, соңгы ядкаре алына. Берничә хәзрәт вә үзенә якын торган аркадашлары тарафыннан тәсбих тәһлил укыла. Урамдагы халык дүрт күз илә җеназа чыкканны көтә. Гакыйбәт[14] сәгать бер тулып утыз минутта Габдулла әфәнде табутка салына, табут өстенә ак ефәк лентага үзенең шигырьләреннән:

Кайт, и нәфсе мотмәиннәм[15]!
««« бар, юнәл, кит тәңреңә;
Бирдең арканңны моңарчы,
««««инде бир бит әмренә! —

мисрагысы язылган, кырые укаланган кара хәтфә ябыла. Соңра ленталы чәчәкләр тезелә, табут бөтенләй чәчәк илә күмелә, ул табут түгел, гүя зур чәчәк букеты булып кала.

Шифаханә ишегалдында, җеназа җирдән күтәрелгәч, тагы бер мәртәбә рәсеме чыгартыла. Гакыйбәт, җеназа урамга чыга, халык шылт итми, тын. Аларны җеназаның, Габдулла әфәнденең мәһабәте баса, җеназа узганчы беркем дә баскан урынынннан кузгалмый. Җеназа чыккач та уңга китеп, Проломный урамына[16] чыга, Габдулла әфәнденең шәэненә[17] лаек бер вәкарь вә мәһабәтлек илә, Проломный урам буенча бара; җеназа артыннан ияргән халык җеназадан ике-өч сажень арттан бара, һичкем алга чыкмый, беркем дә аңар җөрьәт итә алмый. Фәкать күмү комиссиясе әгъзаларыннан булган, тәртип саклар өчен куелган затлар гына халык алдыннан, җеназа янында баралар. Урамның ике тротуары вә юл өстендәге йорт вә кибетләрнең тәрәзәләре халык илә тулы, мөселман булган кибет хадимнәре берсе дә калмыенча урамга чыккан; алар, мәрасимгә катнаша алмаулары өчен, үзләрен бәхетсез саныйлар вә шунда катнашып, бердәнбер шагыйребезне озата барырга хуҗалары рөхсәт итмәүне бер золым, зур бер җәбер саныйлар төсле тоела. Алар, мәэюс булып, җеназа артыннан моңаеп карап калалар. Моннан соң җеназа Университет урамы илә борылып, Печән базарына чыга; монда халык һич урамга сыеша алмый. Өй түбәләре, кибет алдындагы күләгәлек өсләре халык вә тамашачылар илә тула.

Җеназа нәкъ Печән базары мәсҗеде каршысына килеп туктый, монда аның тагы рәсеме алына. Соңра Московский урамы илә барып, Евангелистовскийга[18] (иң киң урам) чыга; бөтен урам халык илә тула.

Моннан соң Екатерининский урамга[19] борылып, җеназа укыла торган площадька юнәлә. Анда шагыйрьнең җеназасын 5-6 меңләп халык каршы ала. Бөтен площадь халык илә тулы, ике якта кыз-хатын, һәркайсы бөек шагыйрь илә соң мәртәбә саубуллашырга тупланганнар.

Казанның имам вә мөәзиннәреннән берсе дә калмый җеназага хазир булганнар. Зариф хәзрәт Әмирхани тарафыннан җеназа укыла. Җеназа соңында табутны имамнардан күтәртелә вә шунда аның янә дә рәсеме чыгартыла.

Җеназа намазыннан соң халыкның бер кыйсме кайтып китә. Меңләгән халык һаман да җеназа артыннан бара.

Аяк асты былчырак булуга карамый, җеназага ихтирамән, һәркем җәяү бара. Хатын-кызлардан да утыручы булмый. Алар да абына-абына җәяү баралар.

Бәгъзе бер ашыгучылар, зыярәттә кеше күп булачагын уйлап, башка урамнар илә алдан китәләр. Ләкин, алдан

[13] Голүвият — олылык, бөеклек.
[14] Гакыйбәт — ахырда.
[15] И нәфсе мотмәиннәм — и минем ышанучы җаным.
[16] Хәзерге Бауман урамы.
[17] Шәэненә — дәрәҗәсенә, бөеклегенә.
[18] Хәзерге Татарстан урамы.
[19] Хәзерге Тукай урамы.

«Кабернең туфрагы күренми. Ул хәзер кабер түгел, чәчәк өеме булып әверелә...»

хәбәр бирүләренә күрә, җеназа барып җиткәнче, каберстанга беркем дә кертелми; җеназа барып җитәр алдыннан, күмү әгъзаларыннан берничәсе барып, каберстан эчендә бер цепь төзиләр, җеназа кертелә, аның артыннан хәзрәтләр, аннан соңра ханым вә туташлар керәләр. Ясалган цепь эчендә фәкать муллалар, күмү комиссиясе, дөньяда вакытта үзенә якын торган дуслары, ханым вә туташлар вә күмүчеләр генә була. Табут җиргә куела, тәгаен кылынган адәмнәр тарафыннан Габдулла әфәнде табуттан алына, кабергә иңдерелгән вакытта аның янә бер рәсеме чыгарыла. Гакыйбәт, кабергә тапшырыла, ләхеткә иңдерелә, кирпеч илә каплана. Туфрак салына башлый, һәркем туфрак салырга ашкына, берсе кулы илә, икенчесе таягы илә туфрак ишә; озак үтми, кабер өскә калка, туфрак өелгәннән-өелә, халык шагыйрен халыктан ераклаштырганнан-ераклаштыра. Күмү тәмам була. Ханым вә туташлар тезелешеп чәчәкләр китерәләр, кабер өстенә тәртипләп тезәләр, кабернең туфрагы күренми. Ул хәзер кабер түгел, чәчәк өеме булып әверелә. Бу да тәмам була. Зариф хәзрәт «Табарәк» укый башлый. Шулвакытта һәркем югалткан кешеләренең кем идекен төшенә башлый, кызулык вә эш илә сизенмәгән якыннары да аңга киләләр, күп кешенең күзендә яшь тамчылары тәгәри башлый. «Табарәк» тәмам була. Дога кылына. Догадан соң Касыйм хәзрәт мәрхүмнең васыяте буенча:

Кайт, и нәфсе мотмәиннәм!
«««« бар, юнәл, кит тәңреңә;
Бирдең аркаңны моңарчы,
«««««инде бир бит әмренә! —

шигырен укый. Соңра берничә кеше тарафыннан нотыклар сөйләнә. Мәрасим тәмам була. Халык югалткан нәрсәсенең кыйммәтен тәкъдир итә-итә, уйланып, таралып китә».

Рүзәл Мөхәммәтша *әзерләде.*

1. Халит Г. Тукай турында замандашлары. Истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы. Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 295 б.
2. Тукай турында истәлекләр. — Җыентыкны төзүчеләр һәм искәрмәләрне әзерләүчеләр Ибраһим Нуруллин, Риф Якупов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. — 256.

ТУКАЙ БӘЕТЕ

Бисмилләһи вә билләһи укыдык корбан гаетен,
Без әйтәбез, сез тыңлагыз Тукай шагыйрь бәетен.

Тугыз йөздә унөч елда апрель икесендә,
Тукай мескен вафат булган Клячкин балнисында.

Ак келәтнең алдында калды бәнем җиләнем,
Егерме алтыда үлеп китте Тукай — шагыйрь сөйгәнем.

Тавык йөри кырлашып, кызлар йөри җырлашып,
Безнең өчен җырлар язды тырышып та тырмашып.

Япун сугыша җир өчен, урыс сугыша дин өчен.
Үзе үлсә дә, эз калдырды безгә сагыныр өчен.

Җөгерә үрдәк, җөгерә каз — боты озынга күрә,
Без Тукайны сөямез җыры матурга күрә.

Җөгереп кердем келәткә, кулым тиде беләккә,
Җылы ашдай җырлары чат җатадыр җөрәккә.

Ызба артында алмагач кискеп җиргә салмагач,
Җырла, моңай, саргай, үл, матур Тукай калмагач.

Мәчет башы манир, манир, манир саен бер талир,
Безне ятим калдырып китте безнең шәп шагыйрь.

Тукай абзый яшь чагыңдан белә идек без сине,
Онытыр, диеп уйлама, онытмамыз без сине.

Алма бирдем — алмадың, тәңкә бирдем — сайладың,
Безнең матур дөньямызда ник ике-өч ел калмадың?

Тауга менсәм — тау биек, түбән төшсәм — тамырлык,
Тукайен җуйган яшьләргә Ходай бирсен сабырлык!

Акдыр җиләнем минем, күкдер җиләнем минем,
Кабереңдә шат йокла, җаным, шагыйрем минем.

«Кояш», 11 апрель, 1913 ел

ТУКАЙГА ЯКЫНАЮ БАСКЫЧЛАРЫ

Әхтәм Зарипов

ТЕАТР ҺӘМ ТУКАЙ

1961 елның язында безне, ягъни Мәскәүдә укып ятучы татар студиясе студентларын, диплом эшебезне күрсәтү өчен Казанга кайтардылар. Спектаклебез Әхмәт Фәйзинең «Тукай» драмасы буенча Г.Камал театры артистлары катнашында куелып, репертуарда калырга тиеш иде.

Рольләрне башкарырга без — шәкертләрдән тыш — Хәлил әкә Әбҗәлилов кебек артистлар да билгеләнүне — спектакльнең уңыш казанып, озын гомерле булачагына гарантия, диделәр. Ышанылды. Яз... Гагаринның космоска очкан көннәре... Тукайның тууына 75 ел тулуны лаеклы каршылау өчен республикада гына түгел, илдә әзерлек чаралары күрелә. Энтузиазм мулдан, кәефләр күтәренке. Ниһаять, премьера. Спектаклебез турындагы хәбәрләр Гагаринның космоска очуы хәбәредәй тиз таралып, телләрдән телләргә күчәр дип көтсәк тә, яшьләр газетасында чыккан кечкенә мәкаләдән башка язма материаллар күренмәве «кикрикләребезне шиңдерсә»дә, студиянең тулы составта Академия театры штатына кабул ителүгә ышанычны сүндермәде.

Спектакльнең премьерадан соң уздырыла торган «Худсовет» җыелышында артистлар уенына уңай бәя

бирелеп, «тиздән академия театры труппасына талантлы яшь артистлар кушылу, Тукайны Тукай итеп күрү ихтималына өметләр уята» дигән сүзләр яңгыраса да, «Тукай» спектакленең бусы да көтелгән эффектны бирмәде», дигән фикернең өстенлек итүе, без — шәкертләрнең өмет үсентеләренә кырау суккандай тәэсир итте. «Артист» дигән диплом әле кесәгә кермәгән, киләчәгебез турындагы шик-шөбһәләр күңелгә кадалып, үз эшен эшли башлаган уйлар белән кабат Мәскәүгә кайтып, яңа спектакль әзерләүгә имитация ясыйбыз. Янәсе, артистлыгыбызны «чарлыйбыз». Чираттагы бу эшебез Юныс Әминев әсәре буенча музыкаль спектакль булырга тиеш, имеш.

Диплом эшләребез инде күрсәтелгән, лаеклы бәһаләр «зачетка»га куелганлыктан, Юныс абый әсәре буенча спектакльнең өлгермәячәген сизенеп, татар теле буенча хәлфәбезне үпкәләтмәс өчен генә вокал дәресләренә йөрибез, «арияләрне» өйрәнәбез. Диплом эшләребезнең берсе Г.Коләхмәтовның «Ике фикер» пьесасы буенча иде. Ул спектакльгә көйләр язучы һәм музыкаль педагог итеп Заһид абый Хәбибуллин чакырылса, Юныс абый әсәре буенча спектакльгә Мәскәүдә яшәүче композитор Әгъзам Фәттах белән шартнамә төзелә. Шул шартнамә «шартламасын» өчен генә репетицияләргә йөреп, диплом кулга керүне көтәбез. Дөресе — вакыт уздырабыз. Шулай вакыт уздыруның бер чарасы буларак, хатыным Җәмилә белән авылда яшәүче бер яшьлек улыма «посылка салу» өчен витаминлы ризыклар эзләп, Мәскәүнең Пушкин урамындагы «Детское питание» кибетенә килдем. Бу кибет кечкенә булса да, миңа кирәкле нәрсәләр иркле сатылганлыктан, хатыным сораган ризыкларны акчам җиткән күләмдә алмакчы булып сорасам, кибетче ханым:

— Зачем так много? Обратите внимание на срок годности? — диде.

— Срок годности?..

...Минем андый сүзне ишеткәнем булгандырмы, юкмы — әмма элек игътибарга алмау ихтималыннан гына:

— На какой срок? — дидем шикелле.

Бу сорауга ишектән кергәч уң кул як почмактагы өстәл артында чәйләп утыручы бер агай татарча:

— Балалар ризыгына сак килергә кирәк. Беткәннән беткәнгә алсаң да, дефицит нәрсә түгел... — диде.

— Авылда дефицит алар, — дидем мин шулай ук татарча.

— Гаиләгез авылдамыни?

— Мин авыл малае ич.

— Шулай инде — безнең талантларыбыз чыгышлары белән күбесе авылдан. Тукай булып Тукай да, Муса да... — авыл җимешләре.

Агайның бу репликасына ни дияргә дә белмәгәннән генә, кайчандыр, кемнәндер ишеткән:

— Әйе, талантлар авылда туа, шәһәрдә үлә шул... — дидем дә товарларымның хакын түләргә акча саный башладым.

— Сезгә әле үлем турында түгел, яшәү турында, мәрхүмнәрне сәхнәдә терелтү турында гына уйлау тиеш, — диде бу абзый, миңа тагын уйлану өчен «сәхнә» сүзен кыстырып. Күрәсең, бу сүзен абзый үзенең кем булуы белән кызыксындыру өчен әйткәндер, әмма мине ул чакта хатыным кушканны үтәүдән тыш нәрсә кызыксындырмагач:

— Кызганычка каршы, мин доктор түгел бит, абзый. Мәрхүмнәрне терелтә торган даруын да, им-томын да, кемне терелтү кирәген дә белмим, — дидем.

Абзый кеше:

— Сез кеше докторы гына түгел, — кешелек, җәмгыять докторы. Мин үзем дә шул кавемнән — композитор. Мин сезнең «Тукай» спектаклен дә, «Мунча»гызны да, «Ике фикер»не дә караган тамашачы. Шуларга таянып әйтәм: Тукаегызның Тукайга тышкы охшашлыгы булса да, шагыйрьнең рухына ераклыгы спектакльне җансыз итте, ясалган тамаша ясады. Ә менә

синең шәмче Галиең мине ышандырды, шик тудырмады, — диде абзый.

Ә мин аның спектаклебезгә бәһасе белән килешмәгәнне белдерү максатында гына:

— Әгәр минем белән монда Тукайны уйнаган артист булса, сез аңа да мәдхия әйткән булыр идегез, — дидем, җиңүче позасына басып.

Абзый сабыр гына миңа карап елмайды да:

— Рәнҗер сүз әйткән булсам, гафу үтенәм. Әмма үз фикеремдә калам. Мин Мансур Мозаффаров атлы кеше булам. Мәскәүгә йомыш белән генә килгән идем, — диде.

Сөйләшү дәвам итте. Бу сөйләшүгә ярты гасырдан артык вакыт узса да, аның тәэсире гомерем буе уйландырган серле васыять кебек булды. Бүген инде әңгәмәне сүзгә-сүз хәтерләмим. Әмма эчтәлеге онытылмый:

— Тукайны мин Камал III, Ибраһим Гафуров башкаруында да күрдем. Сезнең «Тукаегыз» һөнәри эшләнеше ягыннан оста ясалган булса да, Габдуллагыз шагыйрьгә тышкы кыяфәте белән генә бераз охшаш иде, — диде ул, фикерен кабатлап.

— Үлеменә ярты гасыр узып барган шәхесне гәүдәләндергәндә кыяфәт охшашлыгы да мөһим ич.

— Хикмәт рухи охшашлыкта шул... Мин бу хакта мәрхүм Әхмәт Фәйзинең үзе белән дә бәхәсләшкәнем булды. Ул: «Һәр образ заман әмеренә яраклашса гына гомерле була», — дип үз Тукаен яклады. Мин үз фикеремдә калдым һәм калам. Чөнки үз биеклегеннән төшерү дә, күтәрергә маташу да Тукайны бездән ерагайта гына. Бөек зат буларак ул заманга кирәкчә төсләргә мануга мохтаҗ зат түгел. Аның үз биеклеге, бөеклеге, яңгырашы, үз тавышы, үз төсе.«

— Һәр буынның Тукайны үзенчә күрергә, үзенчә күрсәтергә омтылышы гаепмени?

— Менә мин үзем тере Тукайны күреп белгән кеше буларак, аны заман идеологиясенә яраклаштыруларга катгый каршы. Үзе әйткән «окружениесен» дә үзгәртү кирәксез. Тукайга якынаю сезнең буын артистларына кала инде...

Сүз иярә сүз чыгып, мин бу абзыйдан шикләнүләрем бетсен өчен:

— Тукайны «күреп белгән кешемен» дигәнегезне ничек аңларга? — дип сорарга җөрьәт иттем.

Ә ул бер дә исе китмичә генә:

— Ничек ишетсәгез шулай: күрдем дә, ишеттем дә. Малай чакта, китап кибетендә йомышчы буларак, «Болгар» номерларында торучыларга газета-журналлар керткәли идем. Шунда Тукай белән очраштык. Ул миңа фәрештәләр белән очрашып сөйләшүен сөйләде. Шәкерт чак бит, мин бу очрашуга әһәмият бирмәвемнең «узган эш кайтмый, үл син, үл-ела» икәнен хәзер генә аңладым...

Ә мин Мансур Мозаффаров белән очрашуымның язмышымда хәлиткеч эпизодларның берсе булуын, менә бүген аңларга тырышып утырам.

Ул чакта мин аның «Габдулла Тукай истәлегенә» симфоник поэмасы өчен Тукай премиясе алуын да, «Галиябану», «Зөлхәбирә» һәм башка күләмле әсәрләр авторы икәнен дә белми идем. Минем өчен композитор һөнәре ул чак Заһит абый Хәбибуллинның һәм шул көннәрдә безнең белән интеккән Әгъзам Фәттах абзыйларның кәсебе булып кына тоела иде.

«Мансур Мозаффаров» дигән абзыйның кешесез кибеттә кемнедер көтеп торуы үзе бер сер иде. Аны кибеттән кемдер «Волга» машинасында килеп алды. Мин Әгъзам Фәттах дәресенә киттем. Ул миңа Мансур Мозаффаровның татарлардан беренче профессиональ композитор булуын, әсәрләренең милли музыка сәнгатендәге роле, үзенчәлекләре турында, пианинода уйнап, аңлата-тыңлата дәрес бирде.

— Миңа калса, Мансур ага Тукайга багышлап, аның шигырьләренә таянып опера язарга материал туплый. Сезгә аны тыңлау насыйп булачак, — диде бу урыс телле замана композиторы.

Икенче хәлфәбез Юныс Әминев «Тукай» спектаклебезнең көткән нәтиҗә бирмәвенә сәбәпне үзенчә аңлатты: «Тукай исеме белән кәсеп итәргә ярамый шул. Ул мәдхияләргә түгел, иярченнәргә мохтаҗ. Тукай тирәнлегенә төшәбез дип, яисә, күп чак, шагыйрь күтәрелгән биеклеккә менәбез дип, аны үзләре ясаган ялганда яшәтмәкче булалар. Иләктә су тормагандай, Тукайны ясалма мохиттә ябып яшәтеп булмый. Әгәр Мансур абый синең аша сезнең студиягә ышаныч баглаган икән — аның ышанычын акларга тырышу — Тукайча булыр».

Казанга кайтып театрда эшли башлагач, радиода режиссер вазифаларын үтәгәндә Исмай ага Шәмсетдинов белән бер бүлмәдә утыра идек. (Гәрчә, Исмай абыйның утырган чагын хәтерләмим.)

Беркөнне Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган «Тукайны сагыну» җырын монтажлаучы Исмай абый янына Мансур абый килеп керде. Үзе кузгатмагач, беренче очрашуыбыздан соңгы хәлләр турында сөйләшәсем бик килсә дә, «исәнмесез»дән тыш сүз әйтешмәдек.

Ике композиторның килешеп эшләүләреннән көнләшеп утырсам да, күңелем һаман Мансур аганың минем иҗат белән кызыксынган сорауларын көттем. Булмады.

Дәшмәде. Минем белән сөйләшүне кирәк тапмады, дияр идем, монтаж эшләрен бетергәч:

— Йә, шәкерт, җиттек Казанга, эшләр ничек? Кайныйбызмы? — диде. Ни дияргә белми аптырап калуымны күргәч, Исмай абыйга карап:

— Нигә сәхнәдә түгел соң бу егет? — диде, гаепләгән кебек.

Исмай абый:

— Икесенә дә өлгерә ул, — дигәч:

— Бүлгәләнүне, икеләнүләрне Тукай кабул итәр идеме икән? — диде дә, кул биреп исәнләшеп, консерваториягә китте.

Өченче һәм соңгы очрашуым Тукай ролен башкарган артистыбыз Дамир Хәйруллинны җирләү көнендә Академия театры фойесында булды. Мансур абыйның чырае авыруга дучар кеше-

неке кебек моңсу, күзләре яшьле иде. Әйткән бер җөмләсе хәтердә: «Нәкъ Тукай яшендә икән...» Берничә айдан Мансур абый үзе дә вафат булды.

Ул күңелсез көннәрдән алып бүгенгәчә ярты гасыр гомер узган. Мансур абый күрергә хыялланган Тукай образын сәхнәдән күрдекме соң? Ул хыялланган образ булгандырмы-юкмы, әмма опера сәхнәсендә «Тукай» образы иҗат ителде. Танылды, бүләкләнде.

Хәтерем алдамаса, Әхмәт Фәйзидән соң, персонажлары исемлегендә Тукай булган 7 пьеса язылып нәшер ителсә дә, шулардан икесе генә сәхнә күрде. Р.Батулланың (1987) һәм Т.Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» (1986) пьесалары буенча куелган спектакльләр иде алар.

Ике автор да минем сабакташларым. Батулла әсәре буенча куелган спектакль тамашачы тарафыннан җылы кабул ителеп (Тукай — Рәфил Сәгъдуллин), театрга башка режиссер баш булгач кына репертуардан төшерелсә (ата арыслан үзеннән алдагы арысланнан туган балаларны үтергән кебек), Миңнуллин әсәре буенча куелган спектакльне (Тукай — Рамил Төхвәтуллин) тамашачы авыр кабул иткәнгә туктаталар.

Чагыштыруым бары шушы гына. Соңрак бу әсәр буенча минем үземә телевизион фильм төшерү насыйп булды. Ул турыда сүз соңрак булачак. Тукай турындагы башка пьесаларга күчкәндә, Г.Камал театрына тәкъдим ителгән Әхәт Гаффар әсәре «Соңгы сәгать»нең куелмау сәбәбе пьесаның сыйфатында булмавы гына мәгълүм.

Ә менә Риза ага Ишморатовның «Моңлы сазым» драмасында, Тукайдан да бигрәк, авторның үз фикерләре өстенлек итүе сәхнәгә юлны япмадымы икән, дигән шик бар. Автор, милләт турында сүз алып барганда, Тукайдан пафос белән публицистик нотыклар сөйләтә: «Әгәр миңа хәят биргән ана телемне, моң-җыр биргән төрки-болгар татарымны яратмасам, аның яхшылыкка нигезләнгән горефгадәтләрен онытa калсам, яшен атар иде мине! Кайбер хәсрәт тарихчылар әйткәнчә, безнең илбасар Батый хан белән бер уртаклыгыбыз да юк. Язмышыбыз рус халкы язмышы белән бер үк. Батый хан рус шәһәрләрен генә түгел, безнең бабаларыбызның туган илен — Болгар дәүләтен дә — тар-мар иткән. Шәһәрләребез, авылларыбызны яндырып хәрабә хәленә китергән. Бабаларыбызның башын кискән, халыкны кырган, таптаган...

Без — болгарлар... Карагрух мулла, Хаҗи, ишаннарны җенем сөйми...»«һ.б., һ.б.

Әгәр сәхнәгә шушы нотыкларны сөйләп, иптәшләре белән даими каршылыкта талашып яшәүдән тәм тапкан Тукай чыккан булса, милләт кул чабар идеме икән? Театр ялгышмаган — куймаган.

Кыскасы, сәхнәләребез Тукай образына мохтаҗ.

Драматургларыбыз ниндидер «Яхиналар» үз «Тукайларын» сәхнәләребезгә менгезеп «шлагбаум» куйганчы уйланырга һәм тәвәккәлләргә тиешләр.

Тукайның иң асыл сыйфатларыннан да асылы — тәвәккәллек һәм һәрчак, һәрхәлдә үзе булып калуы. Шагыйрьгә якынаю ниятендәге иҗатчы өчен язылмаган законнарның беренче статьясы шул булыр.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ ҺӘМ ТУКАЙ

Әгәр исән булса Тукай иң көтеп алынган, иң тансык «телейолдыз» булыр иде... Тукай шигырьләрен өстәл тартмасында саклар өчен язмаган. Тукайның иҗаты, язганнары — шагыйрьнең яшәү, көрәшү рәвеше. Ул акча эшләү максатында язмаган, ул язар өчен, яшәр өчен акча эшләгән.

Телевидение ул сәнгатьнең үзгә, яңа бер төре: мөстәкыйль мөмкинлекләргә бай, төрле үзенчәлекләргә ия, режиссерларга үз таләпләрен дә куючы төре. Без телевизорга төрле театрларның

спектакльләрен «өйгә китереп күрсәтүе» өчен генә дә олы рәхмәтлебез. Ләкин шул изге эшен параллель эшләп, телевидение үзе куйган спектакль яки фильмнарны да юмартларча күп күрсәтте. Татарстанда да. Бездә бу изге эшләрнең башында Гали Хөсәенов дигән режиссер тора. Аның куюында тамашачы Шәйхи Маннурның «Муса»сын, Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры»н, Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»ен күрә. Гали Хөсәенов заманында телевизион спектакльләрне тасмага төшереп алу, аларны саклау һәм кабаттан күрсәтү мөмкинлеге булмау гына кызганыч.

1972 елда Академия театрыннан режиссер булып актер Әхтәм Зарипов күчеп килгән чорда инде телевизион фильм-спектакльләрне тасмага төшереп саклау, монтажлау, үзгәртү-төзәтү һәм, иң мөһиме, кабаттан күрсәтү мөмкинлекләре туа. Нәтиҗәдә, «Яз сулышы», «Тукай», «Каргышлы балачак» кебек күп серияле фильм-спектакльләр тәкъдим ителә.

Телевидение беренче көннән алып Тукайсыз яшәмәде. Эфирда аның шигырьләре, әкиятләре әледән-әле яңгырап, милләткә кирәклеген, яшәвен сиздереп торды. Юбилей көннәрендә генә түгел, тансыкка гына да түгел, ә кирәктә, ситуация сораганда, вакыт Тукай шигырьләрен таләп иткәндә шагыйрь һәрчак «постында» булды. Тансыкка укыла торган шигырьләр һәм шагыйрьләр була. Ә Тукай һәрчак тансык булды һәм шулай кала да. Шагыйрьнең әсәрләре никадәр күп яңгыраса да, тамашачының эфирда аның үз образы белән очрашасы килү теләге беркайчан да сүрелмәде һәм сүрелмәс тә.

Татарстан телевидениесе («Яңа гасыр»га әверелеп, башка чыкканчы) шагыйрьнең һәр юбилеена йә документаль, йә нәфис фильм-спектакль әзерләде. Аларның саны дистәгә җыела. Шулар арасында әйтеп узган шагыйрьнең 100 еллыгына өлгертелгән 5 серияле «Тукай» фильмы, 110 еллыгына тәкъдим ителгән 7 серияле «Каргышлы балачак» һәм 2 серияле «Без китәбез, сез каласыз» фильмнары игътибарга лаек.

«Яз сулышы» — Ибраһим Нуруллинның Габдулла Тукай турындагы хикәяләре нигезендә куелган беренче телевизион спектакль. Сценарий авторы һәм режиссеры — Әхтәм Зарипов. Тукай ролендә Илдус Әхмәтҗанов, Сәгыйть Рәмиев — Әсгать Хисмәтов, Сүнчәләй — Рәсим Сәләхов, Бәшири — Хәлим Җәләлов. (Спектакль архивта сакланмаган.) Бу спектакльгә кадәр режиссер Әхтәм Зарипов И.Нуруллинның «Тукай Петербургта» дигән әсәре буенча (1973 ел, апрель) спектакль куя, Тукай ролен академия театры артисты Николай Дунаев башкара. Спектакль тамашачыга ошаса да, автор И.Нуруллин: «Игътибарны Тукайның авыруына юнәлтеп, аның шигырьләрен, үз идеалларына тугрылыклы максатчыллыгын күрмәгәнсез», — ди. Моңа каршы режиссер: «Димәк, шулай язылган», — дип аклана. Шушы сөйләшүдән соң И.Нуруллин режиссерга шагыйрь тормышыннан алып язылган үз хикәяләре җыентыгын бирә, «чагыштыр, уйлан», ди. Бу китап режиссерга Тукай шәхесенә, иҗатына һәм тормышына карашын тамырыннан үзгәртү кирәклегенә ышандыра. Моңа кадәр Тукай иҗатына бәһа биргәндә, аны замана идеологиясенә яраклаштырырга тырышып, социалист ясап, дәһри итәргә тырышып язсалар, И.Нуруллин хикәяләрендә шагыйрь үз халкын сөйгән, күзе күпне күреп, колагы күпне ишетүче, милләтне яклаучы һәм саклаучы, шигырьләрендә реаль чынбарлыкны чагылдыручы әдип буларак тасвирлана.

Ул дәһри дә түгел, дини фанатик та, коммунист та түгел. Ул — шәхес, кеше! Барыннан да элек ул — үз милләтенең улы! Аның дуслары күп булган кебек, дошманнары да бар. Ул сызлана да, моңлана да, елый да, көлә дә

торган бер татар баласы. «Яз сулышы» шагыйрьнең тууына 90 ел тулган көннәрдә күрсәтелә. Әсәрдә Тукайны халык артисты Илдус Әхмәтҗанов уйнады.

Газеталарда да уңай рецензияләр чыгуга карамастан, спектакльне кабат күрсәтмәделәр; ул фильм төшерелгән тасманы җуйдырдылар. Кем кушуы буенча, кем җуйдырганы сер булмаса да, җуйдыруның сәбәбен әйтү, табу — тыелган.

Шагыйрьнең тууына 100 ел тулуны билгеләп үткәндә телевидение 5 серияле «Тукай» фильм-спектаклен күрсәтте. Тукай ролен Минзәлә театры артисты Фирдәүс Җәмилев башкарды. (Урыны оҗмахта булсын: шул елда ул фаҗигале үлемгә дучар.)

Бу киң колачлы 5 исемле фильм-спектакль турында минем үземә язу уңайсыз да, килешмәгән эш тә.

Студиянең эш расписаниесе белән театрның гастроль графикасы туры килү съемкаларны оештыруны катлауландырса да, Фирдәүснең үҗәтлеге җиңде. Бу яшь артистның Тукайга мәхәббәтен күрсәтсә, тамашачылар яңа Тукай тууга аңа рәхмәтле һәм бәхетле иде.

Татарстан телевидениесе 1996 елда шагыйрьнең тууына 110 ел тулу көннәрендә күрсәткән 7 сериядән торган «Каргышлы балачак» (Тукай ролендә — Илдус Әхмәтҗановның улы Рөстәм) телефильмы турында «Мәдәни җомга»да басылып чыккан «Шагыйрьнең балачагына сәяхәттән соң» мәкаләсенә өстәп әйтер сүз юк.

Телефильмнардан «Без китәбез — сез каласыз» (Тукай ролендә Фәрит Бикчәнтәев) турында үз вакытында республика газеталарында хуплаган мәкаләләр чыкты. Анда да төп рольне Илдус Әхмәтҗанов уйнады. Бу ике телефильм әле «репертуарда» булганлыктан, экраннарда Тукай образы дигән язмабызны шушы урында өзү дөрес булыр. Чөнки шагыйрь образы турында сәнгатькярләребезнең эзләнүләре дәвам итә. ■

«СИРАТ КҮПЕРЕ»

/тамашасы турында нәни генә хатирә/

Кәрим Тинчурин исемендәге драма-комедия театрында (ул вакытта «Күчмә театр» дип атала иде) Тукайның тууына йөз ел тулуга багышлап, «Сират күпере» исемле драма куелган иде. Аның рәссамы – Әхәт Закир, режиссеры Р. Батуллин иде. Баш рольләрне Рафил Сәгъдуллин (Тукай), Зөләйха Хәкимҗанова (Зәйтүнә), Марсель Җаббаров (Шәүлә) башкардылар.

Тукай ролендә – Рафил Сәгъдуллин, Зәйтүнә ролендә – Зөләйха Хәкимҗанова

Иң беренче рәссамның уңышлы эше турында хатирәләр яңартыйк. Әхәт Закир гаҗәеп талантлы шәхес иде. Аның куелышында «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле Камал театрында дистәләрчә ел уйналды. Күчмә театрда да, рәссам буларак, ул бик күп уңышлы спектакльләр куйды. Аның сурәтле күзаллавы (художественное видениесе) искиткеч төгәл һәм шушы әсәргә тәңгәл килә иде.

Тукай — «халыклар төрмәсе» булган Русиядә яшәгән шагыйрь. Әхәт, әнә шул канатлы тәгъбирдән чыгып, сәхнә

җиһазларын иҗат итте. Сәхнәнең арткы пәрдәсендә ике башлы кара кош (халыкларны изүче империализм символы) канатын җәйгән, Тукай яши торган бүлмә төрмә камерасы кебек, читлеккә уралган. Сәхнәдә өстәл урынында да, ятак урынында да тартмалар, алар җәймә белән капланган, соңыннан ул җәймәләр ачылып китәр, жандармнар Тукай бүлмәсендә тентү ясаганда чаршауларны, җәймәләрне туздырып ташлар, өстәл һәм ятак вазифасын үти торган тартмаларны текә бастырып куярлар һәм анда зур-зур хачлар (тәреләр) ясалган булыр. Шул әле генә өстәл, ятак вазифасын үтәгән хачлы тартмаларны бастырып куйгач, сәхнә караңгы-куркыныч зиратка әверелер. Бу да Әхәтнең сурәтле иҗатыннан килә, монда киная дә, ишарә дә, мистика-эзотерика да бар. Тукай әнә шул кабер ташлары арасыннан якты залга, халык арасына төшеп китәр.

Тукай роле Рафил Сәгъдуллинга тапшырылган иде. Рафил Тукайның үзенә игезәк сыңары кебек тач охшаш артист. Шул ук кылыч борын, киң маңгай — нәкъ Тукайның үзе инде. Бик авыр роль эләкте Рафилгә, ике сәгать буена Тукай сәхнәдән чыкмый. Бу гаять авыр йөк артист өчен, ул һәрвакыт киеренке мохиттә, аны дошманнары да борчый, дуслары белән дә ул гел бәхәстә. Рафил Сәгъдуллинның — Тукайның спектакль азагында киемнәре сыгып алырлык тиргә манчылган була иде. Рафил бу рольне уйнап, йөзгә кызыллык китермәде, Аллага шөкер.

Зәйтүнә ролен артистка Зөләйха ханым Хәкимҗанова башкарды. Ул сәхнәдә Тукай белән нибары ике тапкыр гына очраша. Шушы ике тапкыр очрашу тамашачы күңелендә якты истәлек булып калды. Зөләйханың Зәйтүнәсе тыйнак, сабыр, шигъри җанлы зат. Ул Тукайга җаны-тәне белән тартыла. Ләкин соңгы көрәшүдә Тукай аннан баш тарта. Бу — икесе өчен дә фаҗига.

Артист Марсель Җаббаровның Шәүләне уйнавы артист өчен дә, театр өчен дә, тамашачы өчен дә яңалык иде. Шәүлә — Тукай артына куелган җасус, әләкче, шымчы. Ул теләнче сәләмәләренә уранып, Тукайның ышанычын казана һәм барысы турында да жандармериянең өченче бүлегенә түкми-чәчми җиткезеп тора. Чынын гына әйткәндә, Марсель Җаббаровның бу спектакльдәге Шәүлә роле «иң уңышлы» дип бәяләнергә хаклы иде. Җаббаров бу рольне уйнарга бик әзерлекле килде, күзәтүчән Тукайны үзеннең җандарм әнчеге түгел, базар хәерчесе икәнеңә ышандыру шактый катмарлы хезмәт таләп итә иде. Тамашачы да баштан азагына чаклы хәерченең хәерче икәненә ышанып утыра. Азакта бу теләнчене киемен алыштырган жандармерия офицеры икәнен аңлагач, Тукай да, тамашачы да аптырап кала.

Пьесаны сәхнәгә куючы үзем булганга күрә, режиссура турында фикер куертырга хакым юктыр бәлки, шулай да әйтим, артистларның уенынннан, рәссамның уңышлы эшеннән мин канәгать калдым. Артистлар бик теләп, бик бирелеп эшләделәр бу тамашада. Һәм без — артистлар, рәссам, Тукай белән бергә җиңүче булып чыктык, шөкер. Чөнки бу пьесаны репертуарга алганда да, эш барышында да: «Ай-һай, җиңә алырсызмы бу авыр драманы, Сират күперен чыкканда тәмугка егылып төшмәссезме?» — дип шикләнүчеләр дә күп иде. Тукай үзе, Аллаһы Тәгалә үзе ярдәм итте бугай! Без җиңдек, шөкер!

«Сират күпере» пьесасының авторы,
пьесаны сәхнәгә куючы режиссер —
Рабит Батулла.
2016, 14 февраль

ИЛДУС ӘХМӘТҖАНОВ: «ТУКАЙ МИҢА МӘРХӘМӘТЛЕ БУЛДЫ...»

Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык артисты, Русиянең атказанган артисты Илдус Әхмәтҗанов Тукай рольләрен башкару тарихы турында истәлекләре белән уртаклашты[1].

Габдулла Тукай рольләрен уйнау матур мизгел, дип кенә әйтер идем. Беренче тапкыр аны телевизион фильмда уйнадым. Тукайның тууына 90 ел тулу уңаеннан, 26 яшемдә. Икенче мәртәбә 100 ел тулу уңаеннан театр сәхнәсендә. Тукай ролен уйнау ике очракта да миңа шулакадәр дулкынландыргыч зур вакыйга булды. Тукайга килү, Тукай роленә әзерлек чоры шактый озын булды, мәктәптә түгел, хәтта мәктәпкәчә яшьтә үк башланды, дисәм хата булмас. Безнең гаиләдә шундый күркәм гадәт бар иде: кычкырып китап уку. Кич белән, эшләр беткәч, бөтен гаилә кешеләре җыела идек тә, Рәшит абыем[2] безгә китап укый иде, аеруча Тукай шигырьләрен яратты. Сабый вакытымнан ук аның «Таһир-Зөһрә» кыйссасын укыганы истә калган. Әни, башка хатын-кызлар елый-елый тыңлый иде... Бераз үсә төшкәч, үзем дә Тукай шигырьләрен яттан укый башладым. Сабый баланың хәтере яхшы була. Минем дә, гомергә онытылмас булып, шул чордан ук Тукай шигырьләре күңелемә сеңеп калды. Мәктәптә укый башлагач, Рәшит абыемдагы көрән тышлы Тукай томнары минем кулга күчте. Габдулла Тукайның бөтен шигъриятен, прозасын, хәтта китапның артындагы искәрмәләрен дә укып, шул чордагы язучыларның, шагыйрьләрнең исемнәре, Тукай әсәрләрендәге геройлар, образлар белән тирәнрәк танышып, рухи дөньямны баеттым. Болар барысы да Тукай ролен уйнарга әзерлек булгандыр...

***

1976 ел. Апрель ае. Ул миңа кичәге көн кебек кенә тоелса да, инде 40 ел вакыт узып киткән. Ләкин мин һаман шул көннәр тәэсиреннән арына алмыйча, шул чордагы вакыйгалар әсирлегендә яши бирәм. Чөнки бу чор минем Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли башлаган бәхетле яшьлек елларым һәм... 1976 елның апрель аен мин икенче мәртәбә, өр-яңадан, Тукай күлмәген киеп дөньяга килгән — туган көнем дип тә саныйм. «Тукай күлмәгендә» дигән сүз укучыларны сискәндермәсен иде. Мин бу гыйбарәне һич кенә дә үземне Тукай белән тиңләштерергә, йә булмаса, үземне гайре табигый кеше итеп күрсәтергә теләп әйтүем түгел. «Бәхетле бала күлмәге белән туа» дигән әйтем бар бит. Әйткәнемчә, мин үземне бик бәхетле итеп саныйм. Һәм бу бәхетемнең чыганагы, әлбәттә, Тукайга барып тоташа. Сөекле шагыйребезнең тууына 90 ел тулган юбилей елында Казан телевидениесе Тукайга багышлап телевизион фильм төшерергә карар

---

[1] Илдус Әхмәтҗанов сөйләгән истәлекләрнең видеоязмасы белән beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин.

[2] Илдус Әхмәтҗановның абыйсы Рәшит Әхмәтҗанов (1941-1995) — шагыйрь, журналист, татар милли хәрәкәте активисты.

Илдус Әхмәтҗанов –
Тукай ролендә

кыла. Фильмга сценарийны күренекле артист һәм режиссер Әхтәм Зарипов яза, шулай ук фильмның режиссеры итеп тә аны тәгаенлиләр.

Көннәрнең берендә Әхтәм абый безнең театрга килеп, үзенә кирәк булган артистларны җыеп алды да (бәхетемә, исемлектә мин дә бар идем), «Яз сулышы» дип аталган әсәрен укыды. Әсәрнең төп герое, әлбәттә, Габдулла Тукай. Сценарий барыбызга да ошады. Хуплап кабул иттек. Чөнки ул күләме белән дә, әйтергә теләгән фикере, теле, стиле, динамикасы шул чор атмосферасын төгәл чагылдыруы белән сценарий таләпләренә тулысынча җавап бирә торган әсәр булып, анда Тукай иҗаты, аның хатлары, Тукай турындагы истәлекләр автор тарафыннан баетылып, ышандыру көченә ия булган сәнгати чаралар ярдәмендә драматик калыпка салынган иде. Безне алда киеренке һәм җаваплы эш көтә иде. Вакыт бик аз калган. Тукайның туган көненә — 26 апрельдә фильм экраннарга чыгарга тиеш.

Мин бу очрашудан бәхет дәрьясына ташланган мәҗнүндәй түбәм күккә тиеп кайтып киттем, чөнки минем кулда олуг хәзинә — Тукай роле иде. Ләкин бу эйфория озакка бармады. Беренче репетицияләрдә үк, көймәм комга терәлеп, төшенкелеккә чумдым. Әллә тәҗрибәсезлектән, әллә Тукай шәхесенең бөеклеге ирешеп булмаслык биеклек булып шиккә төшердеме — минем җаным да, тәнем дә акылыма буйсынмыйча карыша башладылар. Репетицияләр минем өчен газапка әйләнде. Мин һаман бер урында таптанам. Үсеш, алга барышның әсәре дә юк. Инде Әхтәм абыйның да күңеленә шом керә башлады бугай. Ул, аптырагач, ничек уйнарга икәнен үзе күрсәтеп бирә башлады. Бу алым, режиссерның артистка булган ышанычы тәмам беткәннән соң гына кулланыла торган, тыелган алым. Аның уены миңа шулкадәр тәэсир итә, мин аны чын Тукай итеп кабул итәм, тетрәнеп карап торам, ләкин кабатлый алмыйм. Шундый мизгелләрнең берсендә мин режиссерга: «Әхтәм абый, нигә үзегез генә уйнамыйсыз Тукайны?» — дип әйтеп салдым. Ул бәлки, мине киреләнә, капризлана дип уйлагандыр, озак кына түшәмгә карап уйланып торды да, берни әйтмичә, репетициядән чыгып китте. Мөгаен, мин аның авырткан җиренә кагылганмындыр. Ул репетицияләрдә безгә Тукайның тормышыннан, иҗатыннан шулкадәр күп мәгълүмат бирә иде, ул мәгълүматның байтак өлешен ул заманда хәтта китаплардан да эзләп табып булмый иде. Бу — бер-ике ай эчендә генә тупланган мәгълүмат түгел иде. Димәк, ул бөтен гомере буе Тукай иҗатын өйрәнгән, эзләнгән, тапкан... һәм бүгенгә кадәр хәтер сандыгында саклаган. Ник? Тукай турында фильм төшерәм дипме? Юктыр, чөнки сәнгать дөньясына ул иң элек режиссер буларак түгел, ә актер буларак килеп кергән кеше. Мөгаен, ул әнә шул актерлыкка укыган елларында ук Тукай ролен уйнарга хыяллангандыр һәм, шул теләген тормышка ашырырга теләп, Тукайның тормышын, иҗатын өйрәнгәндер. Яшь чагындагы фотоларына күз салсаң, аның тышкы кыяфәте белән дә Тукайга охшаган булуын күрми мөмкин түгел. Бәлки ул үзенең ниндидер сәбәпләр аркасында тормышка ашмаган хыялын минем аша тормышка ашырмакчы булгандыр?! Аның ышанычын аклый алырмынмы соң? Ай-һай...

Әнә шулай өмет белән шик арасында яши-яши фильмны тасмага төшерү көне дә килеп җитте. Иртәнге якта телестудиягә җыелдык. Анда декорация, барлык кирәк-ярак, кием-салым, аппаратура әзер. Тиешле шартлар һәм атмосфера тулысынча тудырылган. Ниһаять, мин, гримланып, Тукайны уйныйсы киемнәрне киеп, Болгар кунакханәсендәге 40 нчы номерны хәтерләткән декорация-бүлмәгә кереп, язмышыннан качып котылырга теләгән кешедәй, баштанаяк одеялга төренеп, тимер караватка менеп яттым. Мин бизгәк авыруыннан туңып калтыраган Тукайны уйнарга тиеш идем. Дөрес, одеял астында чынлап та калтырыйм, ләкин бизгәктән түгел, ә куркудан. «Төшерә

башладык» дигән сигнал көтеп ятам. Ул сүзләр минем колакка тиз генә килеп ирешмәсеннәр иде, дигән уй башымнан чыкмый. Хыялым — одеял астында, караңгыда мөмкин кадәр озаграк яту, хәтта, мәңге шуннан чыкмаска да риза. Әмма, бу хыял гына. Чынбарлыктан качып булмый. Төшерү процессы башланды… Көтмәгәндә одеял аша ягымлы, кайгыртучан, җанга якын хатын-кыз тавышы ишетелгәндәй булды. Чү!? Мәрхүмә әнием тавышы бит бу. Шул мизгелдә минем зиһенемдә нindидер бер балкыш, нурланыш, яктылык хасил булды. Шул мине реаль дөньядан башка дөньяга алып кереп китте. Миндә ниндидер үзгәреш пәйда булды. «Бу минме соң?!» — дип, үз-үземнән шикләнә башладым. Куркуданмы, әллә реаль дөньяга кабат кайтасы килүдәнме, яшен тизлеге белән бөркәнгән одеялымны бер читкә алып аттым. Әмма реаль дөньяга кайту насыйп булмады: мин әнием тавышы белән сөйләшүче кунакханә хадимәсе (артистка Вера ханым Минкина) белән әңгәмә корып җибәрдем. Һәм фильмның башыннан ахырына кадәр әнә шундый гайре табигый халәттә сәер дөньяда яшәп алдым. Ниһаять, фильмны төшерү тәмам, дигән мәгънәне аңлаткан таныш «стоп» сүзе мине яңадан чынбарлыкка, бүгенгемә, ягъни реаль дөньяга кайтарды. Режиссер барыбызны да котлап, рәхмәт әйтте. Без — артистлар да аңа рәхмәтебезне әйтеп үзара котлаша башладык. Ләкин минем күңелдә кабат шикшөбһә. Котлашулар да формаль котлашу гынадыр сыман тоелды. Шундый халәттә саубулашып кайтып киттем. Атна-ун көн ашым — аш, йокым — йокы булмады, дөньяга чыгарга, кешеләргә күренергә куркып яшәдем. Ниһаять, Тукайның туган көне — 26 нчы апрельгә бер көн кала фильмны экраннарга чыгардылар. Япа-ялгызым калып, бөтен дөньясыннан качып, өмет белән шик арасында, сәгате җиткәч, телевизорны ачып җибәрдем. Башланды… Күз йомарга да куркып, һәрбер әйтелгән сүзне, һәр хәрәкәтне игътибардан читтә калдырмыйча фильмны ахырына кадәр карап бетердем… Һәм… әйтергә кирәк, көтмәгәндә, фильм миңа ошады! Үземнең уенымны да шул исәпкә кертеп әйтүем бу. Өстән тау төшкәндәй булды. Дөнья яктырып китте һәм шул дөньяда яшисе килә башлады. Чү! Тукта, әгәр дә бу голюцинация генә булса?! Йокысыз төннәр, борчулы көннәр тудырган авыру миңа үзем күрергә теләгән хыялымны гына күрсәткәндер, бәлки?..

Күңелдәге шатлык хисләре белән аяусыз көрәш алып барган әнә шул шик күңелнең бер почмагында һаман патшалык итә иде әле. Башымны бик югары күтәрмичә генә урамга чыгып киттем, театрга — эш урыныма юнәлдем. Театрга җиткәнче миңа берничә тапкыр. «Әнә, Тукай», — дип бармак төртеп күрсәтеп калдылар. Әллә мыскыл итүләре инде? Алай дисәң, йөзләрендә, күзләрендә бертөрле дустанә караш, елмаю чагыла. Барысын да яхшыга юрыйм да, алга баруымны дәвам итәм.

***

Икенче тапкыр шагыйрьне Тукайның йөз еллыгында уйнадым. Туфан Миңнуллин пьесасы буенча куелган «Без китәбез, сез каласыз» спектаклендә. Бу чорда инде мин Тукай яшен дә узып киткән, шактый тәҗрибә туплаган артист идем. Беренче мәртәбә 26 яшемдә уйнасам, хәзер 36 яшь... Шагыйрьнең йөз еллыгына Әхтәм Зарипов икенче, күп серияле фильм әзерләгән. Миңа Тукай ролен тәкъдим итте, ләкин мин аңа алынмадым, чөнки телевидение өчен үземне өлкәнрәк дип санадым. Аннан вакытым да булмады... Театрда да Тукай ролен уйнау башланды, телевидениедә дә башланырга тиеш иде. Мин, әлбәттә, театрны сайладым. Спектакльдә Тукайның Акчуриннарга кунак булып бару чоры күрсәтелә. Икенче тапкыр Тукайны уйнарга туры килсә дә, телевизион спектакльдәге Тукай белән театрдагы Тукай арасында шактый аерма бар. Авторлар әйтергә теләгән фикер башка, вакыйгалар, персонажлар да үзгә... Әмма шул ук авырлыклар, шул ук борчулар... Бу юлы инде мин рольгә очраклы килеп эләкмәдем, ниндидер кабынып китүләр дә башка килмәде. Алар кирәкмәгәндер дә, чөнки мин инде шактый тәҗрибә туплаган артист идем, сәхнәдә фикерләвем дә башкачарак булды...

Минемчә, спектакль бу очракта да уңышлы килеп чыкты. Тукай үзенең халык язмышы өчен борчылып яшәвен һәм халык бәхете өчен көрәшүен күрсәтте, дип уйлыйм. Акчуриннар белән бәхәскә кереп, хәтта аларга каршы шактый гына каты сүзләр әйтергә дә мәҗбүр булды.

Спектакльнең режиссеры Марсель абый Сәлимҗанов иде. Ул артистларны да бик сайлап, иң яхшыларын гына туплады. Тукайның йөз еллыгы! Җаваплылык гаять зур иде.

***

Телевизион спектакльдән соң миңа урамда, гомумән, бөтен җирдә Тукай дип дәшә башладылар. Бу миңа бер рәхәтлек тә бирә иде... Икенче көнне шагыйрь хөрмәтенә уздырыла торган шигырь бәйрәменә юл алдым. Анда исә мин, көтмәгәндә, шул көннең героена әверелдем. Бәлки алай ук та булмагандыр, ләкин миңа шулай булып тоелды. Котлаулар, котлаулар һәм котлаулар... Бу котлауларны ишетү рәхәт булса да, һаман җиз иләк аша үткәреп кенә кабул итәм. Шулвакыт дуслары белән ни хакындадыр сөйләшеп торган Мөхәммәт ага Мәһдиев мине күргәч: «Менә бу егет татар халкына Ходай тарафыннан Тукайны уйнар өчен җибәрелгән егет», — дип әйтеп салмасынмы! Туры сүзле, юк-бар мактаулар белән мавыкмаучы Мөхәммәт абыйның бу сүзләре котлауларның кыланып әйтелгән юкбар сүзләр генә түгеллегенә, ниһаять, ышандырды. Иелебрәк килгән башым югары күтәрелде һәм күзләрем көннең кояшлы, аяз булуын абайлады. Мөхәммәт абыйның бу сүзләренә соңрак Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевның миңа мактаулы исем тапшырганда әйткән: «Илдусны күргәч, Тукайның үзен күргән кебек булам», — дигән сүзләре, һәм Мостай ага Кәримнең: «Тукай ролен башкаручы Илдус Әхмәтҗанов яхшы уйнады. Тукай тормышчан, ышандыра. Артист шагыйрь образын әдәпле итеп, югары культура күрсәтеп башкарды», — диюе, янә Мөдәррис Әгъләмовның: «Мин Казан буйлап Тукайны эзлим.

һәм миңа аны күреп калырга насыйп булды. Ул изге зат — Илдус Әхмәтҗан кыяфәтендә иде. Илдус Әхмәтҗан — Тукайлы гасырның асыл баласы», — дип әйтүе һәм башка әдәбият-сәнгать әһелләренең дә Тукайны уйнавым хакында матбугатта басылып чыккан матур-матур фикерләре халыкның: «Әнә, Тукай килә», — дигән сүзләрен тәфсир кылу, шәрехләү булып яңгырый сыман.

Хәзер дә, Тукай яшен узып китеп, өченче тапкырын атлап килүгә карамастан, һаман да Тукай дип дәшәләр. Хәтта Тукай шигырен сөйләргә чыксам да: «Менә телевизордан күрдек, Тукай булып чыктың», — диләр. Халык мине шигырь укучы итеп түгел, ә Тукай итеп таный башлады.

***

Абыем, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның спектакльне бәяләгәнен хәтерләмим, ләкин шулкадәр борчылып, театрга уйнарга килгәнче үк, ишек төбендә мине каршылап, аннары озатып калуы хәтердә. Ул шулкадәр бирелеп, борчылып, минем өстә сакчы фәрештә сыман торды.

***

Тамашачылар, мәктәп укучылары белән очрашулар вакытында миннән еш кына: «Тукай ролен уйнау авыр булдымы?» — дип сорыйлар. Хикмәт авырлыкта гына түгел. Татар артистлары арасында теләсә нинди авырлыклардан да курыкмаучы, миннән күпкә талантлырак артистлар байтак. Ләкин Тукай ролен башкаручы һәм халык тарафыннан «Тукаебыз» дип кабул ителгәннәре сирәк. Сәбәп нидә? Ирексездән Мөхәммәт ага Мәһдиевнең сүзләре искә төшә: «Ходай тарафыннан җибәрелгән»... Бәлки, чынлап та, шулайдыр, Ходай тарафыннан җибәрелү кирәктер!

Ә шулай да Тукай кебек бөек шәхесне уйнау җиңел түгел, бик җаваплы эш. Әгәр сиңа ул эшне йөклиләр икән, әгәр син шул эшкә алынасың икән, димәк, җилкәңә авыр таш-тау китереп салалар да, син шуны күтәрергә тиеш буласың. Ул авыр йөккә чыдый алмыйча, йә имгәнәсең, йә әкияттәге кебек башта тез тиңентен, аннан билдән, ахыр чиктә муеныңнан җиргә батып күтәргән тавың астына күмелеп каласың.

Аллага шөкер, миңа башка язмыш насыйп булды. Тукай мине батырмады, киресенчә, көчле куллары белән күтәреп, куенына кысты, бәла-казалардан саклап калды.

***

Тукай — татар халкы бәхете өчен көрәшеп яшәгән кеше. Анда — көчле көрәшче рухы. Күрәсең, шушы рух миндә дә Тукай иҗаты аша тәрбияләнгәндер. Мин үзем дә татар халкының азатлыгы өчен борчылып яшим. Мин хәзер дә халкым, милләтем өчен соңгы чиккә җитәргә әзер.

Мин үземне бәхетле кешегә саныйм. Чөнки Тукай миңа мәрхәмәтле булды. Дәрәҗәле исемнәр бирелүе дә, Тукай премиясе лауреаты булуым да, барысы да, барысы да Тукайга, аның иҗатына барып тоташа...

***

Тукай — журналист. Байтак газета-журналларны чыгаруда катнашкан. «Безнең мирас» журналы шулкадәр әйбәтләнде, без, театр артистлары, журналны рәхәтләнеп кулдан-кулга йөртеп укыйбыз һәм барыбызның да теленнән: «Безнең мирас» журналы шулкадәр затлы», — дигән сүзләр ишетелә. Журналлар арасында беренче урында тора, дип бәялибез. Тукай да, әлбәттә, мактар иде, чөнки «Безнең мирас» журналы шулкадәр күп, җитди, милли темаларны күтәрә, тарихны, бүгенге көнне дә яктырта. Әлбәттә, Тукай: «Булдырасыз, егетләр», — дип әйтер, ләкин шулвакытта шагыйрь бик әче телле дә булган бит әле! Ул яратып, әче итеп, чеметеп алырга да сүз табар иде...

Язманы ***Әхтәм Зарипов*** *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

«ШҮРӘЛЕ» БАЛЕТЫНЫҢ КАТЛАУЛЫ ТАРИХЫ

Аида Алмазова

Татар музыкасы тарихында Фәрит Яруллин (1914-1943) үзенә аерым бер урын алып тора. Танылган халык музыканты һәм композиторы Заһидулла Яруллин улының гомере бик кыска. Сугышка кадәр ул Казан музыка техникумында, Мәскәү консерваториясе каршындагы татар опера студиясендә укый. 20ләп җыр, 3 романс, берничә инструменталь-камера әсәре, виолончель өчен соната һәм симфония иҗат итәргә өлгерә.

Ф.Яруллин. Казан училищесы шәкерте

Беренче татар балеты «Шүрәле» — аның опера студиясен тәмамлаганда иҗат иткән диплом эше. Композитор балетның клавирын төгәлләргә өлгерә. Сугыш башлана, ул фронтка китә. Ә 1943 елда, үзенең балетын сәхнәдә күрә дә алмыйча, 29 яшендә һәлак була. Балет беренче мәртәбә 1945 елның мартында Казанда куела, ә аннан соң Петербургта (1950), Мәскәүдә (1955), шулай ук Германиядә, Польшада, Болгариядә, Румыниядә һ.б. күп кенә илләрдә башкарыла.

1945 елның мартында, «Шүрәле» балеты башлап сәхнәгә чыккан көннәрдә, әсәрнең авторлары дип Фәрит Яруллин һәм язучы Әхмәт Фәйзи игълан ителә. Ә партитурасын Мәскәү композиторы Фабиан Витачек төгәлләгәнен күрәбез. Бераз соңрак, 1950 елда, балет С.М.Киров исемендәге Ленинград опера һәм балет театрында яңадан куелды. Әсәрнең исеме бу постановкада «Али Батыр» дип үзгәртелгән һәм авторлары арасында, либреттчы буларак, хореограф Леонид Якобсон, музыка авторлары итеп, В.Власов һәм В.Фере фамилияләре өстәлгән иде. Табигый ки, укучыда либреттоны иҗат итүгә Ә.Фәйзи һәм Л.Якобсон нинди өлеш керткәннәр һәм шулай ук әсәрнең музыкасын язуда Ф.Яруллинның роле нинди булган икән соң, дигән сорау туа.

Тукайның «Шүрәле» әкияте буенча балет язу фикере 1938 елда ук туган булса кирәк. Чөнки беренче инструменталь фрагментларны кәгазьгә төшерү, жанрның ачыклануы шушы вакытка туры килә. Либретто язу эше Әхмәт Фәйзигә тапшырыла. Композитор Н.Җиһанов архивында шундый фоторәсем сакланып калган: «Шүрәле» либреттосын «кече коллегия»дә тикшергән көнне Г.И.Литинский, Н.Җиһанов, Ф.Яруллин, Ә.Фәйзи бергә рәсемгә төшкәннәр. Либреттоның Ленинград дәүләт архивында саклана торган беренче варианты 1939 елның

Г.Литинский (утырган), Н.Җиһанов, Ф.Яруллин, Ә.Фәйзи

27 февралендә тәмамланган. Димәк, Ф.Яруллин балетны 1938-1939 елның башында яза башлаган, дип әйтә алабыз.

Балет либреттосын язуга Әхмәт Фәйзи бик зур җаваплылык белән алына. Халык әкиятләрен, Тукай әсәрләрен тагын бер мәртәбә карап чыга. Үзенең сүз башында әйткәнчә, либреттога нигез итеп шагыйрьнең «Кышкы кич», «Көтмәгәндә», «Буран», «Суык», «Су анасы», «Бала белән күбәләк», «Таз», «Һәр ялтыраган алтын түгел» шигырьләрен һәм, әлбәттә, «Шүрәле» поэмасын ала. Либретто үз вакытында матбугатта чыкмаган, ә кулъязмасы исә яңа табылды.

Ә.Фәйзи либреттосының Санкт-Петербург дәүләт архивында сакланган кулъязмасыннан (3827 фонд, 1 тасвирлама, 161 эш) кыскача эчтәлек:

«Авыл йорты. Тәрәзә артында буран улый. Өйдә әби оныкларына әкият сөйли. Орчык безелдәвенә ияреп, беренче әкият башлана... Кар өермәсе эченнән кышкы, куе кара урман күренә. Шүрәлеләр төркеме барлыкка килә, алар, шатлыктан котырынып, өермәдәй бөтереләләр. Баш Шүрәле килеп керә, аның балалары төрле якка таралышып карлы-бозлы чыршы ботакларына сыенышалар. Урман хуҗасы үзе генә бии һәм ул биегәндә

буран басыла. Шүрәленең тамыр сыман бармаклары бер кыскаралар, бер озынаялар. Хуҗа ярсып котырына, аңа ияреп Шүрәле балалары да котыыналар. Туктаусыз шау-шулы буран улавына кушылып, Шүрәле балалары да бии. Сәхнәдә сызгырып котырынган биюче шүрәлеләр бөтерелә.

Бер аралыкта барсы да югала: ерактан кулына орчык тоткан карчык күренә. Икенче әкият башлана... Аланлыкта адашкан аучылар төркеме килеп чыга. Араларыннан берсе җәнлекне эзләп китә. Башкалары да аңа иярә. Озын бармакларын селкетеп Шүрәле керә. Ул агач кәүсәләренә ташланып, аларны кытыклый, тик тою сәләтләре булмаган агач кәүсәләре хиссез генә торалар. Шулвакыт кулына чыбыркы тоткан егет — Былтыр килеп керә. Шүрәле шатланып Былтырга ташлана. Егет чыбыркысы белән аның бармакларына суга. Шүрәле чыелдап кирегә сикерә. Былтыр, чыбыркысын оста кулланып, Шүрәлене үзенә якын китерми һәм сәхнәдән югала.

Бер кочак чыбык-чабык күтәреп, адашкан карт белән аның кызы Биби керә. Арып, хәлдән таеп, алар ял итәргә утыралар. Кинәт Шүрәле Бибигә ташлана һәм аны кытыклый башлый. Карт аларның арасына баса, Шүрәле картны кытыклый башлый. Биби ярдәмгә кешеләр чакыра. Чыбыркылы Былтырны күрүгә Шүрәле юкка чыга.

Алга таба алтын таракны Су анасы белән малай турында яңа әкият башлана.

Урман аланында яшьләр күңел ачалар. Сәхнәгә Биби артыннан бәйләнеп йөрүче бай чыга. Шүрәле кыяфәтендәге Тазның маҗаралары һәм киеме астындагы савыт-саба белән аны бөтен кеше каршында көлкегә калдыралар. Биредә яшьләрнең биюләре, уеннары. Былтыр белән Бибинең мәхәббәтләре калку итеп күрсәтелә.

Тагын урман. Былтыр килә. Йокысыннан уятылган Шүрәле керә. Бүрәнәне бергәләшеп арбага салу шарты куеп, Былтыр Шүрәле белән «кетикети» уйнарга ризалаша. Шүрәле бармакларын ярыкка тыга, шулвакыт егет балтасы белән бүрәнә ярыгындагы чөйне кагып чыгара. Шүрәленең бармаклары кысылып кала, Шүрәле урман яңгыратып акырырга тотына. Шүрәле балалары йөгерешеп киләләр. Башта алар куркып калалар, ә инде үзләренең иректә калганлыкларын тойгач, пыр тузып әйлән-бәйлән уйнарга керешәләр. Таң ата.

Либретто халыкчан сюжетка корылган, образларның милли характеры, халык фантазиясе белән тудырылган әкият дөньясы анда күркәм чагылыш таба. Ул милли уен һәм биюләр, шаян һәм тапкыр Таз малайның хәйләләре һәм башка яклары белән күңелне җәлеп итә. Әмма либреттода вакыйгаларның шактый таркау булуы, сюжет чуарлыгы күзгә ташлана. Сәнгать белгече В.Чистякова язганча, *«Биюле жанр үзенең табигате белән тормышкөнкүреш детальләреннән, төрле вак нәрсәләрдән арынуны таләп итә... Шигъри гомумиләштерелгән образлар, көчле тәэсирле, киеренке-эмоциональ конфликт – нәкъ әнә шулар балетның рухына җавап бирә»*. Әхмәт Фәйзи либреттосында вакыйгаларның күплеге, социаль һәм көнкүреш детальләре белән чуарлау нык сизелә, «театраль романтика» җитеп бетми, төп конфликт тиешле дәрәҗәдә калку гәүдәләнми кала.

Әмма шунысын да әйтергә кирәк, әлеге кимчелекләр табигый күренеш тә була. Башлап җибәрү һәрвакыт кыен. Авторның балет либреттосын язуда тәҗрибәсе булмый диярлек. Ә жанр хосусиятен үзләштерү балет өчен аеруча мөһим нәрсә. Шуңа күрә балетны 1941 елда Мәскәүдә үтәсе Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында күрсәтергә карар ителгәч, балетмейстер белән бергә либреттоны тиешле дәрәҗәгә җиткерү мәсьәләсе килеп

Болгариянең София шәһәрендә – «Шүрәле» балеты

баса. «Шүрәле»нең балетмейстеры итеп билгеләнгән Л.Якобсон либреттога күп кенә үзгәрешләр кертә. Аның варианты Фәйзи либреттосына (беренче вариантына да, икенче вариантына да) аз охшаш. Ул драматик сюжетны бөтенләй башкача кора, интрига да, вакыйгалар да бөтенләй башка. Хәтта әсәрнең идеясе дә икенче якка үзгәреп киткән, катнашучы геройлар да үзгә.

Л.Якобсон либреттосының кыскача эчтәлеге.

Кара урман. Болытлар арасыннан ай нуры күренә. Урманга Былтыр килеп чыга. Калын имәнгә карап, ул агачны чөйсез ярып булмасын аңлый. Калын агач ботагы кинәт җанлана. Бу ботак түгел, бу Шүрәле үзе. Сикереп төшеп, ул аланга чыга. Аның әйләнәсенә тиз генә җен-пәриләр, шайтаннар җыела, алар урман хуҗасының

«Шүрәле» балетына костюм эскизлары. Рәссам Любовь Сперанская. Кәгазь, акварель. 1953

күңелен табу өчен кыланырга тотыналар. Ләкин кояш нурлары күренүгә качып бетәләр.

Ак каурыйлары белән җемелдәп, алан уртасына кошлар төшә. Араларында — гүзәл Сөембикә. Канатларын ташлап, кошлар кызларга әверелә дә, уйнап-биеп күңел ачарга тотына. Алар артыннан Шүрәле күзәтеп тора. Ул Сөембикәнең канатларын урлап кача.

Очып китәр вакыт җиткәч, барысы да канатларын киеп китәләр. Сөембикә үзенең канатларын таба алмый һәм зур кайгыга чума. Көтелмәгәндә Шүрәленең пәйда булуы аны нык куркыта. Шүрәледән котыла алмыйча Сөембикә хәлдән тайганда, агачлар арасыннан Былтыр чыга. Кеше белән урман хуҗасы арасында аяусыз көрәш башлана. Бер мизгелдә, егет Шүрәлене җиргә бәргәндә, ул озын бармаклары белән агач ярыгына тотына, Былтыр үзе элек каккан чөйне тиз бәреп чыгара. Егет Сөембикә белән бергә канатларны эзләп таба алмагач, мескен кыз хәсрәткә бирелеп елый-ялвара. Тәмам алҗып, ул йокыга тала. Егет аны күтәреп авылга алып кайта.

Былтырның ишегалды. Туй мәҗлесе бара. Сөембикә авылда, кешеләр арасында яңа тормыш башлый. Ишег-

Күренекле биюче Майя Плисецкая (1925-2015) Сөембикә ролендә. Рәссам Чыңгыз Әхмәров

алдында, караңгылык төшү белән, Шүрәле күренә. Кунаклар өйгә кайтканда алар белән уйнашып ала. Ул канатларны, бүтәннәр күрмәгәндә, Сөембикәгә китереп ташлый. Аларны кулга алу белән, кыз, дөньясын оны-

тып, кошка әверелә дә очып һавага күтәрелә. Шулчак аны козгын, каргалар чорнап алып урманга алып китә. Моны белеп Былтыр аның артыннан урманга таба юнәлә.

Шүрәленең оясында җанварлар тагын Сөембикә каршында котырышалар. Аланда кулына факел тоткан Былтыр күренә. Зур бәрелеш башлана. Былтыр куркыныч урынга ут төртә, явызлар ялкында янып юкка чыгарга тиешләр. Янгыннан котылыр өчен, Былтыр Сөембикәгә очып китәргә куша. Ләкин сылу кыз, егетне яратканын белдереп, канатларын утка ыргыта. Хәзер аның язмышы мәңгегә кешеләр белән бәйле. Былтыр сөйгәнен күтәреп ут эченнән алып чыга.

Либреттога карата Муса Җәлилнең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтында саклана торган бәяләмәсе кызыклы. Ул балет либреттосына Якобсон керткән үзгәрешләрне бәяләп үтә. Чыннан да, либреттоның яңа редакциясе театраль драматургия таләпләрен нык истә тотып эшләнгән, төп конфликт үсешенә монда зур игътибар бирелә, образлар күренештән-күренешкә эзлекле төстә ачыла бара, вак деталь һәм эпизодлар төп максатка хезмәт итә. Шул ук вакытта, Якобсон либреттосы җитди кимчелекләрдән дә азат түгел. М.Җәлил рецензиясендә алар ачыктан-ачык күрсәтелә. *«Алар (образлар – **А.А.**) шулай ук халык әкиятләре һәм Тукай әсәрләреннән безгә таныш булган теге яки бу образны күз алдына бастырмыйлар. Якобсон либреттосында Шүрәле Сөембикәне гыйшкы белән эзәрлекләүче явыз демон итеп бирелә. Ул татар халык әкиятләрендә һәм халык шагыйре әсәрләрендә сурәтләнгән образлардан диюне хәтерләтә төшә. Нәкъ менә дию матур кызларны нәфселе сөюе белән эзәрлекли, урлап алып китеп, бик эчендә тота, сихерли һәм башка күп хәвеф-хәтәрләр белән яный. Ә әкиятләрдә һәм Тукай әсәрләрендәге Шүрәле исә – бөтенләй башка. Ул караңгы урманнарда яши һәм аның бернинди дә тылсым көче юк. Ул һәрчак үзенә кызык эзләп йөри... Ул көлке ярата һәм кешеләрне кытыклаудан кызык таба. Нәкъ менә шуңа күрә дә Г.Тукай юмористик әсәрләрен «Шүрәле» исеме белән бастырган. Шүрәленең кайчан да булса гыйшык тотуы, мәхәббәте белән кызларны эзәрлекләве, нинди дә булса тылсым куәсе булуы хакында сөйләнүен мин белмим. Шуңардан чыгып, мин Якобсон либреттосындагы бу образның Шүрәле исеме белән аталуын уңышсыз, дип саныйм. Ул булса «Дию», «Урман иясе», «Урман патшасы» булыр. Былтыр исеме дә уңышсыз алынган. Тәрҗемәдә ул «үткән ел» дигәнне аңлата һәм Тукай әкиятендәге мәгълүм ситуация белән бәйләнештә тора. Монда исә ул нәрсә юк һәм, димәк, исем дә үзен акламый.*

Якобсон либреттосы бик кызыклы корылган. Анда татар халык иҗаты өчен һич тә ят булмаган әкият мотивлары бар. Мәсәлән, тылсымлы канатларда очып килүче торна-кызлар. Ләкин шулай да либреттодагы кайбер моментлар шик уята. Халык әкиятләрендә кеше, гадәттә, мифик көчләр һәм табигать көчләре белән көрәштә акылы һәм тапкырлыгы аркасында җиңүгә ирешә. Әкиятләрдәге мифик көчләр һәм табигать көчләре кешедән көчлерәк итеп биреләләр, әмма кеше – җитез, зирәк һәм хәйләкәр. Шуңа күрә ул өстен чыга да. Тукай әкиятендә егет Шүрәлене хәйлә белән җиңә, ә Якобсон либреттосында Былтыр Шүрәле белән көч сынаша һәм аңардан көчлерәк булып чыга. Ул аны бүрәнә янына көчләп сөйрәп алып килә һәм бармакларын ярыкка кыстыра. Әлбәттә, бу бөтенләй икенче нәрсә һәм болай иткәндә халык әкиятенең бөтен хикмәте һәм матурлыгы югала. Шүрәлене яндыру күренешендә дә без хәйлә һәм акыл өстенлеген күрмибез...» – дип яза М. Җәлил.

Моңа өстәп тагын шуны әйтәсе килә:

халык ышануы буенча, Шүрәлене утта яндыру яңа кавышкан Былтыр белән Сөембикәгә бәхетсезлек китерүе мөмкин. Ә инде урманга ут төртү халыкта һәрвакыт җинаять санала. Балеттагы Шүрәле образы һәм Былтырның аңа карата кылган гамәлләре татар әкиятләрендә таралыш алган мотивлар белән ярашмый.

Якобсон тарафыннан кертелгән бер күренеш татар театрының художество советы утырышларында бер генә тапкыр тәнкыйтьләнмәде. Чөнки анда хәмердән авыз итеп кызып алган картлар, кода белән кодагыйның мәзәк биюләре, үз-үзен тотышлары татарлардагы электән килгән туй йоласы гадәтләре һәм тәртибе белән сыешмый. Традиция буенча, туй мәҗлесендә картларның яшьләр белән бергә җәелеп күңел ачуын, бергәләп җыр-биюләрен күз алдына китерүе кыен. Татарлардагы милли гореф-гадәт һәм йолалар белән таныш булган тамашачылар өчен балет спектаклендәге ул күренешләр бик сәер тоела.

Театр драматургиясе таләпләре җәһәтеннән караганда, либретто, әлбәттә, җыйнакланган, сюжет бөтенлеге яхшырган, һәм, шул ук вакытта, ул милли фольклор рухына җавап биреп бетерми, җитди тәнкыйтькә мохтаҗ булып кала. Балетта алынган сюжет әгәр чыннан да «Дию» дип исемләнгән булса, ул үзенең исеменә туры килә төшәр иде. Әмма либреттодагы мондый эчтәлек балетның музыкасына туры килми, чөнки Ф.Яруллин музыкада нәкъ менә Тукай поэмасында сурәтләнгән сәер урман карачкысы Шүрәле образын тудырган!

Шулай булгач, либретто авторы итеп кемне танырга соң? Әхмәт Фәйзинең шәхси архивындагы материаллардан күренгәнчә, әдип 1938 елдан башлап либреттоның берничә вариантын яза. 1941 елның башыннан бу эшкә балетны сәхнәгә куючы балетмейстер Л.Якобсон да кушыла. Якобсон белән очрашулар, фольклор материалларын сайлау, иҗади эзләнү, либреттоны камилләштерү процессында Ә.Фәйзи балетмейстерны Г.Тукайның сабакташы Каюмов белән очраштырып, мәдрәсәдә Тукайдан ишеткән әкиятләрне сөйләттерә. Шушы әкиятләр арасында кыз кыяфәтенә керүче кош һәм аның канатын урлаган егет турындагы әкият тә очрый. Шүрәле поэмасы белән бергә бу сюжет соңрак балетның нигезенә салына. Ә.Фәйзинең үз кулы белән язуынча, Якобсон варианты фикер алышу барышында әйтелгән тәкъдимнәр нигезендә төзелә башлаган. Шулай итеп, 1941 ел башында балетмейстер Якобсон белән Ә.Фәйзигә балет либреттосын тиешле дәрәҗәгә җиткерү бурычы йөкләнә. Ләкин алар арасында якын иҗади хезмәттәшлек урнашып китә алмый. Ә.Фәйзи, авырып, шифаханәгә керә, ә җәен Бөек Ватан сугышы башланып китә. Ул фронттан кайтканда балет инде татар театры сәхнәсендә куелган була.

***

Фронтка киткәнче, Фәрит Яруллин балетның тулы клавирын (ягъни фортепианода ике кул белән башкару өчен нота язмасын) һәм (укытучысы Г.И.Литинский әйткәне буенча) беренче пәрдәнең оркестр партитурасын тәмамларга өлгерә. Икенче һәм өченче пәрдә партитураларын сугыш чорында Мәскәү педагогы Ф.Е.Витачек эшләп чыга. Балетның бу редакциясе 1945 елда Татар дәүләт опера һәм балет театрында Л.Жуков һәм Г.Таһиров тарафыннан куела. Ә 1950 елда «Шүрәле» балетын Киров исемендәге Ленинград опера һәм балет театрында кую мәсьәләсе килеп баскач, композиторлар В.Власов һәм В.Фере яңа редакциясен (партитура һәм клавирын) әзерлиләр. Шушы редакциядә әсәр киң масштабта танылып китә һәм бөтен дөньяга дан казана.

1971 елда Мәскәүнең «Музыка» нәшриятында басылган клавирга сүз башында Власов һәм Фере болай дип язалар: *«Балет музыкасында, авторның үлеменнән соң саклан-*

ган хәлендә, билгеле бер дәрәҗәдә төгәлләнеп җитмәгән элементлар, фрагментлылык бар, кайбер урыннарда профессиональ яктан тиешенчә өлгереп җитмәгәнлек билгеләре сизелә. Автор партитурасы бөтенләй юк иде». Әсәрнең яңа редакциясенә үзләре керткән иҗат өлешен күрсәтеп, алар болай дип өстиләр: *«Балетны сәхнәгә кую өчен клавирны бик җентекле рәвештә редакцияләп чыгарга, автор материаллары нигезендә күп кенә номерларны язып бетерергә һәм әсәрне тулысы белән инструментларга салырга кирәк иде. Үз вакытында бу эш безгә йөкләтелде».*

В.Власов белән В.Ференың бу раслаулары каршылыклы фикерләр уята. Иң элек беренче пәрдәнең музыкасы өчен автор үзе төзегән партитура хакында алар ничек белмәде икән, дигән сорау туа. Җитмәсә, Витачек эшләгән партитура хакында да кереш сүздә берни әйтелми.

Власов һәм Ференың әсәрне төгәлләнеп җитмәгән, фрагментлы характерда дип бәяләүләре белән дә килешеп бетәсе килми. Чөнки әсәр сәхнәгә кую өчен кабул ителгән, сугыш беткәнче үк куелган һәм шактый зур уңыш казанган. Әсәр клавирының Витачек партитурасына туры килә торган оригиналы сакланып калган.

Ф.Яруллин клавиры белән танышкан һәр кешене аның музыкасының гади һәм шул ук вакытта күңелгә тирән үтеп керә торган самими моңы дулкынландырмый калмый. Ул тышкы эффектлылыкка дәгъва итми, көчле аһәңлеге белән дә аерылып тормый, ул – хисләрнең эчке байлыгы, нечкә шигъри уй-тойгылар уятуы белән гүзәл. Саф һәм садә музыкаль аһәңнәрдә иҗади фикер тибеп тора, чын илһам нурлары сирпелә. Балет образлары чын милли сыйфатларында гәүдәләнәләр, халык иҗатының сихри дөньясы синең алдыңда тирән ачыла бара. Һәр персонаж фольклор традициясе стихиясендә үзенә хас яңгыраштa тасвирланган. Шүрәле образында сәер уенчаклык, кыргый шуклык сыйфатларына басым ясала. Былтыр исә намуслылык, тугрылык, тыйнаклык символы булып күз алдына баса. Сөембикә күңел нечкәлеге, оялчанлык, назлылык сыйфатларын үзенә җыйган. Образларның һәр төркеме үзенә генә хас музыкаль сурәтләү чаралары аша сынландырыла.

Балетны Ленинград опера һәм балет театры сәхнәсендә куярга хәзерләгәндә яңа партитура эшләү мәсьәләсе алга килеп баса. Чөнки Витачек партитурасы театрның зур составлы симфоник оркестры колачына җавап бирми, ә әсәрнең масштабын киңәйтү, фактураны баету таләп ителә. Балетның яңа редакциясе әнә шул максатны күздә тотып эшләнә дә. Әмма эш шунда ки, бу яңа редакция оркестр алымнарын һәм чараларын киңәйтү, әсәрнең гомуми яңгырашын үстерү белән генә чикләнми, ул интонация материалларына, әсәрнең формасына да кагыла. Ни өчен бу болай? Шундый җитди үзгәрешләр кертү ник кирәк булган? Күрәсең, редакторлар Фәрит Яруллин музыкасындагы образлар сурәтләнешенең либретто белән тәңгәл килмәвенә игътибар иткәннәр. Бигрәк тә Шүрәле һәм Былтыр образларының Л.Якобсон интерпретациясендә гәүдәләнеше аларны аптыраштa калдырган булса кирәк, һәм алар бу тәңгәлсезлекне төзәтергә булалар. Нәтиҗәдә балет музыкасына күп кенә үзгәрешләр кертелә һәм ул үзгәрешләрнең байтагы әсәрдә яңа каршылыклар китереп чыгара.

Әсәрдәге һәр образга диярлек В.Власов һәм В.Фере яңа төсмерләр өсти. Шүрәле образында, мәсәлән, аның явызлыгына, буйсындыру көченә, куркыныч кодрәтенә басым ясала. Шүрәле партиясендә өстенлек иткән кискен хәтәр интонацияләр бу «урман сарыгы»ның нәкъ шундый сыйфатларын күпертеп күрсәтә. Ул гына җитмәсә, Шүрәлебез әле алдан корган мәкер белән эш итә торган астыртын һәм хәйләкәр җан да икән. Аның партиясенә әледән-әле килеп керә торган үткен һәм зәһәр тоннар шул хакта

сөйли. Шул рәвешчә образның гротескы, шаянлыгы югала. Бу исә аны халык хыялында туган Шүрәледән ераклаштыра. Яңа редакциядә Былтыр образы да бүтән кыяфәт алган. Монда инде ул урманга утынга килгән чая бер егет кенә түгел, ә коеп куйган баһадир. Шуңа ярашлы рәвештә балетның исемен дә «Али Батыр» дип үзгәртәләр һәм ул урман айкап йөрүче сунарчы итеп сурәтләнә. Яңа куелышта Сөембикә образы да үзгәрешсез калмаган. Спектакль башында ук ул, үз язмышын алдан сизенгән күк, түземсезлек белән нидер көтә, мәхәббәт турында хыяллана. Композитор Ф.Яруллинның иҗат стиленә хас эчке бер самими тыйнаклык, басынкылык, лаконизм редакторларны канәгатьләндереп җиткерми. Әсәрдәге аерым номерларга да, аның бөтен яңгырашына да алар киңрәк масштаб бирергә тырышалар. Власов һәм Фере әсәрдәге көч алышу, көрәш күренешләрен аеруча көчәйтәләр, аны калкурак, дәвамлырак итәргә омтылалар. Әмма алар кулланган алымнар һәм чаралар, чын киеренкелек тудырудан бигрәк, музыкаль диапазонны берьюлы колачлап алып, соңыннан бер урында өзлексез «таптанып» торуга этәрә. Шулай итеп, музыкаль үстерелеш осталыгы, форма динамикасын нечкәләп тою ягыннан балет авторының биредә өстенрәк торганлыгын танырга туры килә. Редакторлар исә нәкъ шушы җәһәттә уңышсызлыкка очраган.

Балетның яңа редакциясендә әсәрнең төп темаларына нигезләнгән зур яңгырашлы кереш, беренче һәм икенче пәрдәләрдәге кайбер номерларны кабатлаган саллы финал өстәлгән. Ләкин алар, әсәргә салынган фикер һәм хисләрне баетудан бигрәк, күләмне киңәйтүгә генә хезмәт итә.

Күргәнебезчә, әсәрнең яңа редакциясендә, аны баетырга, колачын киңәйтергә омтылганда, редакторлар күп кенә төгәлсезлекләр җибәргәннәр.

Яңа куелышның уңай яклары нидән гыйбарәт соң? Күңелне җәлеп иткәне шул: инструменталь яктан әсәр яңа бизәкләргә баеган, алар тагын да куера төшкән. Яңа партитура зур составлы оркестрда башкарыла, анда күп санлы бизәгеч инструментлар (фортепиано, ике арфа, ксилофон, челеста, кыңгырауларчыклар, саксофон, өчпочмак) һәм там-там эшкә җигелә. Оркестр чын-чынлап бай һәм отышлы симфоник яңгыраш ала.

«Шүрәле» балетының ике редакциясен янәшә куеп тикшерү түбәндәге нәтиҗәләргә китерә: Ф.Яруллинның клавирын тиешенчә бәяләп җиткермәүләре белән редакторлар хаклы булмаган, ул – тирән оригинальлеккә ия булган үзенчәлекле әсәр, сәнгатьлелек ягыннан аның мөстәкыйль әһәмияте зур. Индивидуаль иҗат йөзе һәм новаторлык принциплары булган талантлы композиторның гүзәл иҗат җимеше ул. Әсәрне яңадан кулга алудан бердәнбер максат – зур составлы оркестр өчен партитура әзерләү генә була ала иде.

Кызганыч ки, авторның төп иҗат юнәлеше һәм стиленә хас күп үзенчәлекләр редакторлар игътибарыннан читтә калган. Моңа мәгълүм дәрәҗәдә Л.Якобсон либреттосы да комачаулык иткән. Шул ук вакытта редакторларның татар музыкасын йомшаграк белүләре дә киртә булган. Шул сәбәпле, образларның үзенчәлекле музыкаль сурәтләнешен алар тәҗрибә җитенкерәмәү галәмәте, дип уйлаганнар, басынкы яңгырашны стиль камиллеге җитмәү, лаконизмны – төгәлләнмәгәнлек билгесе, дип кабул иткәннәр.

Укучыларда бик табигый рәвештә шундый сорау туарга мөмкин: балет ни өчен нәкъ менә В.Власов һәм Ф.Фере редакциясендә дөньяга танылган? Болай дип җавап бирә алабыз: ничек кенә үзгәртелмәсен, ул барыбер нигездә Фәрит Яруллин музыкасы булып кала һәм аның музыкаль җәүһәрләре матур бизәкле кысага салынган. ■

ТҮБӘТӘЙ – ТАТАР ИРЛӘР БАШ КИЕМЕ

Ясалу урыны һәм вакыты: Россия, Казан губернасы, Казан. XX гасыр башы

Материалы: кара төстәге бәрхет, кулдан сырылган

Үлчәме: диаметры – 15,5 см, биеклеге – 6 см

Музейга кабул ителүе: СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тапшырган. 1987 ел

Г.Тукай замандашлары истәлекләре буенча, 1908 елгы фотографиядә ул шул түбәтәйдә төшкән. Баш киеме шагыйрьгә аның бөтен китапларын диярлек үзенең «Үрнәк» матбагасында бастыручы нашир Гыйльметдин Шәрәф тарафыннан бүләк ителгән. 1908 елда нәшер итү өчен яңа шигырьләр җыентыгы әзерләнә. Нашир китапны шагыйрьнең фотографиясе белән бастырырга тели. Ул Тукай белән С.И.Иванов фотоостаханәсенә бара. Г.Шәрәф, шагыйрьнең озын чәчләреннән кыенсынуын күреп, кесәсеннән пөхтә итеп төрелгән түбәтәй алып, аның башына кидерә.

Г.ТУКАЙ ӘДӘБИ МУЗЕЕНДА ШАГЫЙРЬНЕҢ ШӘХСИ ӘЙБЕРЛӘРЕ

ТАРТМАЧЫК

Ясалу урыны һәм вакыты: Россия. XX гасыр башы

Материалы: кәрәч

Үлчәме: диаметры – 14 см, биеклеге – 8 см

Музейга кабул ителүе: Казан шәһәрендә яшәүче, Г.Тукайның әтисе ягыннан апасы Газизә Зәбиреваның улы Хөсәен Зәбирев тапшырган. 1987 ел

Истәлекләр буенча, Г.Тукай бу тартмачыкны Җаек шәһәрендә үзенең беренче гонорарына сатып алган һәм әтисе ягыннан бертуган апасы Газизәгә бүләк иткән.

ҖИҢ КАПТЫРМАЛАРЫ

Җиң каптырмаларында останың инициаллары күрсәтелгән: «D.G.M.», «OCTER. PAT».
Ясалу урыны һәм вакыты: Германия, XX гасыр башы
Материалы: көмеш
Үлчәме: 2х1,3 см
Музейга кабул ителүе: Казан шәһәрендә яшәүче А.А.Низаметдинев тапшырган. 1987

Җиң каптырмаларын рәссам Альфред Низаметдиневка «Аң» журналының җаваплы сәркатибе Зәйнәп Хәсәни (мөхәррире — ире Әхмәтгәрәй Хәсәни була) 1950 нче елларда тапшыра. 1911-1912 елларда Ә.Хәсәни Австрия һәм Германиядә була. Җиң каптырмаларын шунда сатып алуы ихтимал, ә соңрак дусты һәм хезмәттәше Г.Тукайга бүләк итә.

КАРАНДАШ САВЫТЫ

Петербургка нигез салынуның 200 еллыгына багышлап эшләнелгән. Петербург гербының, Петр I һәм аның ике йортының кабарынкы рәсемнәре белән бизәлгән. «Санкт-Петербург шәһәренең 200 еллык юбилеена истәлек. 16 май, 1908 ел» дигән язу бар.
Ясалу урыны һәм вакыты: Россия, Санкт-Петербург. XX гасыр башы
Материалы: аккургаш
Үлчәме: нигезенең диаметры — 5 см, өске ягының диаметры — 6,3 см, биеклеге — 10 см
Кабул ителүе: СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тапшырган. 1987 ел

Карандаш савытын институтка Казан шәһәрендә яшәүче композитор М.Мозаффаров тапшыра. Аның сүзләре буенча, аны Г.Тукай 1912 елда Санкт-Петербургка сәяхәте вакытында сатып ала.

КАРА САВЫТЫ

Үзенчәлекле формада: аскуймада ау эте утыра, янәшәдә аучының зур эшләпә белән капланган киеме һәм мылтыгы. Савытның кара сала торган өлеше дә шушы эшләпә астында

Ясалу урыны һәм вакыты: Россия, XIX гасыр ахыры-XX гасыр башы

Материалы: бакыр

Үлчәме: 21x15x9 см

Музейга кабул ителүе: СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тапшырган. 1949 ел

Кара савытын шагыйрьгә Санкт-Петербургның татар мәктәбе укучылары 1912 елгы сәяхәте вакытында бүләк итә. Бу бүләк Тукайга бик кадерле була. 1945 елга кадәр кара савыты М.Мозаффаровның әнисе гаиләсендә, Г.Тукай белән якыннан таныш булган Маһруй Мозаффариядә саклана. Аның кияве Әхмәт Урманчиев «Ялт-йолт» сатирик журналының мөхәррире, ә шагыйрь анда җаваплы сәркатип булып эшли. Г.Тукай үлгәннән соң кара савыты Ә.Урманчиевта саклана. Әнисенең васыятен үтәп, М.Мозаффаров аны Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшыра.

ЮЛ КӘРЗИНЕ

Ясалу урыны һәм вакыты: Россия. XX гасыр башы

Материалы: камыш

Үлчәме: 21x53x34 см

Музейга кабул ителүе: СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тапшырган. 1949 ел

Кәрзинне институтка композитор М.Мозаффаров тапшыра. Аның сүзләренчә, юл кәрзине шагыйрьнең сәяхәтләре вакытында юлдашы була.

«Ядкярләрдә — Тукай рухы» китабыннан.

МИЛЛӘТ ЯШӘСӘ, ТУКАЙ ОНЫТЫЛМАС!

Шамил Әхмәтҗанов

Әгәр дә мәгәр миннән бүген:
– Тукай синең өчен кем ул? – дип сорасалар, һичшиксез, болай дип җавап биргән булыр идем: «Ул минем өчен тел белән генә аңлатып бирә алмый торган бер илаһи зат», – дияр идем.
Ул минем бөтен каныма сеңгән, бөтен тәнем белән тоям мин бөек якташымны. Аның сүзләре белән телем ачылган, җаным сугарылган. Аның «Туган тел» җырын (шигырен) тыңлаганда, бөтен гәүдәм тетрәп китә. Әллә нинди хискә бирелеп, сиздермичә генә күзләремә яшь тула. Бу җыр, бу шигырь татар халкының язмышына әверелде, ул көннән-көн актуаль була бара.

Мин Җыр һәм бию ансамбленә эшкә килгәндә (1967), концерт шушы җыр белән башланып китә иде. Нинди горурлык белән башкара идек без бу җырны, шушы җыр белән бөтен СССРны кат-кат әйләнә идек. Нинди ихтирам иде «Туган тел»гә ул заманнарда. Тукай шушы шигыре белән генә дә иң бөек шәхес булып кала бирә. Инде мин дә малай-шалай түгел, 75 яшьне тутырып киләм, Аллага шөкер, әмма минем әле икенче Тукайны күргәнем юк. Һәм инде булмас та, чөнки күпме генә акланырга тырышсак та, ана теле көннән-көн артка күчә, чын татар халкы югала, кими. Бигрәк тә катнаш гаиләләр саны арта, ә бу – безнең өчен иң зур фаҗига. Татар мәктәпләре ябыла, ә аларны ябу өчен Россия хөкүмәте нинди генә хәйләләр тапмый. Кызганыч…

Хәзер радио-телевидениедәге дикторлар тырыша-тырыша телне боза. «Һәм» урынына — «хам», «һава» урынына «хава», диләр. Бу безнең ана теленә барысы да бактерия булып керә, тыңлыйсы килми башлый. Ә Тукайны, әгәр мөмкин булып, терелтә алсак, ул ни дияр иде икән? Мин үскән вакытта нинди еллар иде. Безнең ана теле, татар мәктәпләре гөрләп тора иде. Хәзер бигрәк тә читтә яшәгән татарларга бик кыен: тел бетә, ә алар үзләренең татар икәнлекләрен хәтердә генә йөртә. Әйтик, менә Балтыйк буендагы татарларда, Польша һәм башкаларында тел онытылган, әмма үзләрен «без татарлар», диләр һәм татар булулары белән горурланалар. Алла сакласын, бездә дә кайчандыр шулай була күрмәсен. Мондый адым белән барсак, булырга да мөмкин. Аллаһы Тәгалә нәрсә ди әле? Тырышканга булышырмын, диме? Димәк, безгә дә туган телебезне юк итәргә түгел, ә югалтмаска тырышырга кирәк. Халкыбызның саны кимегән саен, телебезнең дә кирәклеге бетә бара. Ә бит халкыбызның саны елдан-ел үзебезнең ярдәм белән кими. Мәскәүне сөендерәбез. Әгәр дә Россиядә бер рус теле генә калса, хөкүмәтнең проблемасы кимер иде.

Мин шулай бер гастрольдә, 1992 нче еллар булса кирәк, Төркиянең Адана шәһәрендә бер татар абзыйсы белән әңгәмә корган идем. Ул тамыры белән Арча ягыннан булып чыкты, үзе язучы икән. Әңгәмәбез соңында ул миңа шундый сорау биргән иде. Янәсе, Россиядә күпме татар яши? Мин аңа 7 миллион тирәсе, дигән идем, ул бик озак башын тотып утырды да, борчылып, болай диде:

— Рәсәйдә революциядән соң 21 миллион татар бар иде, кая киткән ул татар?

Әйе, Зөлфәт Хәким әйтмешли, безгә үз дәүләтебез булмавы комачаулый, чын татарлар көннән-көн кими бара, Тукай кебекләр җитми. Тукайның бүләген алучылар күбәеп тора, ә аңа хезмәт итүчеләр аз. Менә Язучылар клубында да, Тукайга багышланган кичәләрдә дә бер-ике лауреат катнаша. Ә бит бүләкне алганчы нинди генә тишеккә кермиләр. Алгач та тынычланалар. Шаккатам. Бөтен лауреатларны бергә җыйсаң, үзе бер зал булыр иде.

Бервакыт миңа да шундый мөмкинлек туды: Минтимер Шәрип улы, Президент буларак, мине үзенә кабул итте һәм бик озак сөйләшеп утырганнан соң:

— Шамил, менә син «Арча» көен һәм Рөстәм Яхинның Шәриф Хөсәенов сүзләренә язылган «Сорнай моңы» җырын башкарасың. Ә бит бик күркәм җырчылар да бу җырларны синең дәрәҗәңдә башкара алмый, син Тукай бүләгенә лаектыр, дип уйлыйм, кандидатураңны куймыйсыңмы? — дигән иде.

Мин, кызулыгым беләнме, бу киңәшне кабул итмәдем. Үземне лаек түгелмендер, дип уйладым булса кирәк.

Берничә көннән соң үземнең иҗатыма анализ ясадым. Тукайга багышланган һәм аның сүзләренә язылган җырларымны кабат-кабат тыңладым. Аңа — Тукайга багышланган хезмәтем, чыннан да, аз булмаган икән, дигән нәтиҗәгә килдем. Әйтик, Сибгат ага Хәким сүзләренә Мансур Мозаффаровның «Кайда да йөрәктә», шулай ук Сибгат ага сүзләренә Сара апа Садыйкованың «Бик сагынган чаклар була сине, Тукай», Г.Тукай сүзләренә Мансур Мозаффаровның «Туган җиремә», Тукай сүзләренә «Өзелгән өмид», Көзге җилләр», Тукай туып үскән җирнең гимны булган «Арча» көе дә минем йөрәк аша узган җыр. Бу җырларны ни өчен санап китте, дип уйлыйсызмы? Моның сәбәбе бар. Менә хәзер озакламый Тукайның туган көне якынлаша, кемнәрдер аның бүләгенә үзләренең кандидатураларын куячаклар һәм «шобага» тотачаклар. Иң лаеклы кешеләргә мин ихлас күңелдән уңышлар телим. Тукай телен, Ана телен дәвам итүчеләр булсыннар иде. Милләтебез яшәсә, Тукай бервакытта да онытылмас. Чөнки ул безнең алтын хәзинәбез. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТАШАЯК ЯРМИНКӘСЕ *тар.* — Казан ханлыгы дәверендә XV-XVI гасырларда Казан шәһәрендә хәзерге кремль астында Болак буенда (электә — *Ташаяк бистәсе*, аннары — *Ташаяк урамы*) эшләп килгән мәшһүр ярминкә. Ярминкә мәйданының уртасында зур таш касә-базар җыемы салына торган ташаяк булганга шулай аталган. Ихтимал, биредә фарфор савыт-саба (*чынаяк* — кытай савыты) белән дә сәүдә иткәннәрдер. Гомумән, ташаяк — борынгы болгар базарларына куела торган ритуаль касә. Бу сүзнең «туз тырыс» мәгънәсе дә булган («Шан кызы дастаны»нда телгә алына). Казандагы Ташаяк ярминкәсенә Русиядән, Урта Азиядән, Кавказдан, Кырымнан, Ираннан, Төркиядән һәм башка илләрдән сәүдәгәрләр җыела торган булган. Көнчыгыштан килгән сәүдәгәрләрне *тезиклар/тәзикләр* (таҗиклар? фарсылар?) дип атаганнар. Казанга китерелә торган төп товарлар металл эшләнмәләр: тимер кораллар, бронза һәм көмеш бизәнгечләр, шулай ук төсле тукымалар, пыяла муенсалар, ислемайлар, борыч-дарчин кебек аш тәмләткечләр, җимешләр, лимон-әфлисуннар, талисман-бөтиләр һ.б. булган.

Рус елъязмаларына караганда, 1505 елда Казанда бик зур суеш (погром) булып, бу вакытта рус шәһәрләреннән килгән 15 меңнән артык сәүдәгәр һәлак була. Әкренләп Казан өстеннән протекторатын җәелдерә барган Мәскәү хакимияте 1523 елда Баш ярминкәне Идел буендагы Макарьевога (Мәкәрҗәгә) күчерүгә ирешкәннән соң да монда ел саен язгы ярминкәләр уздырылган.

Казан сәүдәсен махсус тикшергән галимә Л.М.Свердлова «Ташаяк ярминкәсе» XIX гасыр башыннан кабат эшли башлаган, дип яза. Ихтимал, бу вакытта борынгы ярминкә торгызылып, «Язгы биржа» дип аталып киткәндер. Ул 1 майдан 1 июньгә кадәр үткәрелгән. Яз көне Болак гадәттә су белән тулып, июнь ахырларына кадәр авыр көймәләр керешле булган, читтән килгән сәүдәгәрләр товарны Бакалдайдан турыдан-туры ярминкәгә китерә алганнар.

Г.Тукай үзенең «Исемдә калганнар» дигән хатирәләрендә «кайчакта әнисе белән «Ташаяк базары»на барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда, шатланып-шатланып, агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп» торуы хакында яза (XIX гасыр ахыры). Ташаяк ярминкәсенең тасвирын Ф.Әмирханның «Рәхәт көн» хикәясендә табарга була. Мәс., бу хикәядән күренгәнчә, ул заманнарда

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынан басылып килә.

Ярминкә мәйданы. XX гасыр башы

татар кешесе «мороженое»ны «маруз» дип йөрткән, ә арзанлы туңдырма 3 тиен торган икән. Ярминкә яшәвенең соңгы елларына Исмәгыйль Рәмиев мондый катгый характеристика бирә: «Бала-чага, яшь-җилкенчәк, хатын-кыз зәвыкына карап төзелгән ярминкә иде ул. Анда балалар уенчыгы, бүләк-санак әйберләре (сувенирлар), затлы һәм затсыз бизәнү-төзәнү әйберләре саталар. Татлы ашамлык — баллы прәннекләр сатучы чибәр-чибәр украин кызлары килә иде. Тегендә кәмитчеләр шау-шуы, монда гармун көенә карусель әйләнә, таган атыналар. Биш тиенгә бәхет билеты сатучы хәерчеләр кычкыра. Акчалылар күңел ача, акчасызлар карап тора, тамаша кыла». Чыганаклардан күренгәнчә, монда китап сәүдәсе дә булган.

Тагын кара: *Ярминкә мәйданы.*

ТАШКА ҮЛЧИМ — Борынгы ырым сүзе. Тулы варианты — *«ташка тамга үлчим»*. Н.Исәнбәт төзегән «Татар теленең фразеологик сүзлеге»ндә бу гыйбарәгә бирелгән озын аңлатманың бер өлешен китерәбез. «1.Кеше тәнендәге шеш, яра, ор-җәрәхәт кебекләрне тән белән тиңләп сөйләсәң, тиң тиңне тартып, чире миңа да күчә күрмәсен, дигән кара ышану белән шешне йә җәрәхәтне ташка тиңләп әйтем. Ул чагында тиң тиңне тарту кагыйдәсе буенча чир ташка тиңләнеп, ташка күчә дип инанылa һәм шуның белән чирдән котылам дип беленгән. Ягъни ташка чыксын ул авыру, ул шеш». Ләкин, югарыда күрсәтелгәнчә, әйтемнең тулы вариантында «ташка тамга үлчим» дигәннәр. Монда «ташка үлчим» сүзләрен «ташка тамга салу» дип аңласак, ырым аңлашыла төшә, ул инде соңырак заманнарда имтомчыларның тәлинкәгә дога язып суын авыру кешегә эчерүен хәтерләтә башлый. Монда борынгыларның ташка табынуын искә төшерү дә урынлы сыман.

Соңрак, әйтемдәге «тамга» сүзе онытылгач (югалгач), бу сүз һәртөрле тискәре хәлләргә, хәтта шәхесләргә түбән бәя бирү төсмерен алган һәм шуңа күрә Нәкый Исәнбәтнең бүгенге (яңа) аңлатмасын ялгыш дип саный алмыйбыз. Шунысын да таныйк, без әйткән фараз үзе дә өстәмә дәлилләүгә мохтаҗ әле.

«ТАШКИРМӘН КЕРӘШЕНЕ» — Казан арты мөселманнары аеруча үзсүзле, хәтта үҗәт керәшеннәрне шулай дип атап йөрткәннәр. *Ташкирмән* — Татарстан республикасының Лаеш районындагы борынгы авыл, халкы православие кабул иткән. М.Глухов бу авыл халкының көнкүреше һәм сөйләше дә *үзенчәлекле* булуын билгеләп китә. Авыл тирәсендә *«Калабаш»* шәһәрлеге бар. ■

ТУКАЙ ҺӘМ ТУГАН ТЕЛЕБЕЗ

Вахит Хаков
(1926-2008)

Габдулла Тукай үзенең табигый сәләте, сихри моңы һәм әсәрләрендәге җанлы сөйләмнең эчке яңгырашы белән кеше күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтүче һәм хәрәкәткә китерүче бөек шәхесләрнең берсе иде.

Ул татар халкы тарихының иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга бай, катлаулы бер чорында мәйданга чыкты. Аның әдәби тел тарихында тоткан урыны да XX йөз башындагы шул вакыйгалар белән тыгыз бәйләнештә карала. Тукай әдәби телне халык сөйләменә якынайтуда, матур әдәбият һәм публицистика стильләрен үстерүдә гаять зур эш башкарды, телнең киң мөмкинлекләреннән файдаланып, тирән эчтәлекле һәм халыкчан әсәрләр иҗат итте. Ул әдәби телне элекке тар стиль кысаларыннан чыгарды, заман таләпләренә туры китереп, аңа киң үсеш юлы ачты. Татар әдәби теле тарихында гасырлар буе килгән уңай традицияләр Тукай иҗатында бер ноктага җыйнала һәм киң күләмдә гомумиләштерелә. Аның осталыгы да шунда: Тукай халыкны телнең гадилеге һәм матурлыгы белән тәэсирләндереп кенә калмады, аны рухи азык итте, сүзнең көчен дәлилләп һәм раслап күрсәтте. Татар теленең эчке хасиятен һәм иң нечкә төсмерләрен бик ачык тойган Җамал Вәлиди Тукай әсәрләренең теле турында болай язды: «Тукайның иң сөйдергән ягы, – ди ул, – шөбһәсез, аның тел вә өслүбедер. Тукай кадәр җиңел вә тәкәллефсез, шуның белән бергә аһәңле вә сәлис язучы шагыйрь әле һәнүз татарда килгәне юк. Давыт кулында тимер ничек балавыз кебек булып эресә, Тукай авызында татар теле шулай эри».

Тукай татар әдәби телендә генә түгел, бөтен төрки әдәби телләр үсешендә тирән эз калдырды. Шагыйрь үзенең иҗаты белән XX йөз башында яңа юнәлештә үсеп һәм формалашып килгән азәрбайҗан, казакъ, үзбәк, төрекмән, башкорт, каракалпак, кыргыз, кумык әдәби телләренә дә зур йогынты ясады. Урта Азия, Казакъстан, Урал буе, Кавказ язучылары Тукай иҗаты үрнәгендә үз әдәбиятларын һәм әдәби телләрен тагын да үстерделәр һәм баеттылар.

Әдәби телдәге халыкчанлык юнәлешенә Тукай үзенең мөнәсәбәтен яшьли билгеләде. Моңа халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү аеруча ярдәм итә. Шагыйрь фольклор әсәрләрен җыя, аларны туктаусыз өйрәнә һәм андагы үзенчәлекләрне әсәрләрендә бик оста файдалана. Халык иҗаты әсәрләре шагыйрь күңелендә гаять зур көч булып гәүдәләнә. «Халык җырлары чын үземезнеке генә булганга, анда читләрдән, гарәп, төрек, сарт кебиләрнең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм мәхәббәт итәм», – ди Тукай. Иҗатының беренче көннәреннән үк Г.Тукай шул юнәлешне

сайлап ала һәм әдәби тел үсешендә моны бердәнбер дөрес юл итеп күрә.

Шагыйрь тарафыннан кулланылган халык сөйләменең бик тәэсирле булуы турында Гали Рәхим болай яза: «Тукаевның теле – саф халык теле. Ул чит сүзләр катышмаганга күрә генә түгел, үзенең бөтен төзелеше, бөтен тарзы ифадәсе (стиле) белән халык теле. Аның һәммә сүзләре «чат!» итеп бәрәләр. Ул күңелдә эз калдырырлык сүзләрне бер дә мәшәкатьсез таба ала, чөнки ул аларны төпсез кое шикелле булган халык теленнән чүпли».

Ул иҗат итә башлаган чорда татар әдәби теле үсешендә зур үзгәрешләр һәм яңа күренешләр барлыкка килә. Халык теле киң күләмдә бердәм әдәби нормалар югарылыгына күтәрелә.

Г.Тукай татар публицистикасын һәм аның телен үстерүгә зур өлеш кертә, аны жанр ягыннан баетуда һәм вакытлы матбугат аша әдәби телне киң халык массасына җиткерүдә әһәмиятле эш башкара. Ул аеруча иҗтимагый публицистиканың очерк, памфлет, фельетон, сатирик мәкалә кебек жанрларын куллана. Шагыйрь аларны сатирик, фаш иткеч үткен тел белән сәнгатьчә югарылыкта иҗат итә. Шунлыктан Тукайның публицистик әсәрләре тел-сурәтләү чараларының байлыгы, сөйләмнең эмоциональ яңгырашы белән матур әдәбият теленнән аерылмый. Анда киң җәмәгатьчелекне дулкынландыра торган, заман таләпләренә туры килгән төп иҗтимагый-сәяси һәм тормышкөнкүреш мәсьәләләре күтәрелә. Шагыйрь халыкны җәмгыятьтәге кимчелекләргә һәм искелеккә каршы көрәшкә чакыра, яңалыкны тоткарлап, белемгә – мәгърифәткә бару юлында киртә булып торучы һәрнәрсәне юк итәргә өнди. «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» исемле сатирик әсәрендә Тукай азатлыкка һәм киләчәк якты идеалларга ирешү максатын тормышка ашыруны бөтен кискенлеге белән куя: «Тагы да ул кортлар вә ул козгыннарның милләтне ни рәвешле ашаганнарын рәссамнар хезмәте илә милләтнең үзенә күрсәтик, милләтне аларга каршы ачуландырыйк, чәчләрен аягүрә торгызыйк; борынгы кыйлган эшләре өчен милләт аларны аяк астына салып изсен, һич дөньяга килмәгән кеби итсен; каргаларны муеныннан кысып, борынгы ашаганнарын кырылдатып чыгарсын». Кош, хайван, бөҗәк исемнәрен күчерелмә мәгънәдә кулланып, Тукай көчле сатирик эффектка ирешә, үткен сүзләр, сатирик-метафорик бәяләмәләрне киң куллана, аларны сүз уйнату алымы белән бергә куша. Әйтергә кирәк, бу бик уңышлы чыга.

Тукай поэзиясе һәм публицистикасы тел-стиль чараларына гаять бай. Шагыйрь сүз уйнату, сатирик характеристикалар, образлы комик сыйфатлау һәм чагыштырулар, ирония, пародия, риторик өндәү һәм сорау, кабатлау алымнары, бер-берсенә капма-каршы куелган сөйләм берәмлекләрен, сәнгатьчә сурәтләү чараларының күп төрләрен кулланып, үзенең дошманнарын һәм җәмгыятьтәге кимчелекләрне рәхимсез фаш итә. Тукай поэзиясе үзе дә иҗтимагый-публицистик пафос белән сугарылган. Бу тел-стиль чараларында да ачык күренә. «Государственная Думага», «Иттифак хакында», «Сорыкортларга», «Китмибез», «Көзге җилләр» кебек шигырьләр шуны ачык раслыйлар.

Тукай татар сөйләменең эчке мөмкинлекләрен киң рәвештә эшкә җигеп, тел-сурәтләү чараларын гаять оста куллана белүче, әдәби телләрнең стильләрен – бигрәк тә матур әдәбият һәм иҗтимагый публицистика телен яңа юнәлештә үстереп җибәрүче һәм аларны тагы да баетучы, әдәби телнең үсешенә йогынты ясаучы, аңа сизелерлек өлеш керткән шагыйрь һәм әдип булып тарихка кереп калды.

Татарстан радиосының «Тел күрке — сүз» тапшыруына нигезләп, басмага ***Рөстәм Акъегет*** *әзерләде.* ■

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның апрель ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мөселман кызлары өчен гимназия

Казанның иң тәрбияле кызлар мәктәбе булган Фатиха ханым Аитова мәктәбен урта дәрәҗә мәктәп ясарга Казан округы попечителе тарафыннан рөхсәт бирелде. Мәктәптә рус теле, рус тарих(ы) вә Русия җәгъръафиясеннән [география] башка фәннәр һәммәсе татар телендә укылачактыр. Киләсе көздән мөселман гимназиясенең әүвәлге классларын ачып җибәрергә тырышылачактыр. Фатиха ханымны муаффәкыяте [уңышы] белән тәбрик итеп, тәшәббесләрендә[1] җиңеллек вә хәер телибез.

«Казанский телеграф» татарлар өстенә

«Казанский телеграф»та С.Д. имзасы белән мәкалә язган бер кеше фрукты белән сәүдә итә торган татарларның лимонны 40 тиенгә, әфлисунны 60 тиенгә сатканлыкларын бәян итә дә: «Мөхәммәднең балалары бу хирысларын бераз үзгәртергә тиеш иде», — ди. Без комсызлык белән бәһа арттыра торган сәүдәгәрләрнең нинди милләттән булса да, закон буенча җәза күрергә тиешлеген дә шөбһә итмибез. Ләкин мәзкүр гәзитәнең мәкаләсеннән погром исе килә, гүя ки бәһа арттыру бер татарлыктан килгән эш шикелле итеп күрсәтелә. Фрукты белән сәүдә итүче рус фирмалары да нәкъ шул ук бәһа белән сәүдә итәләр. Шулай булгач, мәкалә иясенең татарларны гына махсус атавында бер кабахәт ният күрмәскә мөмкин түгелдер. Милләтләрнең бер булырга тиешле көннәрендә мондый нәрсәләр язучыга вә шуны ирештерүче гәзитәгә оят!

Кояш. — 1916. — №947. — 8 апр.

Мәдрәсә файдасына вәкыф

5 нче апрельдә Казанның 2 нче таш мәсҗед мәхәлләсенең гомуми җыелышында, шул мәхәлләнең могтәбәр байларыннан Габдулла Йосыф углы Апанаев мәдрәсә, имам һәм мөәзин файдасына вәкыф итеп, Спас өязендәге җирләреннән җиде мең сум торырлык бер участка, кырык дисәтинә печәнлек җир биргән. Ошбу җирдән һәр ел өчен йөз сум доход килә икән. Мәхәллә әһалисе, мәгалмәмнүният [шатлык белән] кабул итеп, тиешле мәхкәмәләр аркылы эшне йөртеп, ошбу вәкыфны мәхәллә исеменә күчертер өчен мәзкүр мәхәлләнең попечителе Шакир Апанаевны вәкил кылганнар.

Хәнәфи әфәнде Кайбишев

Казан дарелфөнүненең [университетының] тыйб шөгъбәсен [медицина бүлеген] тәмам иткән Хәнәфи әфәнде Кайбышев, государственный экзамен

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Тәшәббес — бер эшкә тотыну, керешү.

тәмам итеп, җиденче апрельдә тыйблык шәһадәтнамәсе алды. Хәнәфи әфәнде студентлык дәверендә гаҗәп бер истикамәт [намуслык], сәбат [ныклык] вә иҗтиһад белән тәхсилдә [гыйлем алуын] дәвам иткән гаять мәхәббәтле бер симадыр[2]. Соңгы елларында «Аң» журналында аның матур язылган әдәби кыйтгалары да әледән-әле чыгып тордылар.

Кояш. — 1916. —№948. — 10 апр.

Фөкара [фәкыйрь] кызлар мәктәбе

Өченче көн мәдрәсәи Мөхәммәдия карашлы фөкара ир балалар мәктәбендә, еллык имтихан булу мөнәсәбәте белән, имтиханда булган мәхәллә байлары фөкара кыз балалар өчен бер мәктәпне кирәксенеп, шуны булдыру өчен 1700 сум кадәр иганә яздылар. Бу кызлар мәктәбе, фөкара ир балалар мәктәбе күк үк, Ак мәсҗед мәхәлләсе мәктәбе вә мәдрәсәи Мөхәммәдиянең бер шөгъбәсе итеп санарга фараз ителәдер. Мәктәп өчен урын тәгаен итүне әлеге фөкара мәктәбе мөтәвәллиләре үз өсләренә алдылар.

Кояш. — 1916. — №949. — 12 апр.

Тукай кабере өчен

Тукайның вафатына өч ел тулу мөнәсәбәте илә беренче апрельдә Акчуриннарның Гурьевка фабрикаларындагы кызлар мәктәбендә мәктәп балалары өчен Тукай кичәсе ясалган. Шул мәҗлестә Гөлсем ханым Акчуринаның тәшвикы [өндәве] илә вә башлап Гөлсем ханым үзенең 50 сум һәдия итүе илә Тукай каберенә 97 сум иганә җыелган. Ләмига ханым Иманколова тарафыннан җибәрелгән мәзкүр иганә идарәбезгә тапшырылды. Иганә итүче ханым вә туташларның барына да рәхмәт вә тәшәккер укыла.

Кояш. — 1916. — №950. — 14 апр.

Хәлил әфәнде Ибраһимов

Гәзитәбезнең сугыш сафындагы хәрби мөхбире прапорщик Хәлил әфәнде Әбелханов шәһәребездә мосафирдыр. Ул үткән көздән бирле сугыш сафында рота командовать итә иде. Бу көнгә кадәр ул баһадирлык өчен 4 нче дәрәҗә Анна медале белән тәлтыйф ителгән[3] һәм әүвәл подпоручиклык вә аннан соң поручиклыкка күтәрелергә гарыз [тәкъдим] ителгән. Хәзер ул өч һәфтәлек [атналык] отпуск алып, Казанга ял вә истирахәт итәргә кайткан. Аннан соң тагы сугыш сафына китәчәктер.

Кояш. — 1916. — №952. — 18 апр.

«Сәйяр» труппа артистлары

«Сәйяр» труппа артистлары видагъ [аерылышу] спектакленнән соң җәйге тәгътыйльгә [каникулга] таралачаклар. Г.Кариев — Уфа ягына кымызга, Болгарская, Тинчурин вә башкалары — дачага, Фатима туташ Гомәрова Орынбурга берничә концерт бирергә китәчәктер.

Кояш. — 1916. — №958. — 29 апр. ■

[2] Сима — төс, чырай.
[3] Тәлтыйф ителү — дәрәҗә яки орден белән бүләкләнү.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

Әхлаксызлык

Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без,
Кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.

Тик хәзер йөз сумны урлап килгүче угры кеби,
Күз салабыз чын сүз әйтердән элек як-якка без.

Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга,
Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.

Кызык гыйшык

Тирләп, эссе көндә койнырга теләп.
Бер кеше салкын су алды бер чиләк.
Өс-башын салган, вәләкин шикләнә
Су салырга тәнгә, чөнки чиркәнә.
Бер куя җиргә чиләкне, бер тота;
Нишләсен, мескен, суык су куркыта.
Күп азаптан соңра гайрәткә килеп,
Суны җилкә аркылы читкә сибеп
Куйды да, син нечкәләп бер бак сана:
«Әл дә тәнгә тимәде», — дип шатлана!

***

Мин моны яздым, бу — гыйшкым миследер,
Чөнки гыйшкым нәкъ минем шул төследер.
Мин сөям, хәтта ки гаклымнан шашам, —
Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам.
Юлда күрсәм, күз йомам, күрмим, имеш;
Ут йотып янсам да, сер бирмим, имеш!
Бер шигырь язсам да, ялган кул куям,
Мин сөйгәнне белмәсен, дип куркудан.
Тугры килсәм, сүз сөйлим салкын гына,
Булса да күкрәк тулы ялкын гына.
Бер хәбәр бар: ул хәзер киткән бугай,
Шәһәренә күптән барып җиткән бугай.
Кайда ул миннән җибәрмәк хат-сәлам?!
«Белми китте, күп шөкер», — дип шатланам.

***

Белми, дим дә, бәлки, белгәндер әле!
Әллә инде белгәнен белдермәде?
Аңламыйм, төшмим дә аңлау касдына[1],
Шигъреми җәйдем аягы астына;
Өенә җиткәнче басып кайтса аңар,
Шагыйре зур илтифатыннан санар.

Ике хәзрәт вә извозчик

Ике хәзрәт фәкыйрь генә бер мужикта эчләре шартлаганчы ашап чыгалар да, икендегә җитешә алмабыз дипме, ни өчендер, извозчик ялламакчы булалар.

Берсе кычкыра:

— Извозчик! Фәлән җиргә 15 тиен, — ди.

Извозчик:

— Юк, хәзрәтләр, иллешәр тиен бирерсез инде, — ди.

Хәзрәтләр:

— Ул ниткән сүз, без һичбер вакыт 15 тиеннән артык түләгәнебез юк, ерак җир түгел ич.

Извозчик:

— Ерагын ерак түгел дә, хәзрәтләр, сез хәзер генә менә бу йорттан ашап чыктыңыз. Әгәр мин шуны күрмәгән булсам, сезне 15 тиенгә дә алып кайтыр идем: хәзер сез атка авыр буласыз.

Хәзрәтләр:

— Ай ахмак! Кара,ниләр сөйли бит!

Күмәч кибетендә

А с р а у   к ы з:

— Абзый, бу сезнең биргән күмәчеңез герасинлы (керосинлы) икән, акчамны кире бирегез!

К и б е т ч е:

— Сезгә тагын ике тиенгә электрическилесе кирәк идемени?

Телеңезне чыгарыгыз!

Бер агызы (авызы) авырта торган хатын докторга килә. Доктор агызыны ачарга һәм телене чыгарырга куша. Хатын телене чыгара. Доктор янә чыгарырга куша. Хатын тагын бераз чыгара. Доктор янә бераз чыгарырга куша, хатын чыгара. Хатын бераз чыгарган саен, доктор янә чыгарырга куша. Ахырында хатын, тәмам аптырагач:

— Әфәндем! Әллә хатын-кыз дигәч тә, безнең телемезне биш аршын була дип беләсезме? — ди.

Гакыллы хайван

Эчәргә бик ярата торган бер кеше чишмә катыннан үтеп барышлый атын суара. Аты эчеп туйгач, башын басып, янәдән эчермәкче була. Ләкин аты эчми. Шуннан соң бу кеше үз-үзенә: «Гаҗәп! Бу хайван миннән дә гакыллы икән — мин әүвәл үзем туйганчы эчәм дә, аннан соң дуст-ишләр хакы һәм анлар хөрмәте өчен янә эчәм», — ди.

[1]Касдына — теләгенә, ниятенә.

Габдулла Тукайга кагылышлы мәзәкләр

....

Бакый Урманче

Чебен

Борынгы Касыйм ханнарының нәсел тармагыннан булган Фатыйма Шакулова Тукайны күрергә дип Мәскәүдән Казанга килә. Күп телләр белгән, укымышлы бу ханым Тукай белән күрешә. Сүз иярә сүз чыккач, Фатыйма ханым әйтеп куя:

— Сез, Абдулла әфәнде, Шеспирны күбрәк укыгыз! — ди.

— Мин инглизчә белмим бит! — ди Тукай.

— Инглизчә белмәсәгез, урысчасын укыгыз! — ди ханым.

— Урысчасын укыган бар, татарчага әйләндергән дә бар! — ди Тукай һәм үзенең Шекспирдан тәрҗемәсен укый башлый:

Күрәм кайчакта: җанкәмнең яңагына чебен кунган, —
Йөри бит шатланып шунда, үзенчә әллә кем булган!
Карыйм да мин, бәхетсез, шул чебеннең бәхтене көнлим:
«Ходаем, ни сәбәптән булмадым соң шул чебен мин!» — дим.

Гөлсем Мөхәммәдова

Йомгаклар

1911 елда Габдулла Тукай Әстерханга кунакка бара. Мәшһүр шагыйрь шәрәфенә бик олы тантана була. Әстерхан яшьләре Тукай хөрмәтенә спектакль күрсәтә. Ул вакытта хатын-кыз рольләре уйнарга мөселман артисткалар булмаган. Шуңа күрә хатын-кызларны ир-җегетләр башкара торган булган. Тукайның якын дусты, шагыйрь Сәгыйть Рәмиев телчән хатыннарны оста уйнавы белән дан казана. Бу кичәдә ул уң аягына аксый торган, зур күкрәкле телчән хатынны уйный икән.

Тамаша дәвамында Сәгыйть Рәмиевнең күкрәкләре урынына куйган җон йомгаклары тәгәрәп төшеп китә. Халык көлә башлый. Тукай да беренче рәттә елмаеп утыра. Сәгыйть Рәмиев каһәр суккан йомгакларны сәхнә буйлап куа китә. Халык тагы да катырак көлә. Тукай да көлә башлый. Ниһаять, Сәгыйть Рәмиев йомгакларны тота һәм аның ул йомгакларны үз урынына урнаштырырга маташуы халыкны тәмам эштән чыгара. Тукай да рәхәтләнеп көлә.

Тамаша тәмам булгач, Тукай уенчыларны котларга дип, сәхнә артына керә. Сәгыйтьне күрүгә, Тукай тагын көләргә тотына. Эчен тотып, бөгелеп төшә.

— Ә-ә-ә, — ди Рәмиев. — Син, Тукай әфәнде, теге йомгаклардан көләсеңме?

— Юк, Сәгыйть, — ди Тукай. — Мин синең ул йомгакларыңнан көлмим. Син уң аягыңа аксап сәхнәгә чыктың, сул аягыңа аксап кереп киттең!

Тукай көлә

Тукай Әстерханга килгәч, һәвәскәрләр башкаруында спектакль карый, спектакльдән соң концерт программасы — дивертисмент[2] күрсәтелә. Программада Зөлкарнәй Байкин исемле үсмер Тукайның шигырьләрен яттан сөйли. «Тәлләһһеф» шигырендәге:

— Ни сәбәптән җир йөзендә тәңгә — мунча, җанга — юк?! — сүзләрен Зөлкарнәй ялгышып:

— Җанга — мунча, тәңгә — юк! — дип тәмамлый.

Шушы ялгыш Тукайга бик кызык тоела, ул рәхәтләнеп көлә. Аңа кушылып, бөтен зал көлә, залга кушылып, Зөлкарнәй үзе дә көлә.

(Рабит Батулланың «Тузга язмаган хәлләр» китабыннан (1997) алынды.) ■

---

[2] Дивертисмент — күңел ачу, тамаша.

Мирасворд

1908-1909 елларда Казанда чыккан сатирик журнал

Г.Тукайның 1910 елда язган шигыре

Капка (иск.)

«Нокталы ...» (Хәсән Сарьян повесте)

... Шакиржанова

Мәче башлы ябалак (диал.)

Совет истребителе

Теркәгеч

Ерак басуда эшләүчеләрнең күчмә өе

«... яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы» (Г.Тукай)

Хәл бетү, талчыгу

Нәҗип Җиһанов операсы

Г.Тукайның 1908 елда язган шигыре

«Тик икәү без: ... да мин» (Г.Тукай)

Г.Тукай хезмәттәшлек иткән журнал

«Йолдыз»дан ... курка» (Г.Тукай шигыре)

Табигать Г.Тукайга бу сыйфатны мулдан биргән

Абдулла Алиш туган авыл

Кәрим Тинчурин драмасы

«... - егетләр» драмасы (Туфан Миңнуллин)

Йөз белән караган, алгы як

Г.Тукай туган авыл

... - яңа

Зиннур Мансуровның 1988 елда чыккан шигырьләр китабы

Саран; түбән җанлы кеше (иск.)

«... - менә» (Г.Тукай шигыре)

«Күрде милләт ... безне агачтан яки таштан да» (Г.Тукай)

Г.Тукай яшәгән кунакханә

Шомырт (диал.)

« ... зәһре ага җан берлә тәнгә» (Г.Тукай)

Олы юл

Якын, кадерле

Җимеш ашыйсың килсә, чәчәген ... (мәкаль)

Атны әйдәкләү

Ял өчен тукталыш (бор.)

Ил башлыгы, ил хуҗасы

Ярлы Кәрим туган авыл

Икенде, ахшам

Франциядә борынгы озынлык үлчәве

Кытай каласы

Мылтык чакмасы

Рәис Габдулла төзеде.

3 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: баб, «Очкын», ич, абак, Ләйлә, юш, Бәлҗәмин, Әсән, ханә, гает, смерд, иртә, гарт, су, Каюм, Кави, кур, тубал, Вано, эз, диван, балбал, Риан, Ирхан, яса.

Өстән аска: тәгин, Буби, рас, куз, бәет, Абә, Бикчәнтәева, Илбарис, җасус, лира, Уяв, Бах, очлым, Ге, Адана, ихрам, Нил, Кий, Надрюков, «Юлчы», тау, Әшрәф, крон.

«Болгар» номерлары. 1908-1910 еллар

«Безнең мирас»

елъязмасы / апрель

205 ел элек (1811)

Мәгърифәтче, төрки телләр белгече Салихҗан Бикташ улы Кукляшев (1811-1864) дөньяга килә.

95 ел элек (1921)

21 апрельдә күренекле тел галиме, тюрколог, СССР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы Әдһәм Рәхим улы Тенишев (1921-2004) дөньяга килә.

10 апрельдә Мәскәүдәге шәрык телләре институтында татар әдәбияты түгәрәге эшли башлый.

85 ел элек (1931)

Мәскәүдә «ГИХЛ» нәшриятында «Татар әдәбияты» сериясеннән Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы Г.Шәрипова тәрҗемәсендә урыс телендә басылып чыга.

«Яңалиф» журналында Һади Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасыннан «Икенче хат» дөнья күрә.

80 ел элек (1936)

22 апрельдә Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы Габдулла Тукайның 50 еллыгын үткәрү өчен юбилей комитеты төзергә карар чыгара.

70 ел элек (1946)

27-28 апрельдә Башкорт дәүләт педагогия институты һәм Мәҗит Гафури исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты Г.Тукайның тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми җыен оештырыла.

60 ел элек (1956)

«Совет әдәбияты» журналында Шәйхи Маннурның «Җир-әнкәнең сылу кызы» исемле шигъри бәяны басыла.

55 ел элек (1961)

11-12 апрельдә, Г.Тукайның тууына 75 ел тулу уңаеннан, 11-12 апрельдә Казан дәүләт университетында студентларның вузара фәнни конференциясе була. Анда бөек шагыйрь иҗаты турында Казан, Уфа, Ташкент, Чабаксар, Алабуга студентлары докладлары тыңлана.

25 ел элек (1991)

19 апрельдә Ленин мемориалында, Гаяз Исхакыйның әдәбиятыбызга әйләнеп кайтуы уңаеннан, әдәби-музыкаль кичә үткәрелә. Анда язучылардан Ибраһим Нуруллин, Ринат Мөхәммәдиев, Флүн Мусин һ.б.лар чыгыш ясый. ■



Сурәтләрдә – Тукай образы

Абрек Абзгильдин.
«Тукай төше»

Надир Әлмиев.
«Муза белән хушлашу. Г.Тукай»

Ефим Симбирин.
«Шагыйрь»

www.beznenmiras.ru

БЕЗ – МИРАСЛЫ ХАЛЫК!

«Безнең мирас» белән бергә булыгыз!

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275

«Безнең мирас» журналына башкача язылу:

- www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә
- редакциядә
- www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай ур., 74) , «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан метросы киоскларыннан сатып алырга мөмкин.